# Казан утлары



6
июнь
1967

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

## Бу санда:

Тукай премиясе лауреатлары . . . . . . . . 3

ПРОЗА, ШИГЪРЬ, ПЬЕСАЛАР

Ә. Давыдов. Мин — партизан; Татар китабына; Сынчы турында баллада; Була диләр...; Башны тагын минем кыса; Нигә башың салдың әле, туган; Юлның тигезе юк; Тыныч караучылар юк миңа; Дус кеше ул. Шигырьләр . . . . . . . 4
Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек. Автобиографик повесть. . . . . . . . . . . . . 9
Х. Вахит. Соңгы хат. Пьеса. . . . . . . . . 41
Р. Гатауллин. Лениза; Идеал; Кадерлем, кояш кызы син; Мин элекке һаман. Әгәр. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
М. Шолохов. Күтәрелгән чирәм. Романнан өзек . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Ф. Яруллин. Якташлар; Яши алмыйм шунсыз; Җилкәмдәге авырлыкны; Башыңны күтәр әле; Туган авылым. Шигырьләр. . . . . . . . 84

ДУСЛАР ҖЫРЫ

М. Кәрим. Әнием чирләгәндә; Айсылуның күз яшьләре. Шигырьләр. . . . . . . . . . 86
З. Биишева. Җырларым; Башкорт теле. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Ш. Бикколь. Нигә, иркәм; Соңгы трамвай. Җырлар. . . . . . . . . . . . . . . . . 88
К. Киньябулатова. Язмыш; Бик күп кирәк. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . 89
Ә. Атнабаев. Ышаныч. Шигырь . . . . . . 89
Ә. Бикчәнтәев. Койрыклы тел. Хикәя. . 90
И. Абдуллин. Мин ничек ир кешегә әйләндем. Хикәя . . . . . . . . . . . . . . . 92
Ф. Исәнгулов. Балаларым, газизләрем! Хикәя. . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
В. Исхаков. Базәр тавыгы. Хикәя. . . . . 96

6
ИЮНЬ
1967

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ ИЛЛЕ ЕЛЛЫГЫНА

Ф. Ибраһимов. Без түбәннән күтәрелдек. 99

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Ш. Бикчурин. Могҗиза тудыручылар. Очерк . . . . . . . . . . . . . . . . . 104

АГИТБРИГАДАЛАР РЕПЕРТУАРЫНА

Г. Нәбиуллин. Урак өсте. Сценарий. . . 116

ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

М. Әмир. Укучы өчен язабыз. . . . . . . 125

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫННАН МАТЕРИАЛЛАР

Н. Исәнбәт. Шәйхзадә Бабич. Истәлек. . 127

КАНДАЛЫЙНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

М. Госманов. Кандалыйның билгесез поэмалары. . . . . . . . . . . . . . . . . 135

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

В. Воронов. Мәңгелек яшьлек. . . . . . 139

ТӨРЛЕСЕННӘН

Н. Фәттах. Археология докторы А. Халиков белән әңгәмә. . . . . . . . . . . . . . 147
М. Госманов. Тагын Ибраһим хан ярлыгы турында. . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Х. Мәхмүтов. Садовников җыентыгындагы татар табышмаклары. . . . . . . . . . . . 151
Яңа китаплар. . . . . . . . . . . . . . 153
Ш. Галиев. Шигъри рецензияләр. . . . . 155
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . 156
Кроссворд

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянен адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

# *Тукай премиясе лауреатлары*



ТАССРның халык художнигы **Б. Урманче.**



Үзбәкстан ССРның халык артисты **Т. Ходжаев.**



ТАССРның халык художнигы **Э. Гельмс.**



ТАССРның атказанган артисткасы **Ш. Әсфәндиярова.**



ТАССРның атказанган артисты **Ш. Биктимиров.**



Артистка **Н. Гәрәева.**



Артист **Р. Тажетдинов.**

Г. Тукай исемендәге республика премияләре комитеты 1967 елда Г. Тукай исемендәге республика премияләрен Татарстан культура эшлеклеләре (Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Әмирхан, Г. Кариев, Г. Ибраһимов) портретлары сериясе өчен скульптор, ТАССРның халык художнигы Б. Урманчега, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Гүзәлем Әсәл» спектакле (Ч. Айтматов повесте буенча) өчен әсәрне сәхнәгә куючы Т. Ходжаев, художник Э. Гельмс, артистлардан Н. Гәрәева, Ш. Биктимиров, Ш. Әсфәндиярова һәм Р. Тажетдиновларга бирү турында карар чыгарды.

Татарстан язучылары бу талантлы дусларның уңышлары өчен шатлана, аларны тәбрик итә.

*Әнвәр Давыдов*

# МИН-ПАРТИЗАН

Килешергә өнди мистер Джонсон,
«Шартсыз-нисез» сүз куертырга.
Ә тегендә бомбовозлар сибә
Үлем вьетнамлы йортына.

Ә тегендә —
авылларны яндырып,
Напалм белән җирне көйдереп,
Үти Пентагонның гаскәрләре
Банкир, гангстерлар иреген.

Алдый алмас безне төче сүзләр,
Капиталның йөзен беләбез.
Җилкәбездә татымадыкмы соң
Мәкерлеген кичә генә без?

Әгәр фашист безнең илебезне
Баскан булса,
Джонсон әфәндә
Сатулашмас идеме
арзангарак
Безнең канны,
безнең яшәүне?

Ярдәм итеп җирдә фашист куйган
«Изге азатлык»ны сакларга,
Яудырмасмы иде напалмнарын
«Партизан!» дип безнең башларга?

Чакырма син, Джонсон, «Карагыз, —
дип, —
Аек акыл, аек хис белән». —
Башта ал син танкларың йөген
Хәлсез авылларның өстеннән.

«Партизан»нар, — дисең, — тынгы бирми,
Шуңа, — дисең, — тынмый минем җан».
Алайса ат: менә күкрәгем! —
Мин, минем җыр —
иң нык партизан!

1966

## Татар китабына

Рәхмәт сиңа!
Ертып минем күздән
Барлык уйдырмалар пәрдәсен,
Син күрсәттең бөтен биеклектә
Гадилеген һәрбер нәрсәнең.

Дөнья танудагы тәүге юлым
Артык гади,
Мин бит күрмәдем
Ерак гасырлардан кала килгән
Бөек һәйкәлләрнең үрнәген.

Мин узмадым ул чак,
Тетрәнеп,
«Тәмуг»лары аша Дантеның.
Минем пирамидалар —
Тирес түккән
Калкулыгы ындыр артының.

Тигәнәкләр,
Шайтан таяклары,
Тенге кошлар очкан тавышлар
Кичен пышылдаган дога белән
Бар да серлелеккә авышкан.

Менә шунда синең хәрефләрең
Карашыма минем калыкккан.
Күңелемә
Хаклык алып кергәнсең,
Үзең хаклык алып халыктан.
Һәм син шунда
Ертып минем күздән
Барлык уйдырмалар пәрдәсен,
Күрсәткәнсең бөтен бөеклектә
Гадилеген һәрбер нәрсәнең...

1965

## Сынчы турында баллада

Сынчы егет таудан бер таш алып,
Үзенә охшатып, бер сын чокыды.
Әле кискеч[1] эзеннән йөзе шадра,
Җансыз иде күзенең чокыры.

Менә рәссам үз уйларын салып,
Җанландырды сынның күзләрен.
Сөю йөрткән кулы белән сыйпап,
Шомартты ул шадра эзләрен.

---

[1] Кискеч — резец.

Хәзер сынның бөтен торышында
Тормыш, куәт уйный башлады.
Җанлылардан җанлы, мәрхәмәтле
Кебек булды хәзер таш җаны.

Кыска буйлы сынны җилкә белән
Пьедесталга рәссам күтәрде.
Сын ышанып үзенең зурлыгына,
Горур карый җирне, күкләрне.

Ә эчкерсез рәссам үзеннән дә
Өстенлегенә сынның инанды.
Бер әйттеләр аңа:
— Кара, рәссам,
Зурлыйсың бит юкка син аны!

Ул сын гына, эче — бушлык аның,
Тик салкынлык анда таштагы.
Эчкерсез иде рәссам.
Сынны алып
Җиргә атты, ватып ташлады...

Сын урынында кинәт бушлык күргәч,
Куркып китте башта күңеле,
Аннан иксез-чиксез киңлек күреп,
Яңа хыялларга күмелде.

Тик ниндидер бер авырлык хисе
Озак басып торды бәгырьне.
Үз баласын саклап калалмаган
Ана кебек җаны әрнеде...

Бер җыеп ул төзәтмәкче булды —
Шулкадәр җәл иде аңа сын.
Аннан бусына кулын селтәде дә,
Ясый башлады ул яңасын.

1966

●

Була, диләр, шундый рәхәт тормыш,
Һәрвакытта җаның канәгать:
Фәкать үзең, төрле хыял кормый,
Һәр адымда таба бел рәхәт.

Кешеләргә игътибарың хакын
Куша бел син үз эш хакыңа.
(Монда иң шәп политбюро — хатын,
Син киңәшеп кара хатынга).

...Менә шушы вакыйганы һаман
Үзләштерми минем күңелем.
Бер бәясез йөримен мин, заман
Кырларына тамып, түгелеп...

1966

●

Башны тагын минем кыса
Янып торган корыч кыршау.
Тирә-якка кешеләр баса,
Тора нәфрәт тулы гөр, шау:
— Ул гаепле! Мең кат аны
Җәзаларга, җәзаларга!
Ник ул үз исемен атады
«Данко юк» дип санаганда.
Ник кабызды ул йөрәген,
Басты безнең алга чыгып,
Бирегез аңа кирәген,
Китерегез тимер чыбык!
Көче җитмәс авыр эшкә
Ник алынган? Ник алынган
Без бик тыныч торган төштә...
Сук уңыннан, сул ягыннан!
...Мин, авырып, йомшап калсам,
Башымда гел шушындый шау.
Кыса һаман, һаман кыса
Янып торган корыч кыршау.

1966

●

Нигә башың салдың әле, туган,
Син авырудан дөнья җимерелмәс.
Тәрәзәгә күзең төшереп ал,
Күр, табигать бүген нинди яшь.

Үреләләр өскә яшь тирәкләр,
Ал-гөл чәчәк ата газоннар.
Кояш нурларында елтырыйлар
Яңа төзелештәге язулар.

Ике баштан икәү тотканнар да
Карават алып кайта ике яшь.
Шулай булгач,
Бар да үз урынында!
Күтәр башың!
Дөнья җимерелмәс!

1966

●

Юлның тигезе юк, турысы юк,
Тырыш, тап син, әмма дөресен.
Эшнең кечкенәсе юк, зурысы юк, —
Эшлә генә аны ил өчен.

1966

●

Тыныч караучылар юк миңа.
Үз күрәләр мине берәүләр.
Ә берәүләр ярсый-йолкына
Миңа төрле исем бирәләр.

Тирә-якта дуслар чагында —
Алар чиксез — шуңа шат күңел.
Дошманнарым торса алдымда —
Алар да бит, күрәм, аз түгел.

Төзәтәлмыйм инде холкымны мин.
Яхшымы бу икән, яманмы?
Нинди утта минем янганны
Тик аңласын иде халкым, дим.

Син аңларсың, халкым, минем кук
Тойдың хакын яман исемнең.
Бер заманны туган өеңдә үк —
Россияңдә үги идең син.

1966

●

Дус кеше ул — гүя җанга дару,
Сыкрау туган чакта күңелдә,
Дустың килсә, күңел шундый ару,
Сихәт дулкынына күмелә.

Ләкин табип, яхшы дару булса,
Юкка гына бирми дозалап.
Дуслык та шул бер чамадан узса
Агу була, ягъни бозыла.

1965

———●———

*Гомәр Бәширов*

# Туган ягым — яшел бишек



*Автобиографик повесть*[1]

## IV

Менә печән өсте дә житте. Әлеге шул бер күзе «өшегән» кара байталны жигеп, әти белән абый, мин болынга төшеп киттек.

Йорт хужалары, күбесе картлар, зур бер төркем булып, болын кырыеннан печән өләшеп баралар. Бу эшнең дә уртасында әлеге шул Гыйбаш абзый. Кишәрлекләрнең берсенә килеп житкәч, ул шобагалар салган әлеге шул ак эшләпәсен, селкетә-селкетә, өскә күтәрә. Кайсы да булса берсе үрелеп, эшләпәдән хужалыкларның тамгалары салынган юкагач шобага ала. Кем тамгасы чыкса, нәүбәттәге болын кишәрлеге шул кешегә була.

Үлән куерак төшкән жиргә барып житкәндә, агайларның кайсы кулын уа, кайсы теләрен чартлаталар:

— Их, менә бу төш миңа чыкса! — диләр.

— Миңа чыкса да эчне тишмәс иде дә бит!

Ат кузгалагы баскан яисә үлән такыр төшкән урыннарны күргә, сулагай кулларын селтәп, мондый хәлне күрергә язмасын дигәндәй, читкә борылалар:

— Чәнчелеп кенә китте! Бу төш чыкса елата инде!

— Мал-туарның бәхете булмаса, нишләрсең...

Мин, үзебезгә һәйбәт печәнлек чыгартасым килеп, һаман картлар тирәсендә бөтереләм. Гыйбаш абзыйның эшләпәсеннән күземне дә алмыйча, һаман көтәм. Чөнки, начар печәнлек чыкса, әти кашларын жимереп, тагын да кырыслана төшәчәк. Шундый кояшлы, куанычлы матур көндә бөтен авыл киенеп-ясанып болынга төшкәндә, минем аны да, бүтәннәр шикелле, шат итеп күрәсем килә.

---

[1] Дәвамы. Башы 5 санда.

Ләкин мин теләгәнчә булмады. Безнең сәнәк тамга Аҗги амбары янындагы кашлак урынга чыкты. Әти, каһәрләнеп:

— Әй, нәләш, нәләш! — диде. — Чәнчелеп кенә китсен. Уңмадык! Югары башы тап-такыр, суга башташ өлешен гел ат кузгалагы баскан!

Гыйбаш абзый, атлыйсын атламыйча, туктап калды:

— Сукранма, Бәшир абзый, көялеге килер, — диде. — Өлешеңә чыккан көмешең. Төптәнрәк чапсаң, бер йөк чыга да чыга моннан. Билләһи чыга!

Әти аның күзләренә усал итеп, туп-туры карап торды да:

— Әй, Гыйбаш, Гыйбаш! — диде. — Телең юмалый, ә менә күзләрең телең әйткәнгә ышанмый. Нигә рыяланасың? Юньлесе безгә чыгамыни аның?

— Нишләп алай дисең, нишләп чыкмасын? Мин сихерче түгел бит! Шобага ниндигә чыга...

— Нишләп икәнен син үзең беләсең! Оныткан булсаң, әйтим: кайда бал эчәм — анда мул печән, кайда фәкыйрь — анда печән дә такыр.

Гыйбаш абзый нидер әйтмәкче булып авызын ачты. Тик сүз таба алмады. Эшләпәсен салып башын кашыды. Күзен челт-челт йомып сакалын да сыйпаштырып карады. Алай да кирәкле сүз килеп чыкмады. Кулын селтәп китәргә җыенганда кинәт борылды да әтинең янына ук килде, бик кызганыч итеп пышылдарга керәште.

— Син гадел кеше, Бәшир абзый, җир астындагысын да күрәсең. Үземнең дә җаным кыйнала. Бер генә гөнаһым булды, бары бер генә! Нишлим соң? Балаларым ыштансыз да күлмәксез. Өемдә бер умачлык оным юк. Ачтан үлиммени?

Әти, казык каккан кебек, бер сүз әйткән саен йодрыгы белән җиргә кизәнә-кизәнә:

— Үл, үл, үл! — диде. — Җаныңны бер умачлык онга сатканчы, ичмасам, ачтан үл! «Ачтан үлсә үлде, иллә мәгәр баш имәде!» диярләр.

Әтинең кыяфәте бик усал иде. Әйтерсең, ул Гыйбашка чынлап та үләргә куша.

Гыйбаш кинәт кулын күкрәгенә куеп, кызганыч тавыш белән ыңгырашырга тотынды.

— Әвәлгесе — актыгы. Билләһи, валлаһи, таллаһи! Тагын берәр ишетсәң, битемә төкер, җәмагать җыенына чыгып кычкыр!

Шулай торганда аны староста дәшеп алды.

— Әй, нәрсә вәгазьләп торасың тагын анда?.. Чыккан — беткән, пычагыма кирәкме тагын!

Узып барышлый Гыйбаш аңа да ачуланды:

— Кит әле моннан! Син йөрисең тагын канга тоз салып!

Староста күзен акайтып, читкә тайпылды.

Күрше Гайни абзый узып барышлый шаяртып алды:

— И, кайгырма, Бәшир! Аның каравы, Аҗги амбары янында чыккан. Күршеңдә хәзинә бит! Тарттын чыгардын капчыгы белән онны! Тик ят шунда кабартма-коймак пешереп. Әйе түгелме?

Бу аның көлүе инде. Безнең өлеш янындагы «Аҗги амбары» дигәннәре тегермән буасында текә ярлы тирән бер чоңгыл гына ул. Берважытны тегермәннән кайтканда Аҗги кушаматлы кешенең шушы текә яр кырыенда арбасы ауган да биш капчык оны шушындагы чоңгылга төшкән. Шуннан соң, теге кешенең булдыксызлыгыннан көлеп, бу чоңгылны шулай атый башлаганнар. Аҗги Миңлебай моңа үзе һич үртәнми, киресенчә, шул мәзәкне сөйләгәндә иң элек үзе көлә башлый.

Кайбер хуҗалар, атларын юл буенда тугарып, эшкә дә керешәләр. Чаба башлаганчы күрше белән ике арага ызан сызарга кирәк икән әле. Әти кечтеки абыйга, елга буена төшеп, андагы казыктан туп-туры үзенә

таба печән ерып менәргә кушты. Үзе, чалгысын тотып, бу баштагы билгегә килеп басты. Минем дә эшкә ярыйсым килә иде.

— Әти, мин барыйммы, — дидем.

Мин әйткәнне әти колак яныннан гына уздырды. Аның мыеклары чуалган чак икәнен дә сизеп торам, югыйсә. Шулай да кыбырсыкның шул инде аның. Кысыласы килеп кенә тора бит! Тагын бер әйтеп карадым:

— Әти, мин сызыйм инде!

— Булмый ул синнән!

— Туп-туры атлап киләм, сиңа карап кына...

— Әйтелде бит сиңа!

Мин нәүмизләнеп китеп бардым да куак төпләреннән җиләк эзләргә тотындым. Җир җиләге белән каен җиләге шулкадәр пешкәннәр, кыпкызыл татлы тамчы булып мөлдерәп кенә торалар. Каен җиләгенең исе тагын, исе! Андый татлы хуш ис бүтән бер җиләктә дә булмый. Ул ис бармагыңда да әллә кайчанга хәтле бетми.

Бер-икене өзеп кабуым булды, тагын әти тавышы:

— Таптама!

Як-ягыма карандым да, иптәш малайлар да күренмәгәч, сөмсерем коелып, арбага менеп утырдым.

Бөтен болын өстенә, күз күреме җирне чуарлап, әллә никадәр печәнче сибелгән. Әле тегендә, әле монда кояшка каршы, яшен яктысыдай, чалгы йөзе ялтырап китә. Тирә-якта шундый күңелле! Бик күбесе печән чаба, яшь-җилбәзәк су коенып йөри, бер-берсенә шаян сүзләр әйтешәләр, рәхәтләнеп көлешәләр.

Болын өстен яңгыратып, әле унда, әле сулда көйләп-көйләп чалгы яныйлар. Чалгы чыңлаган тавыш инеш буендагы әрәмәләрдән кайтаваз булып яңадан әйләнеп минә дә басу өсләренә таралып юк була. Болын буйларын яңгыратып колыннар, кырыкмышлар кешнәп җибәрә. Аларның муеннарында кыңгыраулар, кечкенә шөлдерләр чың-чың килә. Әлеге базардан кире әйләнеп кайтмаган җирән колын күз алдыма килде дә миңа тагын да күңелсезрәк булып китте. Менә бит, мин бүген, мөгаен, аңарга атланып төшкән булыр идем...

Кешеләргә күңелле. Ә безнең әтинең кашлары һаман җимерелгән. Кечтеки абыйга да эләкте. Ул су буеннан әтигә таба, тар басмадан чыккандагы шикелле, әле бер ягына кыйшаеп, әле икенче ягына ава төшеп чалыш-чолыш атлый башлаган иде, әти аны шундук куырып алды:

— Туры бас! Нәрсә син, исерек аю шикелле, чытыйн-чотыйн атлыйсың? Аягың камырдан әвәләгәнме әллә?!

Күрәсең, үлән ерып менү дә җиңел эш түгелдер...

Арба өстеннән миңа чуп-чуар болын өсте бөтенләе белән күренә. Минем шикелле бала-чага чикерткәләрдәй арлы-бирле сикергәлиләр, җиләк җыялар, куышып уйныйлар. Минем дә шулай, ялан аягымны кытыкландырып, үлән арасында йөгереп йөрисем, әрәмәләр арасында уйныйсым, су буена төшәсем килә.

Ул арада, ирләр чапкан печәнне таратып киптерергә дип, авыл юлыннан төркем-төркем булып хатын-кызлар төшә башлады. Алар һәммәсе бәйрәмчә киенгән. Өсләрендә яңа күлмәкләр, алларында иңбашлары күпертмәле чиккән алъяпкыч, башларында яулык өстеннән, бәйләмичә, купшыланып өстән генә салган юка шәлъяулык, иңбашларында тырмалар. Бактың исә, алар җыенча киенгәндер әле. Соңгы җыен бәйрәменнән кичә генә кайттылар бит.

Шул чуар төркемнәр эченнән, ерактан ук таныйсым килеп, мин әни белән апай килеп чыкканны көтәм. Түшен киеребрәк, өздереп атлаган тәбәнәгрәк гәүдәле, иң купшы киенгәне апай булыр. Аның янында биле

авырткан сыман аз гына янтая төшеп, башын иебрәк, йомшаграк баскан озын буйлы, нечкәрәк гәүдәлесе әни булыр.

Ул, бәлки, берәр тәмлерәк ризык та алып төшәр әле. Я җыеннан калган бәлеш төбе, я берәр бөккән...

## V

Шулвакыт якында гына нидер ишетелгән сыман булды. Борылып карыйм — берәү дә юк. Әниләрне күрми калмагаем дип, юлга гына борылган идем, тагын әлеге аваз:

— Ә-ә-ә-әйй, ә-ә-ә-й-й!..

Бу юлы кемнеңдер көлгәне ишетелде. Күршеләр ягына карасам, Миңниса икән! Күрше кишәрлеккә тугарып куйган арба астыннан шул наян шаярта икән.

Менә бәхет! Без аның белән шундук йөгерешә-куыша су буена төшеп киттек. Миңниса өстенә яңа бишни күлмәк кигән, башында яңа яулык. Атлаган саен үлән арасыннан, биш тиенлек бакыр төсле, шомарып беткән аяк үкчәсе ялтырап китә.

Су буена төшеп кенә җитә идек, безне кире чакырып алдылар. Миңнисаның аягына кидерделәр.

— Бу тирәдә ялан аяк йөрергә ярамый, җылан чагар, — диде әнисе. — Аяк астыгызга карап йөрегез, җыланга басмагыз.

Миңнисаның әнисе дә үзе төсле кара күзле, бөтерелеп кенә йөри торган җинел гәүдәле кечерәк кенә бер апа иде. Ул безнең каршыбызга чүгәләп утырды да кызының чәч толымын урә-урә:

— Бер әфсен өйрәтимме? — диде. Үзе ничектер бик серле итеп елмая, бер сүз әйткән саен башын иеп куя. — Андый-мондый җылан өстенә барып чыксагыз, болай диегез:

Чәңки-чәңки, чәңки җылан,
Чәңки башлы кара җылан,
Агым суда раван җылан.
Атам-анам хакы өчен
Кузгалмый гына ят җылан!

— Картлар әйтә, шушыны әйтсәгез, җылан тимәс, ди. Шулай да очрамаса яхшырак инде...

Без җырга охшаган шушы кызык сүзләрне бергәләп көйли-көйли яңадан су буена төшеп киттек.

«Ажги амбарын» бик тирән диләр. Ул биек кызыл яры белән болын юлына түгәрәкләнеп уелып кергән. Аның суы да үзалдына шомлы булып, кара кучкылланып күренә. Яр буенда абагалар үсеп тора. Бер ягыннан икенче ярына, уктай атылып, ак түшле көрәшчәләр[1] уйнап йөри.

Биек яр башыннан чоңгылга ташлар, балчыклар атып уйный башладык. Кем ераккарак җибәрә ала? Кемнең атканы шәбрәк тавыш чыгарып чоңгылдый? Без аткан балчык кисәге «чоңгылт» итеп суга барып төшүгә, берсен-берсе куып китә бөҗралар, китә бөҗралар! Алар яр буена хәтле тирбәлә-тирбәлә киләләр дә шунда абага яфракларын тирбәтә торгач, хәлләре бетеп сүнәләр.

Ата торгач, Миңниса, нәрсәгәдер гаҗәпләнгән сыман, каушап минем беләгемнән тотты.

— Туктале! Әнә, күрдеңме? Бер капчык он! Әнә, әнә агып бара! — Ул зур булып ачылган кара күзләре белән бер миңа, бер су өстенә карый иде. — Карале, әгәренки аны су анасы юри чыгарган булса?! Безне кызыктырыр өчен!

[1] Көрәшчә, керәшә — яр карлыгачы.

Ул күрсәткән якка карасам, чыннан да капчыклы он! Ул без ясаган әлеге бөжралар астында, юри безне кызыктыргандай, акрын гына ярга таба агып бара. Иөгереп төш тә тартып чыгар! Миңниса мина карый, мин — аңа. Малай кеше булгач, нишләргә кирәген мин әйтергә тиеш инде. Бәлки әтиләргә кычкырыргадыр. Бер капчык он... Әгәр барып ала башлагач кына су анасы якаңнан эләктереп алса? Киттен аннары су төбенә. Яңа салага гомердә әйләнеп кайта алмассың. Җибәрмәс су анасы! Үзенә өйләндерер дә...

Ләкин мин берәр нәрсә уйлап тапканчы, капчыгыбыз агып барды-барды да керде китте яр астына! Мин, алдануыбызга ачуым килеп:

— Әй, болыт ич ул! — дип кычкырып җибәрдем. Күтәрелеп күккә карасак, безнең турыдан нәкъ шундый он капчыгы тикле болыт кисәкләре узып бара икән.

Безне өскә дәшеп алдылар. Әни белән апай әллә кайчан ук килгәннәр икән инде. Әни кара ипине шакмаклап кисте дә аның өстенә мул гына шикәр комы сипте:

— Менә прәннек булды, — диде. Без аны чыннан да прәннек шикелле тәмле итеп ашадык.

Шул арада кояш күренмәс булган, бөтен күк йөзен сорылы-зәңгәрле янгыр болытлары каплап алган. Әти белән әни шул кара кучкыллы авыр болытларга караштырып печәннең чабылган кадәресен таратыргамы, әллә янгыр яуганчы сабыр итәргәме дип киңәшәләр иде.

— Бүген әтәчләр дә вакытсыз кычкырды, әнә бакалар да бик сәер тавыш бирә. Ай-һай, яумагае!

— Елның елында шулай инде ул, — диде әни. — Игеннәр тилмерешеп янгыр көткәндә тамчысын да кызгана, инде печәнгә төштеңме, әйтерсең төбе төшә, тотына яварга!

— Я, сукранмый гына тор. Янгырның бик тансык чагы, ява бирсен!

Әни безнен ике арба арасында Миңниса белән куышлы уйнаганны карап торды да елмайды:

— Нәстә булган боларга? Күзләренә ак-кара күренми...

Юк, мина бернәрсә дә булмаган. Тик Миңниса белән бергә булу бик кирәк, ничектер, үзеннән-үзе гел уйныйсы, йөгерәсе, көләсе килеп кенә тора.

Шул вакыт болын белән янәшә Бишна урманы өстендә, бөтен дөньяны дерелдәтеп, бик яман гөрселдәп алды. Әни, бисмилласын әйтеп, безнең башыбыздан сыйпады. Янәсе, шулай сыйпагач яшен сукмый була.

— Житәр сезгә, чыркылдашмагыз, әнә анда Гөлдери бабайлар килә. Барыгыз, арба астына кереп утырыгыз.

Әни арбага бик күп итеп печән салды да аның өстенә зур торыпша каплады.

Арба астында борынны әчкелтем дегет исе кытыклый, шундук, аннан да уздырып, әле генә чабылган печән исе аңкып тора.

Башта, кайта-кайта, бик озаклап күк күкрәде, аннары шыбырдап янгыр яварга кереште. Әмма безнең арба астына җил дә, янгыр да үтми иде. Без кереп утыргач, арба асты ягымлы гына бер җылы куышка әверелде. Миңниса тәгәрмәчкә аркасын терәп җайлап утырды да як-ягына каранды.

— Әйдә, бу безнең ак өебез булсын! Әйеме? Бүген бездә аулак өй икән, ди, син безгә кич утырырга килдең, ди. Әйдәсә, хуш килдең! Кәвешеңне шунда сал. Бишмәтеңне чөйгә эл, бүрекңне монда эл! Әйдә монда, түргә уз, утырып җибәр киезгә. Хәзер самовар куям, йомырка тәбәсе өлгертәм. Төшеп китим мин базга, алып чыгыйм эремчек, каймак белән бал да май.

Миңнисаның куллары җелт-җелт килеп уйнап кына тора. «Эһ» дигәнче табын да өлгерде, чуерташ самовар булды, ат кузгалагының чәчәге эремчек белән май булды.

— Әйдәсәнә, әйдә әле, кызлар шикелле кыстатма, я әле, ашап кына утыр сана әле... Аннары уен башларбыз, я йөзек салыш, я арка сугыш уйнарбыз...

Әмма «сый-хөрмәте» мул булудан шулай авызы колагына җитеп бик канәгать кыяфәт белән мине сыйлап утырганда, Миңниса кинәт үзгәрде. Бөтен «табынны» бер сыпыру белән аударып ташлады. Аякларын бөкләп утырды да аларны күлмәк итәге белән төреп куйды.

— Әем, кирәкми! Аулак өйдә икәү генә булмыйлар... — Күзләрен челт-челт йомып, «тагын нишләргә икән?» дигәндәй беравык миңа карап торды.

Ул, җәһәт кенә, яңгырлы тышка күз салды, иркә балалар сыман иреннәрен бүлтәйтә төшеп, куркынгандай күзләрен зурайтты да ашыгаашыга пышылдарга тотынды.

— Баягынак болынга төшкәндә, имә? — иске зират турысында без пәри туе күрдек. Имә? Юлның уртасыннан бөтерелеп килә, агай, менә коточкыч! Үзе манара тикле, башы болытларга кереп киткән. Килә, менәтерәк, имә? Үзе зыр-зыр әйләнә, ә уртасында ниндидер кара нәстә утыра. Әби әйтә, имә, өермәнең уртасында, килесенә утырып, кисабына таянып, убырлы карчык шулай туй итеп йөри, ди.

Миңниса, үзе сөйләгәннән үзе үк курыккандай, як-ягына каранды. Ул һаман шыпырт тавыш белән сөйләшә иде әле.

— Шунда, килесенә утыртып, убырлы карчык алып китсә, ә? Син куркыр идеңме?

Мин башымны гына селектем. Андый хәлләргә дучар булганда нишләргә кирәген мин яхшы белә идем.

— Һи, аннан да курыксаң! Бисмилла әйтәсең дә өермәнең нәкъ уртасына китереп сугасың! Белдеңме? Бөтен өермәң, алтын булып, аяк астыңа чәчелә дә китә!

— Таягың булмаса?

— Булмасамы? — Андый чакта ни белән сугарга икән дигәндәй як-ягыма карандым. Ләкин арба астында андый эшкә ярарлык берни дә күзгә чалынмады. Шулай да сер бирәсе килмәде. Мин күзне дә йоммадым. — Аягым белән тибәм! — дидем.

Булдыра алган кадәр тәәсирлерәк итеп, мин дә сөйләнергә тотындым. Шулай да, никадәр тырышсам да, Миңнисаның әллә ни исе китмәде. Минем исә бу кызыйга ничек тә күпне белүче йөрәкле малай булып күренәсем килә иде.

Тышка күз салсам, безнең тирәдә яңгыр туктаган, авыл өстенә утлы-яшелле, сарылы-зәңгәрле булып, бик биек, бик матур салават күпере күтәрелгән. Арча ягында һаман күк күкри иде әле. Шунда, бәхеткә каршы, әни сөйләгәннәр исемә төште.

— Күрәсеңме салават күперен? Әнә... — дип бармагым белән күрсәтмәкче идем, Миңниса минем кулымны бәреп төшерде.

— Чү, ярамый! Әби әйтә, салават күперен бармак белән күрсәтсәң язык була, ди.

— Әм, ярар... Беләсеңме нинди күпер ул?

— Әллә тагы...

— Ә мин беләм!

— Ие, беләсеңдер, бар!

— Билләһи беләм! Әйтимме нигә күк күкри?

— Нигә соң?

— Яңгыр фәрештәләре, зур-зур мичкәләргә бик күп атлар җигеп, әнә шул салават күпереннән күк өстенә дөбер-дөбер су ташыйлар.

— Ә суын кайдан алалар?

Ул елларда мин барган иң ерак авыл — Әзәк иле бездән егерме биш чакрым чамасы иде. Икенче якта, урман артында, Яңилдә булганым бар. Мин, тышка башымны сузып, боларның бераз чамасын тарттым.

— Әнә күрәсеңбит, салават күперенең баш-башлары кайларга дугайланып барып төшкән! Я, бәлкем, аның бер башы Әзәк иле инешендәдер, икенче башы Яңил суында.

Миңниса хәйран калды:

— Ай-яй, ерак икән!

— Суны әнә шул инешләрдән алып меналәр дә җир өстенә коялар. Менә сиңа яңгыр була. Белдеңме?

— Ә күк ничек күкри?

— Арбалар белән күпердән чабып узганда бик каты дөберди бит! Менә шул инде. Буш мичкә белән су алырга төшеп барганда, бигрәк тә каты гөрелти икән.

Миңниса минем күзләремә туп-туры текәлеп бераз тынып торды. Ул ышанырга да, ышанмаска да белмичә икеләнә иде шикелле. Бераздан тагын сорады:

— Алайсам, яшене каян чыга?

Ул кадәресен мин үзем дә чын-чыннан белеп бетерми идем. Әмма монысына калгач кына сер бирәсе килмәде:

— Анысы инде атлар бик каты чабып барганда шуларның дагаларыннан чәчрәгән очкыннардыр... — дидем.

Шундый матур күпердән дөбер-дөбер яңгыр ташучы фәрештәләрне үз күзе белән күрергә теләгәндәй, Миңниса, арба астыннан башын сузып, мөлдерәп торган кара күзләре белән беравык салават күперенә карап торды. Аннан миңа күз салды да ничектер наян гына бер елмаеп куйды.

Болын өсте әллә кайчан аязган, олылар һәркайсы үз эшенә керешкән. Безнең исә хыялыбызда туган шул югарыдагы тылсымлы дөньяның матурлыгыннан аерыласыбыз килми иде әле. Безне әни дәшеп чыгарды.

— Әйдә, утырмагыз анда куләгәдә. Кояшка чыгыгыз. Әнә, Миңниса белән печән таратыгыз.

Апайның безне күргән саен авызы ерыла да, ничек тә булса берәр сүз әйтәсе килгәне сизелә иде. Бу юлы ахрысы түзмәде, шаяртмакчы булды:

— Миңниса килен белән диген!

Шуны ишетүгә, Миңниса кинәт дерт итеп борылды да, бер сүз дәшмәстән, башын түбән иеп, китеп тә барды. Әни апайны шелтәләргә тотынды.

— Син дә шул, — диде, — телең авызыңа сыймый. Нигә урынсызга рәнҗетәсең? Бала гына ич әле алар.

Әти миңа да эш тапты.

— Бөтен кеше эшләгәндә йөрмә тик, — диде. — Әнә, атны сугарып мен!

Тезгеннең очыннан ук тотып атны су буена җитәкләп киттем. Аннан соң миңа печәннән ат кузгалагы сабакларын чүпләргә куштылар.

Әти белән әни, «яңгырга китсә, черемәгәе» дип, инкелрәк урыннардагы печәнне калкулыкка ташырга тотындылар.

Шулай телэр-теләмәс селкенгәләп йөргәндә күтәрелеп карасам, куркудан тыным буылып тавышсыз калдым. Әни сәнәк белән күтәргән печәннән, аның нәкъ башы өстендә, камчы юанлыгы бер кара нәрсә, арлы-бирле айкалып, асылынып бара. Ниһаять, ачыргаланып кычкырып җибәрдем:

— Әни, җылан! Ташла печәнеңне!

Әни, күтәрелеп карауга печәнен ташлап, арба янына барып ауды. Без шул тирәгә йөгерә башлаган идек, әти ачуланып йодрык күрсәтте.

— Барасы булмагыз!..

Ул үзе, йөгереп барып, жыланны сәнәк белән җиргә кысты.

— Тал чыбыгы! Тизрәк! — дип кычкырды.

Абый белән без этигә чыбык китереп биргәндә жылан, сәнәк астыннан ычкынырга теләп, тегеләй дә болай айкала, койрыгы белән шап та шоп сәнәк сабына суга, ике аерлы телен чыгарып, бик куркыныч итеп сызгыра иде.

Тал чыбыгы белән чажылдатып суга торгач, эти аны үтерде дә, таягына элеп, чокырга илтеп ыргытты.

— Кара жылан! Агулысы, — диде. — Ярый әле әнигезнең өстенә төшмәгән.

Шунда минем бик тә телем кычыта башлады. Әнигә иң башта мин кычкырганны әйтәсе иде бит, әйтәсе иде! Тик эти мактанганны бер дә яратмаганлыктан, әйтергә кыймадым. Шулай да сүз кушарга җай чыкты:

— Эти, Миңнисаның анасы әйтә, жылан күргәч, аңа чәңки-чәңки, чәңки жылан, чәңки башлы кара жылан... дип әйтергә кирәк, ди. Шулай дип әйтсәң, чакмый, ди.

Шунда этинең бүген беренче тапкыр елмайганы күренде.

— Һә, шулаймыни? Кара, ник әйтмәдең соң? Жыланны иң элек син күрдең бит! Ник такмаклап күрсәтмәдең чәңки-чәңкиеңне?

Мин түбән карадым. Бер сүз дә әйтә алмыйча, куркуыннан әле һаман да арба янында дерелдәп торган әни янына киттем.

## VI

Без хәзер, үзеннән-үзе шулай туры килгәндәй, Миңниса белән көн саен диярлек очраша торган булдык. Әгәр ул озаграк күренми торса, мин, тау башындагы чирәмгә чыгып, аның я ишек алларына, я урамга, я чишмәгә су алырга чыкканын көтеп утырам. Ул күренүгә, мин аңа, егетләрдән күрмәкче, акрын гына тамак кырган булам, я сызгырып җибәрәм. Ул миңа, башкаларга сиздермәслек итеп кенә, кул болгый. Миңа шул җитә кала. Мин, шуңа бик канәгать булып, көне буе йөгерә-йөгерә эшләп йөрим: ындырда, я тау кырыендагы чирәмдә каз бәбкәләрен көтәм, коралларын кайраганда этигә кайрак әйләндереп торам, әнинең дә бетмәс-төкәнмәс йомышларына йөгерәм.

Озакламый уракка төштеләр. Урак урырга яшьрәк булсам да, мине дә кырга алып йөри башладылар.

— Без урганда бала карар, бала йоклаган арада көлтә ташыр, — диделәр.

Бала дигәннәре сеңелем була инде. Җир өстенә барып төшкәч, абый белән апай, җиңсәләрен киеп, алъяпкыч итәкләрен билләренә кыстыралар да, икесе ике кишәрлек алып керт тә керт урырга тотыналар. Әни сеңелемне кечкенә арбасына сала да, янына тезләнеп, йокыга киткәнче имезеп ала. Сеңелем авызын чөмәкләндереп, иреннәрен чәпелдәтә-чәпелдәтә чыбылдык эчендә йоклый башлагач, мин, арба күләгәсенә утырып, үземә уен эзли башлыйм. Шырпы тартмасына тирарайлар жыяргамы? Әллә саламнан камчы үрергәме?

Тик мин берәр уен тапканчы әни миңа эш куша:

— Улым, бар, бәби йоклаган арада Ушарадан су алып мен!

Савытыма су тутырып кире менәргә борылганда, болын кырыендагы кара-кучкылланып торган кое сыман түгәрәк сулы чокыр янында туктадым. «Диңгез күзе» инде бу. Аны бөтен авыл шулай дип йөртә. Ул, кечкенә булса да, кыш буе катмый, гел буланып ята. Аның суы чишмә суы төсле түгел, коңгырт кара төскә кереп, үз алдына куркыныч булып күренә. Аның төбе дә юк, диләр. Аңа башта колга төшереп караганнар — төбенә җитмәгән. Шуннан соң, башына таш бәйләп, дилбегә төшергәннәр — ул да җитмәгән... Картлар әйтә, төбе булырга, ул бит

жир асларыннан туп-туры диңгезгә барып чыга, ди. Диңгез дигән иксез-чиксез дәрья, менә шушы күзе белән, әллә кайлардан торып, бөтен дөньяны күрә, ди...

Бу төпсез чоңгыл, сихерләгәндәй, мине үз яныннан җибәрми торды. Сагаеп кына шуның дереддек кырыена барып бастым да курка-курка гына кетә башладым: менә хәзер, кайнап чыккан шикелле актарылып-чайкалып да, нәрсә дә булса калкып чыгар, я булмаса китапларда язылган әвен тикле теге диңгез балыгы күренеп китәр...

Ниндидер тавыш ишетелгән сыман булды. Күтәрелеп карасам, өстән апай кычкыра икән:

— Мен тизрәк, юньсез малай, әнә балаң уянды.

Ярый әле: сеңелкәш елак бала түгел, авызына имезлеген каптырып, арбасын бераз тартып йөрсәң, иреннәрен турсайтып, тагын эреп китә.

Мин яңадан әлеге «диңгез күзе» турында уйларга тотынам. Менә шуңа чумарга иде дә, йөзеп-йөзеп, диңгезнең үзенә барып чыгасы иде. Абый үзенең китабында укый бит: диңгез уртасында җәзирәләр [1] бар, ул җәзирәләрдә әлвән-әлвән мивәләр [2] пешеп тора, ди. Бик тәмле ризыклардыр инде ул мивәләр...

— Малай, атны күчереп кил!

Кара бияне үләнлерәк урынга күчереп, казыгын кагып кына торганда, апай тавышы ишетелә:

— Йөрмә анда ләнтәйләнеп! Әнә көлтә ташы! Тиз бул!

Иртәдән бирле өч кеше урган көлтәне бәпкә куясы урыннарга ташырга кирәк. Арыш куе түгел, көлтә дә күп чыкмый. Шулай да кулмәк эченә тулган кылчык аркаларга, янтауларга кадалып үрле-кырлы сикертә. Ялан аякка камыллар кадала, карамыйрак атласаң, утлы күзнең зәһәр инәләре, авырттырып, чәнчеп кала. Камыл ерып йөри торгач, аяк йөзенә, чебиләгәндәге шикелле, бөрчек-бөрчек кан тибеп, ачыттырырга тотына.

Төшкә таба тамаклар кибә. Кулбашлары сызларга тотына, аякларның атлар хәле дә калмый. Инде олылар да бик арыган. Әни әледәнәле урә катып билен уарга тотына, абый белән апай, авызларын чылатып, маңгайларына юеш сөлге бәйлиләр. Шулай да туктарга ярамый. Әти бу җирне төшкә хәтле бетереп кайтырга кушкан.

Шунда зур өмет белән авыл юлына карыйсың. Уракчылар көндезгә кайта башламаганнармы?..

Шунда абый тагын бөтен өметне өзә:

— Нәрсә син анда карга саныйсың! Көлтәне тизрәк ташып бетер дә атны алып кил. Икенче җиргә күчәбез!

Шулай уракка йөргәндә, бер туры килмәсә, бер туры килеп, Миңниса белән без басуда да очрашкаладык. Мин инде аның атасы белән анасын да, хәтта корсагына ак ямау салган ала-кола атларын да әллә кайдан ук шәйли торган булдым. Миңнисалар җире башыннан узганда мин, дилбегәне үз кулыма алып, кечкенәрәк бер егет сымаграк кыланырга тырыша идем. Миңниса ишетсен өчен, дилбегәне болгый-болгый атка да кычкырыбрак дәшәм:

— На, на! Нәрсә аяк өсте йоклап барасың!

Шул вакыт апай, кулын күзләре өстенә куеп, карангаларга тотына:

— Кара, кара, бәпкәләр арасыннан нинди төенчек тәгәри? Әй, төенчек түгел, Миңниса килен икән бит ул! — дигән була.

Мин аңа йодрык белән кизәнәм. Тик апайның зәңгәрсу-яшькелт күзләре шундый әчкерсез сөйкемле елтырый, шундый якын итеп, яратып елмая, аның белән мин үзем дә көләргә тотынам.

---

[1] Җәзирә — утрау.
[2] Әлвән-әлвән мивәләр — төрле-төрле җимешләр.

VII

Аннары без Миннисa белән азан тыңлаганда очраша башладык. Уразаны тотканы тота, тотмаганы болай гына да уздырып җибәрә. Яшьрәк ирләр белән егетләр, бер-берсе белән очрашканда, моны яшереп тә тормыйлар:

— Нихәл, уразаның хәле китмәдеме әле? — дигән була берсе. Икенчесе:

— Һи, хәле китәргә, тоттырмый бит ураза! Койрыгы кыска! — дип шаярта.

Әмма кемнең халык алдында «уразасыз» дигән яман атын чыгарасы килсен? Шунлыктан, тик йөриләр шыпырт кына тегесен-монысын капкалап. Безнең эше ялан аякларны, кичен авыз ачар алдыннан, урам буенча шаулап кайтыр өчендер инде, азан тыңларга җибәрә торганнар иде. Безнең йорт мәчет янында гына булганлыктан, бала-чаганың күбесе безнең бакча буена, я тыкрыкка җыела да, бу тирәләр кичен гөрләп тора.

Кыз балалар, күбесенчә, бер тирәгә җыелып, чүпләм таш уйныйлар. Миннисаның, күп уйный торгач шомарып беткән, чикләвек кадәр генә вак ташларны нәни бармаклары белән җелт-җелт китереп кенә элек берәмләп, аннан соң икешәрләп, өчәрләп, дүртәрләп, башта учына, аннары бөтенесен өскә чөеп, берсен дә җиргә төшермичә кул аркасына алуын сокланып карап торам. Кызлар арасында аңардан җитезрәк, аннан да матуррак уйнаучы тагын кем бар? Берәү дә юк! Миннисa үзе мине күрмәгәнгә салынса да, минем карап торуымны яратуын әллә кайдан сизәм. Мин карап торганда, ул ничектер җинеләеп китә, ешрак көлә, күзләре дә бүтән төрлерәк елтырый башлыйлар.

Менә кызлар кинәт кенә сикерешеп торалар да түгәрәк булып яңа уен башларга җыеналар. Шунда мин дә алар арасына барып кысылдым. Әмма кызларның бер ишесе, әллә безнең дуслыктан көнләшеп, әллә болай гына кәҗәләп, түгәрәктән чыгып китте.

— Әем, әем! — дигән булдылар. — Бик хаҗәте бар! Ул уйнаса, мин уйнамыйм. Моны кызлар гына уйный.

— Шулай, шулай! Әнә такмагында да әйткән: «Без уникe кыз идек», дигән, уникe малай димәгән.

Шунда берсе читкәрәк тайпылды да, кулын авызына бүрәнкә итеп куеп, бии-бии үчекләргә тотынды:

— Кияү, кияү, мыяу-мыяу!

Минем инде мондыйны беренче ишетүем түгел иде. Андый чакта үзүзеңне басымчак иттереп дәшмичә калдыңмы, көт тә тор, тора-бара синең күзеңне ачырмый башлыйлар. Теге кызның артыннан җитеп сөяклӛч аркасын дөпелдәтеп килмичә күңел тынычланмады.

Хәзер инде кызлар бөтенесе тавыш кубардылар:

— Әһә, кыйнашамы? Уйнатмыйбыз булгач, уйнатмыйбыз! Миннисa иркә кызлар шикелле, иреннәрен турсайтып, йомшак сүзе, ягымлы карашы белән иптәшләрен юмаларга тотынды.

— Бер генә уйнасын инде, бер генә!

— Әем, әем, уйнамасын! Үзе кыйнаша, үзе... малай!

— Я инде!

— Юк, юк, якын да килмәсен!

— Я инде, бер тапкыр гына ич инде.

Шунда кызлар үзара күз кысышып алдылар.

— Билләһи, валлаһи диген!

— Билләһи менә, валлаһи бер генә!

— Я, ярар инде алайсам, тавышы тыгылсын!

Эшләр көйләнде. Менә без — унбер кыз һәм чыркылдык чәүкәләр

арасында калган бердәнбер карга сыман — мин, барыбыз бер авыздан, уенның такмагын көйләргә тотындык:

Без, без, без идек,
Без уникe кыз идек.
Базга төштек — май ашадык,
Келәткә кердек — бал ашадык.
Бер тактага җыелдык,
Таң атканчы юк булдык.
Кап та коп, Якуп!

Шундук, авызларны йомып, «мм...» дип суза башладык. Һәммәбез, иреннәрне кысып, бер-беребезгә карый-карый, мөгерибез. Әмма шундый караңгы төшеп килә торган тыкрыкта, кайсының борын асты елтыраган, кайсының чәче тузгыган шушы чекери күзле кыланчык кызлар арасында, малай башым белән, шулай бозау шикелле мөгерәп утыруым миңа бик тә кәмит кебек тоелды. Мин түзә алмадым, кинәт көлеп җибәрдем.

Кызларга шул гына кирәк иде. Барысы берьюлы кычкырып җибәрделәр!

— Әһ-һә! Ачты, ачты! Беренче ул ачты!

Миңа җәза тиешле. Анда да барысы берьюлы ябырылдылар:

— Кем түбәсенә төштең?

Як-ягымнан кабыргама төрткәлиләр, ашыктыралар. Мин, алдын-артын уйламастан, телгә килгән беренче күршенең исемен әйттем.

— Сөләйман абзыйлар түбәсенә.

— Алар ничә кеше?

Шундук кайсыдыр санап та өлгерде:

— Алтау!

— Әһә, алтаумы? Китер маңгаеңны! Менә сиңа! Менә сиңа!..

Кызлар бик тырышып, берсе артыннан берсе «шык» та «шык» минем маңгайга чиертергә тотындылар. Ичмасам, күземне дә йоммыйм. Кечтеки генә булсам да малай кеше ич мин!

Пәке калаш та уйнадык, биш таш та туйдыра башлагач, йөгерешеп, качышып уйнарга тотындык. Мәчет тә, азан да — бөтенесе дә онытылды, бөтен урам чыр-чу белән тулды. Күршеләр түзә алмадылар:

— Җитте сезгә шайтан балалары! — дип кычкырдылар.

Шуннан соң, малае-кызы бер очтан, күрше Гайни абзыйларның коймалары буена тезелештек. Миңниса ике тезен янәшә үк китереп аларны күлмәге белән каплый да кочаклап утыра. Кайчакларны башын беләкләренә сала да, мине дә, бүтәннәрне дә күрмичә, күз карашын әллә кайларга төбәп, тынып кала. Нәрсә уйлый икән ул шундый чакта?

Мәзин бабайның, иске кәвешен лыштырдатып, икенде намазына узып китүен инде онытып бетердек! Кояшның Бишна урманы артына төшеп күренмәс булуына да инде әллә кайчан. Хәтта мәчет тәрәзәләренә төшкән шәфәкъ шәүләсе дә сүнәм-сүнәм дип кенә тора. Урамнарга, тыкрыкларга эңгер-меңгер иңә башлады. Азан һаман юк та юк. Уразалы кешеләр әле бу капкадан, әле икенчесеннән башларын сузып безгә карыйлар. Ул мескеннәрнең тавышлары ук чыкмый башлаган.

— Оланнар, азан әйтмәдеме соң әле?

Һәммәсе зарыга, тик мин генә зарыкмыйм. Мәзин бабай манарасына никадәр озаграк менми торса, минем рәхәтем шулкадәр озаграк булачак...

Шулай да ул вакыт җитте. Мәзиннең башта манара баскычыннан меңгәндә тамак кыргалап алуы ишетелде. Бераздан манара тәрәзәсеннән чалмалы башы күренде. Ул авызын ачарга өлгергәндерме, юктырмы, бала-чага, дәррәү күтәрелеп, кычкыра-кычкыра йөгерергә үк тотынды:

— Азан әйтте, азан әйтте!..

Миннисa белән без, кулларыбыздан тотышып, безнең яндагы тыкрыктан түбән таба йөгерәбез. Мин аны тау башына кадәр озатып куям да артыннан карап калам. Миннисa тау кырыеннан сузылган тар сукмактан, кәҗә бәтиедәй сикерә-уйный, өйләренә таба оча.

## Тырма эзләре

### I

Бер көнне кичке чәй вакытында эти гел миңа күз салгалап утырды. Табын яныннан торып киткәннән соң, мин тегесен алып, монысын кузгатып верстак тирәсендә кайнашканда да, каш астыннан гына гел мине күзәткән кебек күренде. Эш кушмакчы буламы? Әллә берәр шуклыгымны сизеп алып, элэктерергә чамалыймы?

Мин инде, ул-бу кузгалганчы мыштым гына чыгып таярга җайланып, ишек янына ук барып җиткән идем, эти кырт кисте:

— Йөрисе түгел! Җитте сиңа! Ят та йокла. Иртәгә тырмага чыгарсың.

— Әһә! Әнә ничек! Иртәгә орлык чыгарасы көн икән. Әйтәм аны, әни бүген көне буе печәнлектә йомырка җыеп йөрде. Әйтәм, эти белән абый, бәйрәмгә әзерләнгәндәй, ишек алларын, урамнарны себерделәр, сабан белән тырмаларны, барлык кирәк сбруйларны хәстәрләп куйдылар. Бөтен өй эче, мунча кереп, юынып чыкты. Апай самоварны агартып, аңа йолдызлар төшерде, идән-сәкене юып чыгарды. Ишек алды белән өй эче үзенә күрә бер бәйрәм төсе алды.

Мин шундук, тәүфыйклы малай кыяфәтенә кереп, чишенергә тотындым. Менә нилектән эти шулкадәр сынап караган икән! Бу малайның буе-сыны, җегәре-мазары ничек, тырмага кушарлык рәте-юне бармы, булдыра алырмы? — дип чамалаган икән! Дөрес, минем җиде-сигез яшьтә үк тырма тырмалаганым, хәтта сабан артыннан да йөргәнем бар. Тик ул бит я этигә, я абыйга ияреп кенә. Ә монда инде үзең баш, үзең муен. Үзең башлыйсың, үзең түгәрәкләп тә куясың.

Мин иртәгә, чәчү башланган көнне, иртүк торып олы кешеләр белән чәй эчүләр, басуга чыгып китүләр турында йоклаганчы хыялланып яттым. Иртә белән әни, мөгаен, каймаклы катык ашатыр, бәлки, коймак та пешерер әле... Бер-ике йомырка эләгә дә эләгә инде. Урталай ярасың да тоз сибеп ашап җибәрәсең. Шул киселгән җиренә азрак атлан май да тидереп алсаң, телеңне йотарлык ук була да бит...

Болай кыр эшендә йөргәч, син инде олы кешеләр белән бер үк төрле ашыйсың, бер табактан, үз маңгай тирем, үз кул көчем керде дип, кыенсынмыйча. Юкса бит...

Әйтергә генә ансат, сигез тутырып килүемә карамастан, минем һаман да үз иманам[1] юк иде әле. Дөрес, эти дә, бүтәннәр дә минем үземә моны артык сиздермәскә тырышалар. Шулай да берәр кеше белән сөйләшеп утырганда ул турыда әледән-әле сүз чыкмыйча калмый: берәр читтән килгән кунак, сүз арасында:

— Җиде-сигез кашык күтәрәсез икән. Иманагыз икәү генәмени? Ир-ат сездә өчәү ләбаса? — ди.

— Менә кече улыбыз җир өләшкәннән соң туды да җирсез калды шул!

Җирне уникe елда бер генә, анда да ирләргә генә бирәләр. Мин, күрәсең, бу дөньяга җир бүлгәнче килергә өлгерми калганмын. Ваемсызлык түгел диген!.. Менә шул уңмаганлык аркасында, ун елдан артык җирсез яшәп кара әле.

[1] Имана — патша вакытында бер җанга тигән җир һәм шуннан түләнә торган налог.

Берәү дә бер сүз дә әйтми, әмма барыбыз да һәркөнне сизеп, күреп торабыз: әти беләң абыйның гына жире бар, калганнарыбыз һәммәбез дә алар икмәген кимерәбез. Буй үсә, буыннар ныгый, түгәрәкләнеп кенә үсеп килгән чак. Өздереп-өздереп ашыйсы килә. Ләкин күп вакыт, табында икмәк азая төшкәч, аңа сузылырга батырчылык итмичә, күзеңне мөлдерәтеп кенә каласың.

Әле мин генәме! Мин кечкенәрәк кеше, апай да шундый ук кыенлыкны кичерә бит. Эшнең иң авыры әни белән апай өстендә. Арыш белән сабан ашлыгын уру, чүп утау, киндер, житен йолку, бәрәңге алу, киндер чылату, ашлык сугу, терлек карау, җеп эрләү, киндер сугу, су китерү, мунча ягу, утын ташу, өйне җылытып, җыештырып тору — тагын әлләниләр, әллә ниләр! Әмма аларның да жире юк. Әнә моны берәү дә аның исенә төшермәсен, әнә ул минем шикелле оялчан да булмасын. Әмма кайвакытларда табын уртасындагы икмәккә ул да кыяр-кыймас кына сузыла, вак-вак кына кабып, ничектер, бүтәннәр өлешенә кергән сыман, оялып, кыенсынып кына ашый иде.

Болай тырмага йөри башлагач, мин апай өчен дә эшлим була бит инде. Мин, аны тынычландырасым килеп, аңа әйтергә ниндидер ягымлы сүзләр дә эзли башладым.

## II

Әни, капканы ачып, игеннәргә уңыш, безгә жиңел аяк, хәерле юл теләгәндә әтинең чырае караңгы түгел иде.

— Шулай булсын! — диде.

Хәер, иртәсе дә караңгы чырайлы эленке-салынкы түгел, бик ягымлы, бик тә ямьле булып, матурланып килә иде. Кояшка каршы түшләрен ялык-йолык китереп, келәт түбәсендә сыерчык сайрый, койма өсләрендә чыпчыклар чыркылдаша, өй түбәсеннән күгәрчен гөрләве ишетелә. Төрле йортлардан арбаларына тырмаларын, сукаларын, орлык ашлыкларын төяп, безнең шикелле сабанчылар чыгып килә.

— Әти, күкәй кемгә әлегер икән, ә?!

Орлык чыгарган көнне иң беренче булып очраган кешегә йомырка бирергә кирәк. Борынгыдан килгән гадәте шундый.

Капканы чыгуга, әти як-ягына каранды.

— Кем булсын? Әнәтерәк!

Югары очка таба карасам, аннан әлеге шул күк алашасына атланып, Гыйбаш абзый төшеп килә. Башында һаман да шул ямьшәеп беткән ак йон эшләпәсе, аякларында оек-чабата.

Әти аңа тубалдан ике йомырка алып сузды:

— Гыйбадулла! Гел мач кына килеп тора да инде үзеңә! Чәчү йомыркасы сиңа эләкте бит! Әллә югыйсәм, исеннән сизәсеңме син? Ә?!

Гыйбаш абзый борыны белән генә көлеп куйды.

— Һы, һы, һы. Бәхетле... нинең борыны очында бер ашарлык ризыгы йөрер, ди. Шуның шикелле...

Шундук, мыш-мыш килеп, йомырканы ашарга да тотынды.

Жир өстенә барып житкәч, әти, уртага кереп, бер йомарлам туфрак казып алды да аның җылылыгын чамаларга кереште. Ул аны әле бер кулында, әле икенчесендә кысып карады. Аннары, жиңен сызганып, беләгенә куйды, борынына якын китереп иснәп алды. Ул туфракны шундый иплән, күзләрен йома төшеп, шундый ихлас күңел белән тәмле итеп иснәде, аның бераз жылымсарак төче исе хәтта минем борыныма да килеп кергәндәй тойдым. Әмма әти һаман да канәгать түгел кебек иде. Миңа ул як-ягына каранды. Нинди нияте барын шунда ук абайладым. Бүтән елларны ул жирнең чәчәрлек булып жылынганмы,

түгелме икәнлеген җиргә утырып карап чамалый торган иде. Әмма бу юлы якын тирәдә кешеләр күп булганлыктан, алай итәргә кыймады булса кирәк. Җир өстенә чүгәләгән килеш, кулындагы туфракны бер болай, бер тегеләй күтәреп, «бүреге белән» киңәшергә тотынды. (Аның өчен мин әллә бар, әллә юк.)

— Һм, җылы төшеп җитмәгән шул... — дип сузды авыз эченнән. — Бүген үк чәчкәндә тишелә алмыйча сөтләнеп ятмагае, бозылып. Ярый ла җылытып җибәрсә! Чәчми торсаң, соңгарак калуы бар... Бишектәге бала инде. Җылы кирәк, җылы!.. — Шулай байтак икеләнеп утырганнан соң, шактый ук күтәрелеп җылыта башлаган кояшка күз салды, күрше-тирәдәге чәчүчеләргә карап алды да аягүрә басты. — Аллага тапшырдык!

Тубалга бодай тутырды да, аның өстенә әни пешереп җибәргән дистәдән артык йомырканы салды. Тубалны муенына асканнан соң, җир башына барып баскач, йөзен төрле якларга боргалап, җилнең кайсы яктан исүен чамалап торды.

Минемчә, һава тып-тын, җил бөтенләй юк шикелле иде. Биткә дә бәрелми, атның ял-койрыгы да, юл кырыендагы әремнәр дә селкенми. Әмма әти кулын көньякка таба күтәреп торганда нидер чамалады, күрәсең.

— Алай икән, — диде. Авызын кыймылдатыр-кыймылдатмас кына бисмилласын әйтеп беренче адымын атлады.

— Хәере белән. Ярабби, бала-чага, терлек-туар бәхетенә... — дип пышылдады.

Бер уч сипкән саен, орлык чажылдап тубалга бәрелә дә чәчрәп китеп җир өстенә сибелә. Селтәнгән саен туфракка бер-ике йомырка барып төшә. Борынгыдан калган йоласы шундый: беренче көнне орлык белән бергә күкәй дә чәчәргә кирәк. Шулай итсәң, игеннәр уңышлы була, бөртекләре шушы йомырка шикелле эре була, имеш. Бабайлар шулай әйтеп калдырган...

Әмма йомырка дүрт-биш селтәнүдән артмады. Алар туфрак өстендә чит-ят нәрсә булып, тегендә дә монда агарып күренәләр иде. Әти, чәчүеннән туктап, аларга кызгангансыман карап торды да миңа баш какты.

— Җыеп ал!

Аргы баштан менгәндә әтинең яңадан чырае бозылып өлгергән иде. Ул, сукрана-сукрана, адымлап җир башын үлчәргә тотынды.

— Нәләш, нәләш! Ай бу ач күзне! Ай бу туймас күзне!

Шул вакыт күрше өлешкә малае белән Галимҗан абзый килеп туктады. Гадәттәгечә «алла куәт бирсен»не әйткәннән соң, җир башына карый-карый мескен бүреген салып, шуның тышкы ягы белән тирләгән башын сөртергә кереште. Аның аты да җирән, малае белән үзе дә кызгылт-сары башлы иделәр. Бактың исә, Сарник дип йөртүләре дә шуннан килеп чыккандыр әле.

Әти аның үзенә дә, малаена да икешәр йомырка сузды.

— Аша, Галимҗан, аша! — диде. — Йоласы шулай. Орлык чыккан көн. Тик кеше хакына кермә, гадел бул!

Галимҗан абзый, сөртенүеннән туктап, авызын ачып калды:

— Син әллә нәстә әйтәсең түгелме, Бәшир абзый... Берүк, аллам сакласын. Булмаганны!

Әти, аның сүзенә игътибар итмәстән, кулын артына куйган килеш, күршесенең күзенә туп-туры карап, дәвам иттерде:

— Аллаң сакламаган шул менә, Галимҗан! Беләмсең, иң изге ниярсә дөньяда? Гаделлек! Үл, кырыл, утка ян, тик гадел бул! Гадел бул,

туганкай! Югыйсә бит, син минекен йолкы, ди, мин синекен. Аннан кемгә ни файда? Кайсыбызның арт ягына... кояш чыга?

— Туктале, кем, Бәшир абзый, әйтеп сөйләш: нәстә булган?

— Минә, ниярсә булган!

Әти Галимҗанның җир башыннан киерелеп-киерелеп житез генә адымлап китте.

— Минә карап тор! Синеке унсигез адыммы? Әле ике чабата иңлеге артыгы да бар. Инде минә безнең җирне үлчик... Унбиш, уналты ярым! Унҗидегә дә тулмый. Кая киткән моның адым ярымы? Синең комсызлыгың бу, Галимҗан! Югыйсә бит, икебезнең дә җир бертигез булырга тиеш!

— Соң бит, Бәшир абзый, адымның нинди булмый, дигәндәй...

— Алып батыр адымы түгел, кеше адымы. Ниярсәгә хәрәмлисең, Галимҗан, нишләп кеше хакына керәсең?

— Ялгыш кынадыр ул, Бәшир абзый, хаталык белән генәдер. Минә бу җирән шайтан ызан сызганда синең җиргә таба каергандыр...

Әтинең ачуы торган саен күперә бара, аның саен күзләре усалрак карый. Ул катырак кычкыра башлады.

— Һай, Галимҗан, һай бу килде-китте лыкылдаучы телне! Соң алай булгач, ул җирән шайтаның ник ичмасам бер генә тапкыр булса да ялгышмаган! Ничек ул синең үз жиреңнән берәр адым каермаган?!

— Исләрең китмәле инде, күрше, шаклар катмалы.

— Юк, Галимҗан, син исең-һушың китмичә, ир кеше булып, чын дөресен генә әйт әле! Нишләп син Бурсык юлында ике адым, Бөйдә буенда адым ярым минем җирдән ярып алдың?

Сарник йомырканың кабыкларын бармаклары арасында чытырдатып ватып читкә ыргытты.

— Әйтәм, Бәшир абзый, билләһи минә ихлас күңелдән, тәүбә итеп әйтәм. Күңел дөреслеккә бик дөрес минем, бик! Күңелгә, ичмасам, тузан кадәр дә үпкә юк! Җир башына килеп житкәч, күңел әйтә: кеше өлешенә кермә, Галимҗан, яхшы түгел, язык була, ди. Ә кул дигәнең, каһәр суккыры, тарта да төшерә алашаны читкәрәк. Күңел җир буена сызланып бора, «һай, дөрес булмады бу, Галимҗан, язык инде бу, кеше хакына керелде ләбаса, тукта син, икенче әйләнмә», ди. — Сарник шап иттереп күкрәгенә сугып куйды. — Юк бит, әйтә торып тыңламый нәфес! Тыңламый! Тагын читкә тарта алашаны! Икенче әйләнүдә тагын бер тирән иңлеге каерып аласың! Аптыраш минә шуңа, Бәшир абзый, прәме кешедән оят!

Әти, коңгырт мыекларын сыпырган булып, тубалына иелде. Мин аны көлемсерәгән сыман күрдем.

— Күңелең эшеме, кулың эшеме, анысын үзең төпченерсең, Галимҗан. Минем җиремне кире үземә кисеп бир!

— Чәчелгән булса дамы?

— Шулай, орлыгың кергән булса да! — Әти, тубалын алып, яңадан җир башына барып басты. — Әгәр кулың монысында да күңелеңне тыңламый икән, анда инде үпкәләштән булмасын! Иген өлгергәч, өч җирдән бер арба ашлыгыңны төйим дә китәм. Минә шулай, Галимҗан күрше!

Әти шулай диде дә тубалын асып чәчәргә тотынды.

Мин тырмаларга тотынганда, Сарник, җир башларын үлчәштереп, арлы да бирле сугылгалап йөрде дә, эшкә тотына алмыйча, кире авылга кайтып китте.

## III

Әти алдан чәчеп бара, бер уч сипкән саен «черт» тә «черт» килеп орлык як-якка чәчри дә шыбырдап туфрак өстенә сибелә. Мин әти артыннан тырмалап барам. Әлеге шул бер күзе «өшегән» кара бия,

башын чайкый-чайкый, бәкәленнән дымлы туфрак ерып атлый. Тимер тешле агач тырма үрле-кырлы сикерә, тырма артыннан балчык кисәкләре келтер-келтер сөйләшеп калалар. Берничә адым гына арткарак калып, кортлар чүпли-чүпли, бик зур эш кыргандай түшләрен киереп каргалар бара.

Ындыр артыннан Ышна елгасына кадәр бөтен тирә-як сабанчылар белән тулган. Кайсы сукалап маташа, кайсы тырмалый. Төрле якта сабаннар челтери, ара-тирә атлар пошкырып куя. Әле унда, әле сулда бары сабан чәчкәндә генә әйтелә торган үзенә бертөрле ат куу, ачуланү, орышу, сызгыру тавышлары ишетелеп тора.

Сука белән җир ертучы агайлар тагын да үзләренчәрәк. Бераз гына читкә тайпылдымы, илереп атларына җикеренәләр:

— Ябагай, үләт себергере!

Минем шикелле тырмачы малайлар, атлары да җәһәтрәк атласын, күнеллерәк тә булсын дип, бераз барган саен я кычкырып, я сызгырып җибәрәләр.

Мине иң кызыктырганы яшь колыннар иде. Алар, аналары җир башыннан борылып киткәндә, башларын иеп йокымсырап калалар. Бераздан, аналары ерагая төшкәч, «Нишләп мине калдырып китәсең?» дигән сыман, упкәләп кешни-кешни, шөлдерләрен чыңлатып, аналары артыннан чабарга тотыналар. Мин үзебезнең теге, базардан әйләнеп кайтмаган җирән колынны күз алдына китерергә тырыштым. Хәзер инди булыр иде икән инде ул?..

Урман яшелләнеп житмәгән әле. Аңа күгелҗем-яшькелт төс кергән. Тик каен күбрәк булган урыннар гына бераз яшелләнеп килә. Тавышлар тынып торган арада ул яктан, тонык кына булып, күкеләр кычкырганы ишетелә. Әһә! Менә, су коена башларга да ярый икән инде.

Шушы йөз төрле авазның һәммәсенең өстендә сабанның сайрар кошы — тургайлар тавышы яңгырый. Тургай моңы күктән шулкадәр мул булып коела, әйтерсең, һәр агайның җире өстендә бер тургай эленеп тора. Алар кояшның яктылыгына, көннең җылылыгына да куаналар. Менә бу кешеләрнең шулай тырышып-тырышып җир сөреп ятулары да аларның күнелен күтәрә кебек.

Язның менә шушы барлык авазларын тыңлап йөрү бик тә рәхәт иде. Әмма шунда җир башыннан этинең усал тавышы ишетелде:

— Нәрсә син анда аяк өсте йоклап барасың?! Ку атыңны!

Мин шундук аякларымның талчыгуын тоя башладым. Җитмәсә, чабаталар эченә күп булып туфрак тулган. Ул да түгел, өздереп ашыйсы килә башлады.

Шунда тагын этн кычкырды:

— Кемгә әйтәләр! Кая кереп барасың?

Карасам, әлеге теге юньсез кара бия! Минем күз урманда, аның күзе миндә. Кырын-кырын атлый торгач, чыга да китә эздән. Дилбегәне болгый-болгый кычкырып җибәрдем:

— На, на! Менә салырмын берне сырт буйлап!

Эти, тырмалауны минем үземә генә тапшырып, икенче җиргә китеп барды.

— Төшкә тикле өч катлап бетерергә кирәк! — диде.

Хәзер инде җир башыннан узучыларның һәммәсе дә миңа дәшеп китәләр:

— Алла куәт бирсен! — диләр.

Минем дә үземне хәзер олы сымаграк тотасым килә. Тырма артыннан атлый биреп:

— Исән бул! — дип узам.

Зуррак малайлар минем олыларча киенеп, алдыма киндер алъяпкыч ябып чыгуыма, ат артыннан дилбегә каккалап, сызгыргалап ба-

руыма елмаебрак узалар. Кайбер усалраклары, синең атына таба кулы белән күрсәтеп, нидер булган кыяфәт белән бик каты кычкырырга тотына.

— Төште, төшеп калды, тот тизрәк, тот!

Шуңа алданып атыңны туктатсаң, житмәсә, тагын:

— Нәрсә, нәрсә? — дип сорасаң, бөтен басуга көлкегә каласың. Ник дисәң, алар шундук авызларын ерып көлә башлыйлар.

— Ябалак, байгыш! Күрмисеңмени? Кара бияңнең тизәге! — дип кычкыралар.

Бераздан әтинең килүен күргәч, мин атны тагын да кычкырыбрак куарга тотындым.

— Әти, әнә кайта башладылар, — дидем.

— Ярар...

Ләкин ул кулын артына куйды да ызан буйлап жирнең түбән башына төшеп китте. Акрын гына ул бара, аның артыннан тырмалап мин барам. Әллә күрә минем ничек тырышуымны, әллә юк.

Безнекенә башташ икенче бер өлешкә төшеп житкәч, башын чайкап, телен чартлатырга тотынды:

— Әт-тә-тә! Кем эше булды бу?

Бу жирне әле күптән түгел генә Миңзай дигән малай тырмалап киткән иде.

Әтинең иртәдән бирле ачылмаган чырае берьюлы ялтырып китте:

— Кара син малай актыгын, ә! — диде, сакал очын сыйпаштыргалап, тигез генә булып тезелеп киткән тырма эзләренә сокланган-дай, жир башында арлы-бирле йөргәли башлады. — Һе! Эшен китергән бу, юеш борын! Мамык иткән бу жирне! Кара син, ә, ник бер генә кисәкле балчык калсын! Менә уңа да уңа инде монда иген!.. Тәгаен!

Миңзай жире бер башыннан икенче башына кадәр бик тигез итеп пөхтәләп, тарак белән тарап чыкканга охшый иде. Жир өстендә ник бер генә ат эзе, я аяк эзе калсын!

Мин тиз генә үз жиремә борылып карадым. Шунда миңа бик тә күңелсез булып китте. Жир өстендә ат башы тикле кантарлар турсаеп тора. Тырма бөтенләй сәлам бирмичә чи калдырып узган урыннар да бар. Менә тамаша! Ничек күренмичә калганнар диген син!

Әти Миңзайны һаман мактый да мактый:

— Менә бу эш тек эш инде! Тырма эзләрен буйдан-буйга ничек кенә тездергән! Бур жебе белән сызганмыни!

Жир башын кара син, жир башын! Машина белән чикмән якасы каеган шикелле! Шундый да матур иттергән, юеш танау!

Мин тырмалаган жир торган саен сөйкемсезрәк булып күренә башлады. Минем хәзер үз жиремә карыйсым да килми иде. Шушы кара шайтан аркасында гына инде бу! Ул йөрде өшегән күзен акайтып, тегендә дә монда боргаланып!

Әмма никадәр генә атка сылтасам да, күңелнең бер төше үземнең дә гаеп барлыгын сиздереп тора. Көнчелек тә кытыклый башлады. Сүзем сүз! Барыбер Миңзайныкы шикелле итеп тырмалап куям! Барыбер!

Төштән соң шулай тырмаладым да.

Дөрес, әти минем эшне алай ук үтереп мактамады. Аның жир башыннан мыек астыннан гына елмаеп узуы да миңа бик житкән иде.

Ул көнне кич йокларга яткач күз алдында алай да, болай да килеп, гел тырмалаган жир әйләнеп торды. Тырма үрле-кырлы сикерә, тырма артыннан, келтер дә келтер килеп, очсыз-кырыйсыз вак балчык тасмасы, тип-тигез тырма эзләре агыла.

# Әлиф, би, ти, си...

## I

Бер көнне иртә белән өч тиен сәдака, бер утын алып, янга китапбукчамны асып, «гыйлем эстәргә» киттем.

Мәзин өендәге шау-гөр урамга ук ишетелеп тора иде. Түбән өйнең эче тулы бала-чага. Һәммәсе дә минем шикелле җиде-сигез яшьлекләр. Малае-кызы һәммәсе бергә тау шуып, боз өстендә кәшәтаяк[1] уйнап, җәен-көзен су буйларында, болыннарда, кырларда бозаулар, казлар көтеп, кайчакларны аерылмаслык дус булып, вакыты белән дөмбәсләшеп, бергә аунап үскән балалар. Хәзер аларның күбесенең кулында «Иман шарты», икенче ел укучы кызлар калынрак китап — «Һәфтияк» тотканнар. Байтагысы йөзлек буена, анда сыймаганнары ян сәкегә тыгыз булып тезелешеп утырганнар да, ара-тирә китапларына карап алып, берсеннән-берсе уздырырга тырышкандай, кычкыра-кычкыра сабакларын кабатлыйлар.

Мин килеп керүгә, бер генә сулышка тынып калдылар. Кайсыларыдыр борынын тартып куйды. Кайсыдыр:

— Яңа малай! — дип кычкырды.

Кыз балалар әле миңа, әле Миңнисага күзләрен елтыратып, берберсенең колагына пелделәр, кылчыкланып, чырык-чырык килделәр. Миннисa, гүя янтавына энә кадагандай, «дерт» иттереп тәрәзәгә таба борылды. Минем дә исем китмәде. Үз эшем үземә җиткән, бер җаным бизгәннән соң һич күрәсем килеп тормый иде әле.

Утынны аралыкка куеп, ишек янындарак бер урынга барып утырдым да югары өйдән абыстай төшкәнне көтә башладым.

Күп тә узмады, балалар, мине онытып, янадан шауларга тотындылар. Ничектер, үзеннән-үзе, һич күрәсем килмәсә дә, Миңнисага карап алдым. Ул терсәге белән тәрәзәгә таянган да сабагын ятлаган була. Әмма кара күзләре китап өстеннән миңа карап елтырый. Ул да түгел, мине бөтенләй күрмәгәнгә салышып, янындагы бер кечкенә кызга кычкыра-кычкыра сабагын өйрәтергә тотынды:

— Менә кара: монысы утыртып куйган казык төсле туп-туры тора. Менә шушысы үзе генә була әлиф. Шул казыкның башына кош кунган шикелләме?

Һи, мактанчык. Бик исем китә. Андыйларны гына мин үзем дә беләм инде. Киндер букчадан өр-яңа «Иман шарты»н чыгарып, аның беренче битендәге бакчаларны, айлы манараларны карап утыра башладым. Ләкин никадәр генә тыңламаска тырышсам да, кырык тавыш арасыннан миңа аның тавышы гына ишетелә иде.

— Әлиф артындагысы нәрсә төслерәк? Аш табагы шикеллерәк. Анысы була би...

Теге бала, борынын тарта-тарта, бармак очы белән борчак тәгәрәткәндәй, хәрефне арлы-бирле өтәләргә тотына:

— Би...

Миннисага карамас өчен, Фатыйма түти төшәчәк баскычларны санарга тотындым. Бер, ике, өч, дүрт... Ул һаман төшмәде. Шуннан соң мин баскычларны югарыдан түбәнгә таба саный башладым. Бик озак көтә торгач, баскыч өстеннән башта читек башы күренде, аннары күлмәк итәкләре, аннары Фатыйма түти үзе. Озын буйлы, озынча ак йөзле, төз гәүдәле, дүрт-биш бала үстергән бер абыстай.

Түргә узганда мине дә күреп алды.

— Ә, яңа шәкерт килгән икән, — диде.

[1] Хәзергечә хоккей була.

Сәке өстенә менеп, аягын бөкләп утырганнан соң, үз янына дәште. Минем өр-яңа китабымнан беренче биттәге беренче тыныш арасын күрсәтте.

— Менә шунда тикле укып килерсең. Белмәсәң, апаңнан сора, я абыеңнан...

«Дәрес бирү» шуның белән бетеп тә куйды. Икенче көнне дә, өченче көнне дә дәресне шулай ук ала идек.

«Иман шарты»ннан башлыйсың да «Ясин»ны ятларга тотынасың. Аннары «Һәфтияк»кә төшәсең. Нилэр генә тутырылмый шәкерт башына! Күзләреңне чытырдатып йомасың да, бүтән малайларның акыруларын ишетмәс өчен, колакларыңа бармакларың тыгып, ятларга тотынасың:

— ...Аллаһетәгалә бардыр, бердер, җирдә дә дәгелдер, күктә дә дәгелдер, аста да, өстә дә, унда да, сулда да, артта да, алда да дәгелдер, үзе хактыр, мәңгедер...

Аллаһетәгаләнең кайдалыгын ничек кенә булса да чамалыйсым килеп башта түшәмгә, аннан идәнгә, уңга, сулга, алга, артка карадым. Зерә дә мәзәк! «Дәгелдер!» Тегендә дә, монда да дәгелдер. Бар җирдә дә «дәгел» булгач, айсам кайда була соң ул?..

Әллә нинди ятышмаган сәер сүзләр такылдап утыруым үземә үк көлке тоелды да көлеп җибәрдем. Фатыйма түти күзен чылт-чылт йомып, миңа карап тора икән. Кинэт ачуланып китабымны тартып алды:

— Моны укыганда алай көлмиләр! Язык була! Һе, тапкан көләр нәрсә! Әнә язган бит! Тагын сиңа ни кирәк?..

Мин күзләремне чытырдатып йомдым да чайкала-чайкала яңадан кабатларга тотындым.

— ... бардыр, бердер, җамигъ җәһәттән мөнәззәһтер...

## II

Беркөнне шау-шу кызып кына житкән бер вакытта, безнең янга Фатыйма түтинең кызы Маһибәдәр апай килеп төште. Күкрәк астыннан кулларын кушырып, идән уртасына басты да:

— Оланнар, җан кисәкләрем! — диде. — Тагын да шәбрәк кычкыра алмыйсызмы? Әле минем башларыма да капмады, колагым да саңгырауланмады. Акырыгыз, оланнар, ярыймы? Ныграк кычкырыгыз!

Без нишләргә белмичә туктап калдык. Әллә чынлап әйтә, әллә үчекли. Аның йокысы туймаганга охшый иде. Чәче чуалып, күзләре, кашлары өстенә таралган. Аягында да киез ката гына. Ул караңгы почмакка таба борылды да ап-ак кулы белән авызын каплый төшеп, күзләрен бөтенләй йомып бетереп, башта озак итеп искәнде, аннан соң терсәкләрен як-якка тырпайтып бик тәмле итеп киерелеп алды. Яулыгын артка чөйде, беләзекләрен салып тәрәзә төбенә куйды, шуннан соң ашыкмыйча гына почмактагы ләгән өстендә юынырга тотынды.

Мин аның бит юуын рәхәтләнеп карап утыра торган булдым. Безнең авыл кызлары арасында ул болай да буйга-сынга да, төскә-биткә дә иң чибәр кызлардан иде. Менә хәзер якыннан күргәч, тагын да сокландыра төште. Ничек аның беләкләре шулкадәр ап-ак, шулкадәр матур икән? Битен юганда аның нәни генә колак яфрагында фирәзә кашлы алкасы селкенә, ап-ак сабын күбегенә уралган куллары битләрен тегеләй дә, болай да сыйпап, иркәләргә тотыналар. Ул комганның суы беткәнче, пошкыра-пошкыра, озак итеп юына. Юынган саен бите тагын да алсулана, тагын да матурлана бара кебек иде.

Мәзин дә, аның остабикәсе дә мәҗлескә-мазарга киткән көнне безне Маһибәдәр укыта иде.

Ул һәйбәт сабын исләре килеп торган матур кулларын, берсе өстенә икенчесен куеп, йөзлек буенда бераз гына тыңлап утыра да кузгалып китә.

— Житте! Бүтәннәрегез иртәгә тыңлатырсыз. Әйдәгез!

Без, бөтен өеребез белән, аның артыннан ишек алдына атылабыз. Кызлар мал-туар астыннан җыеп салам көлтәләргә тотына, малайларның кайсы кар көри, кайсы терлек астын тазарта. Маһибәдәр биленә таянып карап тора да ап-ак тешләрен күрсәтеп көлеп җибәрә:

— Кара нинди уңган балалар икәнсез! Менә монысы эш дисәң дә эш, ичмасам. Барыгыз, тизрәк таегыз. Минем эшләрем бар.

Кадимчә уку вакытыннан тагын кайбер нәрсәләр истә калган икән әле.

Язның бик матур бер кояшлы көне иде. Мин сабакка барырга чыккач, үзем дә белешмәстән, нәкъ безнең турыда гына уйнап йөрүче иптәш малайларга кушылдым. Башта без чылтыр да чылтыр китереп, төнге суыкта ат эзләренә каткан пыяладай юка бозларны ватып йөрдек. Аннары яз кояшы коймa буйларындагы карны челтәрләп ясаган матур куышларга сокландык. Стеналары, юка пыяладан койган кәрәз төсле, челтәр-челтәр. Бер карыйсың, ул челтәрләрдә алсу очкыннар уйный, икенче карыйсың, я зәңгәр, я бишни булып күренә. Аннары батыргычлар ясадык. Ул да түгел, чана эзләреннән челтерәп аккан яшькелт-сары карлы-бозлы гөрләвекләргә күз төште. Тиз генә кереп уенчык су тегермәнен алып чыктым. Гөрләвеккә көйләп куюым булды, әй китте әйләнеп, чарыкларына күз дә иярми. Сабагы да онытылды, мәзин үзе дә. Мин генәмени!? Бөтен урам өсте, кояшның үзе шикелле киң күңеллелек белән елмаеп, шаулап-гөрләп тора. Егетләр, кызлар ялан өс чыгып урамның бер ягыннан икенче ягына кар туплары атышалар. Барыбыз да шат, куанычның иге дә, чиге дә юк.

Уйный торгач, күтәрелеп карасам, каршымда дәү гәүдәсе белән эти басып тора.

— Аһ, дуңгыз малай! Сабагың нишли, ә?! — ди бу.

Букчаны эләктереп, мәзиннәргә йөгерсәм, сабак беткән, балалар әллә кайчан өйләренә таралганнар.

Кире борылырга дип кенә торганда, югары өй баскычыннан башта Гайнетдин абзыйның яшел үкчәле кыршылган читеге, аннары очлы сакалы килеп төште.

— Әәә, уйнап туйгач монда да сугылып чыгасы иттеңме? — диде ул. — Шулаймы? Кая әле!

Ул башта, мондый эшкә күптән үк күнеккән оста бармаклары белән, бик тырышып, тәмам җиренә җиткереп, колагымны борды. Аннан соң идән астына төртеп төшерде.

Идән астында бик караңгы, бик тынчу иде. Җылыйсы да килде. Шулай да җыламадым. Ничектер мәзингә дә ачу тотмадым. Үзем гаепле. Бая урамда гөрләвекләр янында уйнап йөрү рәхәте өчен мондый гына җәзага түзәргә кирәк булгандыр.

Озакламыйча безнең уку бүлмәсенә бозаулар, көтүе белән сарык бәрәннәре кереп тулды. Алар минем баш өстемдә сикерешә, тыпырдый, сөзешә башладылар. Анысына да исем китмәде. Тик бу ябылу бик озакка сузылгач кына кыбырсый башладым. Шулай озак утыртсалар, мин моннан котылганчы кояш сүреләчәк, гөрләвекләр акмый башлаячак бит!

Ул шулай булды да. Мин урамга чыкканда гөрләвекләрнең өсте чирап юка боз белән капланган иде.

Капкадан атылып чыксам, аз гына Миннисага бәрелми калдым. Ул, аягы белән бозга типкәләгән булып, баганага сөялеп тора. Миңа яңы белән генә торып, көмеш кәгазьгә төрелгән бер нәрсә сузды.

— Мә!

Мин кулымны суза башлагач, кире алдым.

...Бакчада алма өлгергән вакыт иде. Миңниса иптәш кызы белән байтак вакыт безнең койма буенда әйләнгәләсәләр дә, мин алар янына чыга алмадым. Әти миңа эш кушкан иде. Бераздан әти өйгә кереп киткәч, мин аларның икесенә ике алма чыгарып бирдем. Миңниса мин биргән алманы, ачылыгына йөзен чыта-чыта, шундук ашый да башлады. Аның иптәш кызы алмасын күлмәк итәге белән сөртеп ялтыратты да аны әле бер битенә, әле икенчесенә тидерде. Балалар беркатлылыгы белән, башын чайкый-чайкый куанырга, кызыктырырга тотынды:

— Әләли, әләли, минем алмам нинди матур! Мин өйгә алып кайтам! Әнигә күрсәтәм!

Миңниса аның алдында сикергәләде дә:

— Кая әле? — дип, иптәш кызының алмасын тешләп тә алды. — Әһә! Сиңа тәмлесен биргән икән. Баллысын. Мә, әчесен ашап кара! — диде, үз алмасының калдыгын иптәш кызына сузды. Кызый аны алмады, елый-елый Миңнисаның иненә ябышты. Миңниса иптәш кызының әченә типте. Аны акырып елаган хәлдә урамда калдырып, үзе өйләренә йөгерде.

Мин теге кызыйга бөтен алма чыгарып бирдем. Ул, күзләрен сөртәсөртә, акрын гына китеп тә барды. Әмма Миңнисаның бу явызлыгын һич оныта алмадым.

...Менә хәзер карасам, күмеш кәгазь эченнән хат башына чәчәкләр ясый торган кызыллы-зәңгәрле матур карандаш күренеп тора. Миңниса, минем икеләнүемне ошатмыйча, түземсезләнеп, карандашны тагын сузды:

— Мә инде!

Минем андый карандашым юк, малайларда күреп андыйга әллә кайчаннан бирле кызыгып йөри идем. Шулай да алырга кулым бармады.

— Юк! Кирәк түгел! Үзеңә булсын!

Миңнисаның йөзе кинәт бозылып китте, күзләре елтырап мине тишеп алырдай усал итеп карадылар.

— Һи, шадра пәри! — диде. — Алмасаң, тәтеми дә әле! Менә, мә!

Ул миңа телен чыгарып күрсәтте дә тыкрыкка таба йөгерергә тотынды. Мин аның артыннан җитеп, иңбашыннан эләктереп алуга, Миңниса шундый әшәке итеп чәрелдәде, андый тавышны ишетмәс өчен, әллә кайларга качарсың.

Шуннан соң без Миңниса белән очрашканда, бер-беребезне күрмәскә тырышкандай, читкә борылып китә торган булдык.

Язгы кояшның эссесе, йомшак карлар белән бергә, безнең уку дәртен дә эретеп алып китә иде. Аз гына җир күренә башладымы, без инде, кырык сылтау табып, сабакка бармый калу ягын карыйбыз. Мин дә шулай бер көнне кайтып кердем дә китаплар букчасын шүрлеккә ыргыттым. Әни, эшеннән туктап, миңа текәлде.

— Рәхмәт әйттеңме соң?

— Кемгә?

— Менә инде, остазларыңа!

Әйтелмәгән икән шул.

Әни беркавым башын чайкап торды:

— Кыш буе тырыштылар, гыйлем булсын, колагыңа юньле сүзләр керсен, диделәр. Син шуны оныттыңмыни?

Оныткамын икән шул...

# Бәбде Бәҗвин

## I

Ул көнне әни мине көндәгедән иртәрәк уятты.

— Тор, улым! Оныттыңмыни? Бүген мәдрәсәгә барасың бит, шәкерт булдың ич инде.

Минем, үзем дә сизмәстән, йокым берьюлы ачылып, күңелем күтәрелеп китте. Шәкерт булам бит, шәкерт!

Әти «хәлфәңә сәдака бирерсең» дип бакыр акча тоттырды. Әни, хәерле юл теләп, капкага тикле озата чыкты.

Урамга чыгып тыкрыкка күзем төшүгә, шунда йөгердем. Тамаша иде анда! Аргы якның Минзай исемле малай ялан аяк кар ерып менеп килә! Аның башында колаклары салынып төшкән куян бүрек, өстендә бишмәт, ә аягы ялангач. Ул инде чөгендер төсле булган. Минзай артыннан бер төркем малай ияргән. Алар батырның бер алдына, бер артына чыгалар.

— Капкадан ук ялан аяк чыкты! — ди берсе.

— Туңамы, малай, дөресен әйт!

Минзай аңа борылып та карамый. Борынны чөйгән, кулын кесәсенә тыккан:

— Бик исем китә! Ичмасам, төкереп тә бирмим!

— Билләһи диген!

— Кит әле моннан! Салып егармын!

Малайлар шигәеп читкәрәк тайпылалар.

Ышан Минзайга! Аның кулына эләксәң! Аннары Минзай болай да бик сәер малай иде. Аның кулыннан теләсә нинди эш килә. Ул мич чыгара, гармун уйный, ватылса, аны үзе үк төзәтә дә белә. Аның лапас түбәсендә, келтер-келтер килеп, Минзай үзе ясаган кечкенә җил тегермәне ашлык тартып утыра...

Минзай мәдрәсәгә якынлашуга, андагы шау-шу кинәт тынды. Малайлар йөгерешеп аның каршысына чыктылар. Кайсы Минзайның батырлыгына сокланып телен чартлата, кычкырып җибәрә, кайберләре көләргә тотынды:

— Һа, һа, һа, чабатаңны кызганасыңмыни?

Мәдрәсәнең ишек төбенә килеп җиткәннән соң да сер бирмәде. Ул ак кар өстендә бик сәер булып бөрешеп торган кызыл аякларын кузгатып та карамыйча, әллә никадәр вакыт ишектән кермичә торды.

— Сүзем сүз! Кыш буе ялан аяк киләм. Менә күрерсез!

Мәдрәсәдә укуы күңеллерәк иде. Монда инде без коръән сүзләрен ятлаудан тыш, җәгърафия дә укыдык. Беренче елны ук укырга-язарга, дүрт гамәлдән кайсы саннарга кадәрдер хисап эшләргә өйрәнә башладык.

Дөрес, ул хисап дигәннәре кызык кына укытыла иде. Хәлфәбез Зәбихулла абый, үзе кадим мәдрәсәсендә укыган кеше булганлыктан, яңача укытуны белеп җиткермичә, кайчакларны кадимен-җәдитен бергә бутап та башны әйләндергәләде. Менә дәрес башланганда хәлфә абый үзебез белән йөртелә торган кечкенә кара такталарны, грифель карандашларны хәзерләргә куша. Аннары ул, тәрәзә тирәсендә арлыбирле йөреп, чыгарасы гамәлләрне әйтә башлый. Без, кара тактаны тезгә куеп, язарга тотынабыз.

— Әүвәл башта алдым фәләнчә баш куян тиресе, дип язасың. Берсе фәләнчә тиеннән бәһасе буладыр фәләнчә. Янә алдым фәләнчә баш сыгыр тиресе...

Зәбихулла абый безнең кара тактага күз салгалап әйләнә дә алга басып сорау бирә:

— Җәмгысе күпме була?

Шушы куян тиресе белән сыгыр тиресенең байтакка кадәр башларын әйләндердек. Алар, эт эчәгесе шикелле, хисапның һәр гамәле саен диярлек һаман иярәп йөрделәр. Сыгыр дигәннәре дә үзебезнең абзар тәрәзәсеннән башын сузып ашарына сорап мөгерәп торучы, әлеге шул гап-гади сыерларыбыз инде, югыйсә. Ләкин ул вакытта халык сөйләгәнчә генә язу килешмәгән, күрәсең, фәнчә булмаган. Шунлыктан без аны, әллә кайчаннан ук килгән гадәт буенча, үзенә күрә бераз сырландырып, «мөгез» чыгарып, сыгыр дип, барысы дип кенә язасы урынга «җәмгысе» дип язарга тиеш идек.

Әмма минем иң яратканым туган тел белән җәгърафия булып чыкты.

Менә бер көнне Зәбихулла абый, Арча базарыннан кайткач, түр стенага чиккән ашъяулык төслерәк яшелле-зәңгәрле матур кәгазьләр элеп куйды. Бөтен бүлмә ничектер берьюлы ямьләнеп китте. Без тәнәфес вакытына кадәр көч-хәл белән генә түзеп, аларның эре хәрефләрен укырга тотындык. Берсенә Аурупа харитасы[1], икенчесенә Асия[2] харитасы дип язылган иде.

Шул көннән башлап бу карталар минем өчен иң кызыклы, иң мавыктыргыч нәрсәгә әверелделәр. Нинди искиткеч яңалыклар, нинди серләр генә ачмады бала күңелендә ул яшелле-зәңгәрле матур карталар!

Ул вакытта безнең өчен җир яссы иде әле. Хәтта җирнең читенә барып җитеп, кырыенда аягын салындырып утыручылар турында да ишетергә туры килгәләде. Әйе, җир яссы икән, аны кит балыгы күтәреп тора икән. Юк, алай түгел икән, җир үгез мөгезендә эленеп тора икән. Менә бит нинди тамаша!..

Әгәр үгезне кигәвен-мазар тешләсә? Шунда ул, безнең авыл үгезләре кебек, койрыгын чәнчеп, үкерә-үкерә җир тырнарга тотынса, аннан да хәтәррәге — ятып ауный башласа? Кыскасы, ул турыда бөтенләй уйламау яхшырак иде...

Менә шушы җир безнең күз алдына беренче мәртәбә шар формасында булып килеп басты. Ул үзе искиткеч зур да, аның өсте гаҗәеп дәрәҗәдә төрле-төрле дә, урыны белән бик бай да, ярлы да икән. Адәм баласы аның өстенә меңнәрчә шәһәрләр салган, авыллар булып утырган, тимер юллар сузган.

Үз авылында, тәрәзәләре бозланып каткан кечерәк кенә тәбәнәк өйдә утырган килеш әллә кайлардагы ят җирләр белән, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән әкияттәгедәй тылсымлы яңа иләр белән, ниндидер аңлашылмый торган телләрдә сөйләшүче ят халыклар белән танышу безнең өчен искиткеч, мавыктыргыч яңалык булды. Моңарчы дөнья, җир йөзе ничек күз алдына килә иде? Менә безнең авыл, аннары бүтән авыллар тезелеп киткән. Гел авыл да авыл, шәһәре дә зур авыл булып күз алдына килә. Аның аргы ягында да, бирге ягында да шулай бик ерак китәсең. Әллә йөз чакрым, әллә ике йөз чакрым. Шуннан аргысын күз алдына китереп тә булмый иде.

Безгә, моңарчы үз телебездән башканы белмәгән авыл балаларына, картадагы яңа сүзләр, яңа исемнәр үзләре генә дә бик кызык та, серле кебек тә тоелды. Менә сиңа Алмания[3], Энгелтерә[4], Парис, Әлҗәзаир[5], Бәхер-Мөхит атласи[6]... Менә шул сәер сүзләрне кат-кат әйтә-

---

[1] Европа картасы.

[2] Асия — Азия.

[3] Алмания — Германия.

[4] Энгелтерә — Англия.

[5] Әлҗәзаир — утраулар, Алжир шушы сүздән бозып алынган.

[6] Бәхер-Мөхит атласи — Атлантик океан.

әйтә, зәңгәр җеп булып сузылган Иделне кичеп, Мәскәү шәһәрен, Валдай сыртларын узасың. Алда сине мавыктыргыч яңалыклар көтә. Нинди-дер Вильно, Рига, Данчиг дигән шәһәрләр аша Алманиягә, аннан Маншу[1]ны чыгып Энгелтерә иленә, аннан да узып эссе чүлләргә, сахраларга сәяхәткә чыгып китәсең. Синең алдыңда барган саен яңа илләр, яңа шәһәрләр, елгалар, күлләр ачыла бара. Һәркайсының ниндидер искиткеч ягы, сокландыргыч яки куркыныч яклары бар. Кәгазь өстендәге сары һәм бигрәк тә кызыл урыннар, башы күкләргә тигән карлы таулар булып, зәңгәр урыннар дулкынланып торган диңгезләр булып җанлана. Шушы исемнәргә элегрәк укыган китаплардан истә калган төрле кызык һәм гыйбрәтле вакыйгалар өстәлеп китә. Балалык хыялы болардан ниләр генә тудырмый, нинди генә мавыктыргыч вакыйга һәм күренешләр күз алдына килеп басмый! Кеше башы кадәр татлы җимешләр үстерүче диңгез уртасындагы мәңге ямь-яшел, матур утраулар. Өсләренә ефәк белән елык-елык итеп кенә торган атлас киемнәр киеп йөрүче, энҗедәй ап-ак тешле, йолдыздай үткен күзле, кызыл, я кара тәнле һиндләр, гарәпләр, кытайлар, тагын әллә кемнәр, бөтенләй башка дөнья, башка тел халыклары. Зәңгәр диңгезләрдә аккош төсле генә йөзеп баручы ап-ак корабльләр, кыя ташлар арасында шул корабльләр кереп туктый торган зәңгәр сулы аулак күрфәзләр[2]. Тутый кошлар белән маймыллар яши, арсланнар гына хөкем сөрә торган мәңге яшел калын урманнар. Хыялый бакча эчендә утырган тылсымлы сарайлар...

Ул заманда китапларның беренче битендә һәм төсле шәмаилләрдә бары тик хыялда гына яки төштә генә күренүе мөмкин булган соклангыч матур бакчалар, бай шәһәрләр, зиннәтле сарай сурәтләре бирелә торган иде. Ихтимал, география укыганда хыялны үстереп җибәрүгә әнә алар да ярдәм иткәндер.

Кайчак шулай карта өстендә илдән-илгә күчә-күчә, сәяхәтнең рәхәтенә бирелеп тәмам онытылып кына утырганда, хәлфәнең соравы яңгырый:

— Идел нәһре[3] кайсы диңгезгә коя?

Янсә:

— Энгелтерә җир шарының кайсы кыйтгасендә?..[4]

Тик күңелгә ошаган мондый дәресләрне тиз үк тормыш миннән кызганды.

## II

Укуымның өченче елында эти мине, сөеп укыган туган тел белән географиядән аерып, һич көтмәгәндә, күрше Каенсар авылының кадим мәдрәсәсенә[5] илтеп ташлады. Моңа эни дә, бөтен өй эче дә каршы иде. Кардәш-ыруларга кадәр борчылды. Нигә болай? Ни сәбәпле ун яшьлек малайны һәйбәт кенә укуыннан аерып, кеп-кечкенә бер авылның сукыр лампа шикелле генә төтәсләп утырган кадим мәдрәсәсенә илтергә? Ләкин нишлисең? Эти беркем белән дә исәпләшми иде.

Моның төп сәбәбе соңыннан гына ачылды. Эти элекке старостаны янадан сайламаска өндәгән. Ул җәмәгать җыенында аның попларга илле сумга сатылып, авыл башына чиркәү салдыруын сөйләп биргән. Ләкин мулла белән мәзин, алар тирәсендә яхшатланып, куштанланып йөрүче мөтәвәллиләр үзләре эчертеп килгән ялагайлар белән тавыш

---

[1] Маншу — Ла-Манш.
[2] Күрфәз — култык.
[3] Нәһер — елга, дәрья.
[4] Кыйтга — кисәк.
[5] Кадим мәдрәсәсе — бик искечә, фәкать дин сабагы гына укытыла торган мәктәп.

кубарганнар, яңадан шул ук бозык кешене староста итеп калдырганнар.

— Ни җаным белән шулар кулына бала бирим? — диде эти. — Малай надан калса калыр, тик мин аларга ялыначак түгел.

Әти тәкәббер кеше иде, ул үзенең дошманнарына баш имәде. Әмма моның бөтен авырлыгы минем өскә төште.

Каенсар мәдрәсәсе гади авыл мунчасыннан аз гына зуррак иде. Шуның шәп-шәрә идәнендә аркылы да, торкылы да утырган егермеләп малай. Кайсы бишмәт кигән, кайсы күлмәкчән. Без иртән яктыра башлауга килеп утырабыз да, күзләребезне түшәмгә, я стенага терәп, башкалар тавышын ишетмәс өчен колакларыбызны томалап, нигә кирәк булуларын да, нәрсә икәнлекләрен дә белмәгән китап сүзләрен ятларга тотынабыз.

Бер-ике айдан ук минем Каенсарга йөрисем килми башлады. Үзебезнең авыл мәдрәсәсендә җәгърафия белән туган тел укулар рәхәт кенә булган икән. Җомга көннәрне береннән-бере кызганыч бәетләр күчереп язу, я булмаса, карта буйлап әллә нинди чит-ят җирләргә ил гизәргә чыгып китүләр кая инде ул хәзер! Тик моны әтигә ничек әйтергә? Ничек аннан кайтырга рөхсәт алырга?..

Шуңа бер җай чыкмасмы дип, мин, җомга көн авылга кайткач, этинең верстагы тирәсендә кайнаша торган булдым.

Безнең өйгә килеп керүгә, борынга коры йомычка исе, түшәмгә киптерергә куйган чыршы, нарат такталардан сагыз исе, төрле буяу һәм замазка исе килеп бәрелә. Стенада әллә ничә төрле пычкы, өтерге, стамеска һәм эреле-ваклы бораулар тезелеп киткән. Ишек янына зәңгәрсу ак төскә буялган төрле тәрәзә рамнары эленгән. Әтинең тәрәзә буена көйләнгән верстагында көне буе бертуктаусыз кисеп, ярып, ышкылап, шомартып һәм кеҗәйләп төрле әйберләр ясавын, аларны буявын карап утыру үзе бер рәхәт. Нарат белән чыршы безнең өйгә калын такта булып керәләр, якты тәрәзә булып чыгалар, бүрәнә башы булып керәләр, такта умарта булып чыгалар... Верстак астында аунап яткан төрле-төрле шакмакларның исәбе-саны юк. Теләсәң, өй салып уйна, телисең икән, берәр уенчык яса. Тик кадакка тидереп этинең коралларын гына бозма.

Бу кайтуымда этинең аргы як Мостафага урындыклар ясаган вакыты туры килде. Аның бу эшкә бик дәртләнеп тотынуын һәммәбез дә күреп йөри идек. Урындык ясыйсы каенны ул әллә кайдагы ерак урманнан түбә җирдә үскәне, могылсызы[1] булсын дип үзе сайлап алып кайтты. Аны күләгә урында өстен каплап үз көенә елдан артык киптерде. Хәзер аның ул каены эшләгәндә коры сөяк шикелле кетердәп тора.

Урындыкның аяклары матур булып тышка таба дугайланып чыккан, аркасы, утырырга җайлы булсын дип, бөгелмәле итеп, артка таба авышрак итеп эшләнгән. Хәзер ул шушы беренче урындыгының аратасын матурлап маташа. Аның янында эреле-ваклы өтергеләр, безләр, стамескалар. Әти шул коралларның әле берсе, әле икенчесе белән аратаның өч җиренә ниндидер бизәкләр уя: уртага дәүне, баш-башларына кечерәкләрне.

Өйдәгеләрнең берсе керә, берсе чыга. Кече якның чаршавы артында ара-тирә көйсезләнеп кечкенә сеңел шыңшый. Әни күгәрчен шикелле гөрләп аны юатырга тотына. Бер мәлне, абзардагы аналарының тавышын ишетеп, идәндә сикергәләп йөргән бәтиләр кычкыра башлый. Тик әти боларның берсен дә ишетми. Ул әлеге бизәкләрне һаман кыра, түгәрәкли, матурлый.

Миңа ул аратаны ераккарак куеп карады да тузаннарын өргәләп миңа да күрсәтте:

---

[1] Могыл — чирләшкә каенның кәүсәсеннән бүлтәеп чыккан авыру урыны.

— Яле, ниярсәгә охшаган?

Әтинең күңеле күтәренке, чырае ачык булу минем өчен дә күңелле иде. Я, бәлкем, әле Каенсар турында да әйтеп булыр?

— Чәчәккә! — дидем.

— Ниндиенә?

— Кечтеки генә гөнбагыш башына да охшаган. Тик күбрәк акчәчәккә. Әнә теге теш сызлаганда кайнатып эчә торганына.

Әти авыз эченнән «мм...» ди-ди, әлеге чәчәкләрне башта пыяла чите белән кырды, аннары кытыршы кәгазь белән шомартты да бик озак, ялтыраганчы тула кисәге белән ышкыды.

Чәчәкле аратаны урынына беркетеп кенә тора иде, ишек алдында сәлам биргән тавыш ишетелде. Әти, өстенә тунын салып, кунакны каршы алырга чыгып китте.

— Бәгаләйкүм әссәлам!

Мостафа бай икән. Ул бәрән тунын чишеп кенә жибәрде дә, бүреген верстак өстенә куеп, урындыкны карарга тотынды. Башта утырып карады, аннары «дык» иттереп каты гына идәнгә куйды. Иң соңыннан баш түбән әйләндереп, аякларын югары күтәртте.

— Кайчан бетереп бирәсең? — диде.

Чәчәкләрне күрмәгәнгә әтинең ачуы килде.

— Анысы ниэшкә тагын? — диде бай. — Мин ул төшенә аркамны терәп утырам. Беләсең ич, минем артымда күзем юк.

— Син күрмәсәң, бүтәннәр күрер. Болай матуррак чыга ич. Бөтен өенә ямь биреп торыр. Унар тиен өстәсәң...

Мостафа, бармакларын бөккәләп, исәпләргә кереште.

— Биш кәррә унын — илле, янә илле дә тагын егерме.

— Нибары сум егерме тиен генә!

— Һе! Нибары! Ике пот он ич ул! Язгы бер пот көз баенда ике пот булып балалап кайта! Беләсеңме син шуны! Булмый. Кыйбатка төшә.

Ул да түгел, әти урындыкны ишек янына тотып атты. Мич буенда юкә себеркесе ашап торган бәтиләр, дәррәү кубып, почмак якка ташландылар. Мәче, пырсылдап, мич башына очты.

Тик әти урындыкны шундук кире алды да верстак өстенә бастырып, балаларны иркәләгәндәй, аның аркасын, аякларын, чәчәкле аратасын сыйпарга кереште.

— Күрмисеңме әллә! Күз өстендә кашы бит ул моның! Ә син нәрсә дисең? Әйдә, күзе булса, кашы ни пычагыма кирәк димәкче буласың! Ашны пешерүен пешер, тик тоз салмасаң да батар, дисең. Булмый шунсыз, булмый! Канатсыз кош, тавышсыз сандугач килеп чыга!

Мостафа урыныннан торып, төймәләрен элэктерергә тотынды.

— Башта нәрсә карадың? Әйтеп сөйләшәләр аны! Можыт, мин Арча осталарына кушарга исәп тотар идем.

Әтинең никадәр ачуы килсә дә, аратаны сыйпаштырганда чырае яктырып киткәли иде.

— Эшли башлагач килеп чыкты бит, үзеннән-үзе, көтмәгәндә. Баш яктырып китте дә шулай...

— Булмый! Монысы да сиңа муеннан инде. Кем эшләтә? Мостафа бай эшләтә! Даны ни тора! Эш белән күмәрләр үзеңне. Менә күрерсең!

— Поты бер тиен! Минем кем булуымны кулларым әйтә, эшләгән әйберләрем кычкырып тора! Син каян карыйсың бу якты дөньяга? Мин ясаган тәрәзәдән карыйсың! Каян керә сиңа көн яктысы?.. Менә шул шул. Барыбер әрәм итмим. Үземчә эшлим, бушлай эшлим! Муенына так ун тиенеңне!

Әти Мостафа чыгып киткәннән соң да озак сукранды.

— Карун, туңбаш, мәлесез, күзен чыкмагандыр бит күрмәскә!

Верстагындагы коралларынын берсен алып, берсен куеп озак кына эшенә тотына алмыйча азапланды да, әнигә дәште:

— Синэйтэм! Итенне мулрак сал. Бүген минем ни...
Аш өлгерер алдыннан мина Мөхәммәтжан жизнине дәшеп кайтырга кушты.

### III

— Ә, шәкерт, нихәл? — диде жизни. — Иртәгә тагын китәсеңме?
Аның тавышы бик ягымлы кебек ишетелде. Мин шундук Қаенсар турында аңарга әйтергә кирәк дип уйлап алдым.
— Барырга кирәк тә...
Жизни кызыл чуар итегенең сыңарын гына кигән килеш туктап калды.
— Шуннан?..
— Барасы килми.
— Ничек алай?
— Анда күңелсез. Жәгърафия дә укытмыйлар, туган телне дә. Гел күрми сабак[1] кына.
Жизни, башын чайкап, урыныннан ук торды.
— Менә, менә, әйтәм бит! Ул туң башларның бөтен белгәне шул — жыен кирәкмәгән чүп-чар белән баланың миен черетү! Әлисә[2] ничек була соң инде? Авылга кайтам дисеңмени?
Мин шуны гына көтәм дә бит инде!
— Дим дә... Әти кайтармас шул.
— Бабаймы? Ул да төшенмәсә, бүтәннәргә ни сан?
Мөхәммәтжан жизни әтинең беренче хатыныннан туган иң олы кызының ире: карасу-кызгылт йөзле, коңгырт күзле чандыр гына кеше. Яшьрәк чагында ул әллә кайда, бик еракларда күмер казыган. Кич утырырга килгәч, шахта төбендә ничек мүкәләп йөрүләре, кәйлә белән ничек күмер чабулары турында сөйләгәне бар. Иң кызганычы жир астында күмер ташучы атлар була иде. Алар шунда сукыраялар икән... Хәзер инде жизни авылда гына яши. Ул, аркасына такта кыстырган сыман, муенын бер якка бора алмый, читкә карыйсы булса, бөтен гәүдәсе белән борыла, йөргәндә бөгелми-сыгылмыйча үрә катып кына йөри.
Жизни муенына ике койрыклы солдат башлыгы элде.
— Я, барып карыйк әлисә.
Ул күмердән алып кайткан шахтер лампасын кабызганда мин үземне чак кына тыеп калдым. Бу кызык лампаны шул тикле үзем тотып кайтасым килде! Шулай булмыйча, ул бит нинди жилдә дә сүнми, керосины түгелми, кая бәрсәң дә ватылмый. Мондый лампа бөтен авылга бер генә, ул да безнең жизнидә генә. Жизни моны сизде, ахрысы, лампаны минем бишмәт изүенә эләктерде.
— Жир астында менә шулай түшкә элеп йөри торган идек, — диде. Минем куануыма бик рәхәтләнеп карап торды.
Урамга чыккач, мин лампаны төрле якка айкап-чайкап карадым. «Юри генә» капка баганасына бәрелдем. Ичмасам, кымшанмады да. Ул чагында мин үземне чын шахтердан бер дә ким хис итмәдем. Тик бу вакытны урамда малайлар гына юк иде.

Кояш та баеды, караңгы да төште. Мин узган ел бергә укыган шәрикләрем[3] белән күрешеп өйгә әйләнеп кайтканчы йолдызлар кәтүе бөтен күк йөзенә таралырга да өлгерде. Ә өйдә һаман шул мин чыгып киткәндәгечә. Табындагы эче бал чирәге һаман шул башланган килеш кенә тора, әти, кашларын жимереп, тәрәзәгә карап утыра. Мөхәммәт-

[1] Күрми сабак — күңелдән ятлыйсы сабак.
[2] Әлисә — алайса.
[3] Шәрик — сабакташ, бергә укыган иптәшләр.

жан жизни дә шул килгәндәге төсле үк төссез чырайлы. Тик аның куллары белән күзләре генә уйный. Ул кулларын әле верстакка куя, әле йодрыгы белән тезләренә суга.

— Менә син старостаны яратмыйсың, — ди ул. — Дөрес, әй! Ул сатлык җан, карак, кеше хакын ашаучы. Тик менә, бабай, үзең чамалыйсындырмы, юктырмы, кайчакны син дә бит аның җырын җырлыйсың!

Әтинең чырае ук бозылды.

— Булмас! — диде әти. — Синең авызың ниярсә әйткәнне колагың ишетәме? Болайга китсә, мин кунагым дип тә тормам!..

Кече яктан, бик борчылып, әни чыгып җитте.

— Карагыз әле! Бу нинди сәер бәндәләр булдыгыз әле сез! Өч-дүрт көн күрешми торсалар, сагынышалар. Бергә килделәрме, тынышалмыйлар. Син дә инде! Кунакка күсәк күтәрмәс кеше!

Жизни куллары белән ишарәләп:

— Хәзер, хәзер! — диде. — Әйтеп кенә биримче. Беләсезме, кичә староста ничек котырынды! Мәдрәсәгә кереп бөтен кеше алдында оныгының хисап дәфтәрен ерткалап ыргытты. Ник дисезме? «Сез, җәдитләр! Минем баламны нигә тәре ясарга өйрәтәсез? Аллага шөкер, мин хак мөселман», — дип акырына. Ни әйтеп карады хәлфә. «Бу бит тәре түгел, кушу галәмәте, ди. Моны урыслар гына түгел, немесләр дә, гарәпләр, төрекләр, тагын әллә кайсы мөселманнар да шулай яза». Юк, ышанмый гына бит тунбаш! Һаман шул бер кирелек инде: «Без — мөселман, дин укытыгыз, кадимчә укытыгыз»...

Әти аны ярты сүздә бүлдерде:

— Барыбер син мине староста белән бутама! Ул кем дә, мин кем, ә? Төкерә ул синең динеңә! Аңа мәчет картлары белән байлар алдында языгын юарга кирәк. Менә нигә дин дип, кадим дип кычкыра староста. Бер ай элек ул ук җәмәгать җыенында җәдитне яклап җикеренде.

Жизни, көлемсерәп, тез башына сукты.

— Икесе дә бер тиен, ике чабата бер кием...

Әти чирекләне җилтерәтеп алып икесенең дә тустаганына бал койды.

— Сине кунакка дәшкән мин җүләр! Синең белән сөйләшеп утыру үзе үк язык та бит инде, әллә нишләп куып чыгара алмыйм. Мә, эч, зимагур!

Тустаганын әйләндереп салды да кашык очына эләктереп кенә бернично бавырсак капты.

— Менә син торасың да дингә каныгасың. Дин сабагы укытма, дөнья гыйлемен өйрәт, дисең. Әйт әле, дөнья гыйлеме ни пычагыма ярый? Бу фани дөньяда безгә ни рәхәт бар? Беләсең ич, безнең татарга кая сугылсаң да юл ябык. Зур укырга алмыйлар, юньле эшкә куймыйлар. Зерәгә әрәм үтә гомерләр.

— Иске мәдрәсәдә унар-унбишәр ел чүбек чәйнәү әрәм гомер түгелмени? Аннан чыккан шәкерт нәрсәгә ярый?

— Аннан, ичмасам, гыйлем булып чыга. Намаз-нияз укырга өйрәнә. Аның, ичмаса, өмете була. Кем белә, бәлки җәннәткә эләгеп куяр?!

— Теге дөньяга хәтле бусында көн итәсе бар бит әле. Шул дин аркасында шулай надан калдык та инде без. Шуның аркасында шундый ярлы, бетәшкән.

— Туктале, зимагур, нигә дин синең шул тикле бугазыңа сөяк булып кадалды? Әллә ул сине әйбер урларга, я булмаса, кеше хакына керергә өйрәтәме?

— Өйрәтми анысы өйрәтүен.

— Әллә аракы эч, тәмәке тарт дип көчлиме?

— Юк.

— Я, бәлкем, дин китаплары кеше үтерергә котырталардыр?

— Инде, инде! Андамыни эш? Котыртмый инде, юк!

— Юк шул менә. Һа, һа! Үз телең белән үк әйтеп салдың! Син шуны искәрмисеңмени, зимагур: борынгы китаплар сиңа, хәзерге җәдит китаплары шикелле, «ат чаба, арба-чана»[1] гына түгел инде ул. Авыл кешесе андыйны гына укымыйча да белә. Дин китапларында, беләсеңме, нинди хикмәтле, нинди гыйбрәтле сүзләр очрый! Синең белән без андыйны ун ел утырсак та уйлап чыгара алмыйбыз. Белдеңме шуны?

— Я, я! Нинди соң алар? Минем шушы иләс-миләс башка да берәрсе кереп калмасмы икән?

— Беләсең килсә, дин китабы җанга азык бирә, чын кеше булырга өйрәтә, күңелгә мәгънәле оеткы сала. Начар булма, яхшы бул, шакшы йөрмә, ару йөр, ди ул. Ишетәсеңме? Ялганлама, урлама, кешене хурлама, танавыңны күкләргә чөймә дип тә әйткәли. Туганнарыңны якын ит, ата-анаңа мәрхәмәтле, шәфкатьле бул дип әйтә. Кем әйтә? Дин китабы әйтә! Я, сөйләп кара, акыллы баш! Кайсы җәдит китабыннан табарсың икән шундый алтын сүзләрне?!

Әти, җиңгән кыяфәт белән җизнигә күз ташлап, тустаганнарны тутырды да үзенекен аударып та куйды. Җизни, тустаганын тотып үрә каткан килеш, нәрсәнедер исенә төшерергә тырышкандай, күзен челтчелт йомгалап, беравык ишек өстенә текәлеп торды.

— Әһ-һә! Менә мин сине сыртың белән салам хәзер! — дип тустаганын авызына каплады.

Әти, мыекларын сыпыргалап, көлде генә.

— Күккә төкермә, күкрәгеңә төшәр.

Мөхәммәтҗан солдат малай чагында үзе дә мәдрәсәдә укыган, аның өстенә күмердә русча да бераз маташтырган дип әйтәләр. Ул миңа күз кысып алды да яңадан этинең башын әйләндерергә кереште:

— Бабай, син кичләрен малайларыңнан укыта торган китапларны шулай мактыйсың инде, әйеме?

— Соң мактамаска, саваплы китаплар булгач...

— Инде! Минем үземнең дә тыңлап утырганым бар. Бәдвам, Бакырган, Йосыф белән Зөләйха. Арада Яңа Кисекбаш та, Сак-сок бәете дә, суга баткан Гаишә дә бар иде сыман.

— Андыйлары да укыла инде.

— Йосыф белән Зөләйха да саваплы инде, ә?!

Әти, нәрсәдәндер шикләнгән сыман, җизнигә сәерсенебрәк карап алды.

— Булмыйча, пәйгамбәрләр турында ич ул.

Җизни, шап иттереп, тезләренә сугып алды.

— Әлисә, бабай, патша хатыны Зөләйханың Йосыф дигән чибәр егеткә гыйшык тотуы да бик саваплы инде, ә? Шулаймы? Мисыр хатыннарының бу егетне күргә, бөтен дөньяларын онытып, пычак белән бармакларын турый башлаулары ничек тагын? Аңысында күпме икән савап?!

Әти эшнең болайга борылуына сәерсенеп карап торды да җизнигә бармак янады.

— Кара син зимагурны, ә! Кайсы яктан тез астына суктырды!

Җизни, әлеге ишек өстенә, күзләрен челт-челт йомып текәләп тордыторды да шуннан тапкан уйларын сынап карагандай, бармак битләрен уарга тотынды.

— Менә шул шул! Савапта гынамыни эш! Сиңа җан азыгы биргән, чын кеше булырга өйрәткән шул акыллы сүзләрне алла сүзе, пәйгамбәр сүзе дип беләсеңмени?

— Сүзе хикмәтле булгач, кем әйтсә дә барыбер түгелмени?

Җизни тагын чуар итегенә сугып алды.

---

[1] Ул еллардагы кайбер дәреслекләрдә шундый күнекмәләр очрый иде.

— Түгел! Муллалар «кара халык — кара сарык» дип, «мажик» дип мыскыллап йөрткән халык сүзләре алар. Тау астыннан атылып чыккан чишмә шикелле, китап юлларыннан халык акылы бәреп чыга!

Әти тустаганын бер ала, бер куя, нигәдер уңайсызлангандай кузгалгалап утыра иде. Җизни балын эчеп йөзен чытты. «Беткән баш — беткән!» дигәндәй кулын селтәде.

— Мин күмердә бик күп халыклар белән бергә эшләдем. Тик бездәге кадимче картлар ише кире беткән томана башларны беркайда да очратмадым. Аларны кеше итәр өчен кемнәрнең башы Себер китми! Халыкка дөнья гыйльмен өйрәтик, башына аң кертик, дигән кешеләрне патша бит төрмәгә яба, катыр җибәрә! Аңгыра баш булмасалар, ник шуны аңламыйлар? Аларны укымышлы кешеләр юньлегә өндиләр. «Әйдә, кояшка чык, сиңа монда әйбәтрәк булыр», — диләр. Алар нәрсә ди? «Юк, мин шушы пычрак сазда быкырдарга да риза. Тик оҗмахлы гына булыйм. Бөтен өметем җәннәттә», — ди. Әзерләп куйганнар, ди анда сиңа!

Җизни авыз эченнән ниндидер хәтәр сүзләр мыгырдап, «тефү» диде.

Әти, өйдәгеләргә борылып, тамак кырып алды.

— Ярар, Мөхәммәтҗан, — диде. — Ташка эссене шәп тондырдың. Язгы үз башыңа. Төш инде ләүкәдән. Башыңа эссе кабуы бар.

Мин уянганда төннең кайвакытлары булгандыр, чамалавы кыен иде. Бал чирекнең төбендә генә калган, табакта ит тә бик аз күренә иде инде. Әти терсәкләре белән верстакка таянып, күзләре белән аксыл тәрәзәләргә текәлгән. Аның тавышы баягы кебек кырыс ишетелми, ул хәзер җизнигә эчен бушата иде шикелле. Җизнинең йөзенә бераз җан кергән, ул, үрә каткан гәүдәсен селкеткәләп, ара-тирә «Инде! Инде!» дип куйгалый.

— Төшеңдә бастырылганың бармы синең? Тының буыла, җаның тамак төбенә килеп җитә. Шундый кыса сине, әйтерсең, күкрәгеңә тегермән ташы бастырганнар. Мена, менә буылдым, беттем дип торасың.

— Инде! Инде! Күмердә була андый, порода җимерелеп забойда бикләнеп калганда!

— ...Бер елны менә шундыйрак чагында күрше авылның карт хәзрәт килеп чыкты. «Алай өметеңне өзмә, Бәшир, өметсез шайтан, ди бу. Хода тәгалә үз бәндәләрен онытмый, ул һәр даим бәла-казадан җолып алырга әзер тора. Менәтерәк шундый киңәш: урыс патшасы чукындырып бетергәнчегә тикле төрек җиренә күчеп котылырга кирәк. Симеттән фәләнчә йорт китә, Максабаш белән Шыңардан, Кибәхуҗа белән Казакъллардан фәләнчә. Алдан бераз акча биреп куйсаң...»

Әйтүе ансат та бит, кузгалуы читен. Туган-үскән җир, үз туфрагың. Гомер буе атаң-бабаңның күз яшен, маңгай тирен сеңдергән җир. Әллә тагын да түзәргәме? Я, бәлкем, еллар җиңеләеп китәр, я, бәлкем, патша күңеленә алласы рәхим-шәфкать салыр...

— Салмый, салмый! Көтмә юкны, көтмә!

Әни мыштым гына чаршау артында тыңлап утырган җиреннән этинең аркасына тиеп алды:

— Самоварны яңартыйммы әллә?

— Һи, яңартмыйча! Әле башлыйбыз гына ич!..

Әти бераз тынып торды да тагын сөйләп китте:

— Нишлисең? Суздым ун сумны. Байраклар егермешәр, утызар сум бирде. Безнең авылдан гына да йөз сумнан артык җыелды. Инде көтәбез. Менә хәбәр киләсе дә җыенып төреккә чыгып китәбез. Анда баргач инде, янәсе, җир дә мул буласы, тамак та тук, өс тә бөтен буласы.

— Инде! Тот капчыгыңны! Җыен юләр, җыен караңгы!

— Бер ел узды — хәбәр юк. Хәбәр дә юк, хәзрәт тә юк. Куыш таяк эченә яшергән хатлар җибәреп, сорашып та карадык. Юк, онытылды төрек. Шулай ике-өч елдан тагын бер килеп чыкты бу.

— Кая соң, мин әйтәм, хәзрәт, кайчангарак кузгалабыз? Булмаса, акчаны кайтарасыңмы әллә? Карасам, хәзрәтем ичмасам, күзен дә йоммый.

— Һи, Бәшир, — ди бу,— акчаң өчен хафаланма! Бик изге юлга китте синең акчаң, дин юлына!

— Менә сиңа, мә!

— ...Чүгәләде дә бу: «Яле, бер дога!» — диде. Аллаһе әкбәр минем акча. Беләсеңме, ун сумга нинди шәп ат алып булыр иде ул елларны! Менә дигәнне, ажгырып торганны!

Әти, тустаганны авызына каплап, яңадан коеп куйды.

— Юк дөньяда дөрес кеше, бер генә кеше дә юк!

Әллә уяндым, әллә төшем булды, бераздан тагын сөйләшүләрен ишетә башладым. Таң әтәче дә колакка чалынды. Аның тавышы нәкъ әни йөзендәге алсу чаршау шәүләсе төсле бераз моңсу да, таң алды яктылыгы төсле сагышлы да, өметле дә кебек иде.

## IV

Озак та үтмәде, әти миңа яңадан үзебезнең мәдрәсәдә укырга рөхсәт итте. Туган телдә уку да, иптәш малайлар да шулкадәр сагындырган, кая ул узган еллардагы кебек эленке-салынкы йөрүләр, кая ул ялкаулану!

Бәлки, безнең мәдрәсәгә кергән кайбер яңалыклар да күңелне күтәреп җибәргәндер?

Язга таба, бер базар көнне, без мәдрәсәдә котырынып уйнап ятканда, кайсыдыр:

— Кайткан! — дип кычкырып җибәрде. Без аңыбызга килгәндә, Зәбихулла хәлфә, кыска гына муенын якасы эченә яшереп, ишектән үк килеп кергән иде. Киез катасын мич артына салып, читегенең кунычын тарткалады да кәләпүшен төзәтеп түргә барып утырды. Әмма без аның түгәрәк көрәнсу йөзенең ара-тирә яктыргалап китүеннән, вак кына апак тешләренең күренгәләп куюыннан базардан ниндидер шатлык алып кайтуын чамалаган идек инде. Хәлфә күкрәк кесәсеннән өр-яңа бер китап чыгарды:

— Кем укый? — диде.

— Мин! Мин! — дигән тавышлар төрле яктан ишетелсә дә, ул китапны миңа сузды. Шатлыктан кулларым дерелдәп китте. Әмма ул шигырьне укый башлагач, әллә нигә, тагын да каушыйрак төштем.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы...

Ике юлын укуга әллә ни булды. Нигә икәнен үзем дә белмәстән, әсәрләнеп туктап калдым. Бик газиз булып, әти белән әни күз алдына килде. Мәдрәсәдәге тынлыкка сәерсенеп як-ягыма карадым. Зәбихулла абый, кысык күзләрен елтыр-елтыр тәгәрәтеп, әле беребезгә карый, әле икенчебезгә. Иптәш малайларым авызларын ачып, минем кулдагы китапка текәлгәннәр. Мин шулай иләс-миләс торганда кабыргама төртеп колагыма пышылдадылар:

— Укы инде, укы!

Болай төрле яктан дәртләндереп торганны күргәч, мин тагын да батырланыбрак тотындым:

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән;
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

Бу шигырьне миңа тагын бер кат, аннан соң тагын бер кат укыттылар. Аннары без аны пәнҗешәмбе көн, җомга ялына таралыр алдыннан, бөтен мәдрәсә белән бергә кычкырып укый торган булдык. Бу шигырьнең бик ансат кына, сүзләренең мәгънәсенә юш килеп кенә тора торган көй сыманы да бар иде. Шигырь көйләгән калынлы-нечкәле балалар тавышы ишетелә башлауга, чишмәгә төшеп баручы хатын-кызлар, әбиләр, бабайлар мәдрәсә янына туктыйлар. Без аның саен дәртләнәрәк төшеп, кычкырыбрак әйтә башлыйбыз.

Без мәдрәсәдән чыкканда, әбиләр, күзләрен сөрткәләп, безнең аркадан сөеп калалар иде.

— И рәхмәт төшкерләре! Әнә нинди әйбәт мөнәҗәт әйтәләр, күңелләрне әллә нишләтеп җибәрә, — диләр.

Мәдрәсәдә, билгеле, ара-тирә сүз дә тигәләде, сирәк-мирәк кенә булса да почмакка тезләнергә дә туры килгәләде. Әмма әгәр дә син сабагыңны белсәң, дәресләреңне яхшы әзерләп килсәң, шул ук кырыс холыклы хәлфәнең йөзе яктырып, вак кына тешләре күренеп китә. Ул синең тырышып укуыңа ихлас күңелдән куанып, дәфтәреңнең кырыена я «тәхсин», я «афәрин» дип куя иде.

Ничек кенә булмасын, дүрт-биш кенә тәрәзәле шушы кечкенә иске бина үзендә укып чыгучылар күңелендә онытылмаслык истәлек калдыра иде. Әнә анда бик үк оста да укытмасыннар, әнә анда яшь гомернең байтак вакыты кирәкмәгән дин сафсатасын чәйнәүгә дә әрәм булсын. Шулай да монда син беренче тапкыр белем ишеген ачып кердең. Ул иске бина сине үз телеңдә укырга-язарга өйрәтте, күңелеңә һәйбәт тойгылар сеңдереп, күпме яхшы теләкләр уятты. Бәбде бәҗвиннән [1] башлап географик атамаларга кадәр — барлык белеп чыкканнарың гомер буе синең тормышыңны баетып, аңа ямь биреп килде.

Шуны алдан сизеп булса кирәк, язгы каникул җиткәч, без, шәкертләр, булган кадәр бәйрәмчәрәк киенеп килеп, тәгътил [2] мәҗлесендә хор белән саубуллашу шигыре көйли идек:

> Тәгътил дигән хәбәрләр
> Йөрәкләргә салдылар,
> Тукталабыз мәктәптән,
> Мәктәп җаным, әлвидаг [3].
>
> Кулга каләм тоттырдың,
> Безгә өмет йоттырдың,
> Фикер, зиһен арттырдың,
> Мәктәп җаным, әлвидаг.

Элекке шәкерт малайлар, егет булып җиткәннән соң, солдатка, я эш эзләп читкә китеп барганда шул тәбәнәк иске бина белән дә саубуллашалар. Читтән кайтканда, Каенсар үрен менгәч, күзләре белән туган өйләрен эзләгәндә, мескен генә булып посып утырган шул кечкенә йортка да ягымлы караш ташлыйлар иде.

*(Дәвамы бар.)*

[1] Бәбде бәҗвин — гарәп телендә хәрефләрдән тезелеп шигырь кебек ятлана торган тапкырлау таблицасы.
[2] Тәгътил — каникул.
[3] Әлвидаг — хушлашу сүзе.

*Хәй Вахит*

# Соңгы хат

*Драматик поэма, сигез картинада*

## Катнашалар:

Нияз — институтны яңа гына бетереп чыккан врач-хирург.
Зөһрә — институтны яңа гына бетереп чыккан врач.
Зөфәр — институтны яңа гына бетереп чыккан врач.
Ибраһим — участок больницасының баш врачы. Олы яшьтә.
Дилбәр Галиевна — врач. 30 яшьтә.
Розалия — медицина сестрасы. 18 яшьтә.
Фәйзи Шакирович — урта яшьләрдә, больницаның завхозы.
Рафаэль — Зөһрәнең энесе, 15—16 яшьтә.

Вакыйга безнең көннәрдә бара.

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Җәй, июнь ае. Медицина институтының Актлар залында кичә бара. Чыгарылыш кичәсе. Моңсулык һәм шатлык бергә кушылып, күңелләрне үз иркенә алган, әмма без залның зур өлешен күрмибез. Безнең күз алдыбызда залның колонналар артындагы кечерәк бер култыксасы. Киң һәм биек тәрәзә.

Залда вальс бара. Киң колачлы, ашкынулы вальс.

Әгәр дә залны күрсәтүе авыр булса, вакыйганы институт бинасының түр бакчасына күчерергә мөмкин. Ул чагында безгә бинаның бакчага чыга торган ишеге, киң баскычы, икенче катның зур тәрәзәләре, балконы күренер. Бакчага алып керә торган аллея һәм эскәмия дә кирәк булыр.

Вальс дулкыны бирегә дә бәреп чыккан. Кичнең бөркү булуы аркасында, күрәсең, яшьләрнең берничә пары биредә дә вальска әйләнә. Менә Зөһрә белән Зөфәр күренә, алар Ниязны эзлиләр. Күреп алгач, янына ашыгалар. Ниязның кичәгә яңа гына килүе.

Зөфәр. Кичә күптән башланды бит, кайда йөрисең син?

Урам яктан Ибраһим керә.

Зөһрә. Исәнмесез, Ибраһим абый.

Ибраһим. Исәнме. Сезгә сугыла алмадым, әтиеңне күрәсе иде. Бирәдәдер бит?

Зөһрә. Ул бүген килә алмый. Ибраһим абый, таныш булыгыз, дусларым: Нияз, Зөфәр. Бу — авыл больницасының баш врачы.

Ибраһим. Тәбрик итәм, тәбрик итәм. Кичәге шәкерт, иртәгедән булачак врачлар, ягез, кулыгызны кысыйм.

З ө һ р ә. Рәхмәт.
Б а ш к а л а р. Рәхмәт, рәхмәт.
З ө ф ә р. Диплом кесәдә, Ибраһим ага, без дә кеше булдык.
З ө һ р ә. Бүген биредә соңгы кичәбез.

З ө ф ә р.

Сау бул, вузым, аерылабыз инде,
Бүген синдә соңгы кичәбез!
Синдә алган белем хәзинәсен
Киләчәккә алып китәбез!

З ө һ р ә. Тормыш кочагына!
З ө ф ә р. Иртәгә безнең тормыш белән беренче очрашуыбыз!

З ө һ р ә. Ой, ямансу да, шатлыклы да. Алты ел бергә укыдык бит. Алты ел! Менә канатларны җәйдек инде. Очабыз. Төрлебез төрле якка.

З ө ф ә р. Бәхет эзләргә! Тик үзебез ул бәхет дигән нәрсәнең нинди икәнен белмибез әле. Калку күкрәкле хатын-кыз кыяфәтендә микән ул, әллә инде мал белән дыңгычлап тутырылган сандыклар микән?

И б р а һ и м. Бәхетне күрәсегез килсә, рәхим итегез, миңа — участок больницасына килегез. Эзләп йөрисе дә юк.

З ө ф ә р. Әзер килеш, агачта үсәме әллә? Үрелеп өзеп кенә аласымы?

И б р а һ и м. Я, кайсыгыз? Нияз, синме?
Н и я з. Булмый, Ибраһим абый, шәһәрдә калдыралар.
И б р а һ и м. Шәһәр синнән башка яши алмас дисеңмени?!
Н и я з. Күз алдыма да китерә алмыйм.

И б р а һ и м. Ә мин тагын, берәрсен авылга тартып булмасмы, дигән идем.

З ө ф ә р. Без укыганда фәнни түгәрәккә йөрдек. Өчебез бергә бер зур гына тема өстендә эшләдек һәм кайбер нәтиҗәгә дә ирештек. Шул фәнни хезмәтебезне дәвам иттерергә мөмкинлек булсын өчен өчебезне дә шәһәрдә калдыралар.

Н и я з *(мыскыл катыш)*. Күрдегез, без нинди кыйммәтле бәндәләр. Сайланып кына алынганнар. Алланың кашкалы тәкәләре.

З ө ф ә р *(Ниязга)*. Между прочим, син өч көн буенча күзгә-башка күренмәдең. Шул арада күпме яңалык булды. Безнең хезмәтебезне журналга урнаштырачаклар. Бусы булды — бер. Ректорат буенча безнең өчебезгә дә мактау белдергән приказга инде кул куелды. Бусы булды — ике.

И б р а һ и м. Сездә бүген чын мәгънәсендә тантана икән. Котлыйм, котлыйм.

З ө ф ә р. Кермәгән җирем калмады, министерствога кадәр барып җиттем.

Н и я з. О, без хәзер эшне министр белән генә йөртәбез.

З ө ф ә р *(кесәсеннән бер шешә кызыл аракы чыгара)*. Бу тантананы билгеләп үтмичә ярамастыр. *(Кәгазьдән бокаллар ясарга керешә. Моңарчы әкрен генә ишетелеп торган вальс моңы көчләрәк яңгырый башлый.)*

Кайда гына йөрсәң дә,
Ниләр генә күрсәң дә,
Җиңел юллар эзләмә,
Җиңел юл эзләмә...

Н и я з. Фю!.. Кызыл буяу. Спирт алып килергә ярамаган. Без, хирурглар, организмны спирт белән генә юарга гадәтләнгәнбез.

З ө ф ә р *(бокал күтәреп)*. Олы юл алдыннан, соңгы тост!

З ө һ р ә *(бокал күтәреп, шаяру катыш)*. Тормыштан алырга мөмкин булганның барысын да алып бетерергә!

З ө ф ә р. Гел кояшка карап атларга, күләгәләр артта калсын!
З ө һ р ә. Якты уйлар булсын юлдашыбыз!
З ө ф ә р. Ахырдан оялырга туры килмәслек итеп яшәргә!
Н и я з. Үлгәнчегә кадәр яшәргә!
З ө һ р ә. Нияз, әллә инде эчеп килгәнсең?
Н и я з. Бүген дә эчмәсәң, кайчан эчәргә?! Минемчә, бүген аек йөрү — үзе гөнаһ.
З ө һ р ә *(кисәтеп)*. Нияз!
Н и я з *(басым ясап)*. Җиңел юл эзләмәскә!
Б а ш к а л а р *(күтәреп алалар)*. Җиңел юл эзләмәскә! Эзләмәскә! *(Кәгазь бокалларын чәкештереп эчәләр. Вальска кушылып җырлыйлар.)*

Кайда гына йөрсәң дә,
Нилар генә күрсәң дә,
Җиңел юллар эзләмә,
Җиңел юл эзләмә...

З ө һ р ә. Әйдәгез! Ибраһим ага, рөхсәт итегез! *(Ибраһим белән вальска әйләнеп китә. Биредә Нияз гына кала. Аның кәефе шәптән түгел. Ә вальс моңы көчәйгәннән көчәя бара.)*

Гомер юлы — бакча юлы түгел,
Чокыры да булыр, тавы да.
Нур балкыган аяз көннәр булыр,
Булыр көннең җилле чагы да.
Адашырсың, юл табарсың, —
Күңел бит ул омтыла да эзләнә.
Кайда гына йөрсәң дә,
Нилар генә күрсәң дә,
Җиңел юллар,
Җиңел юллар эзләмә,
Җиңел юл эзләмә...

Зөһрә кире килә. Аның артыннан Зөфәр. Икесенең дә күңелләре күтәренке, бәйрәмчә.

З ө һ р ә. Нияз, син нишләп биемисең?
З ө ф ә р. Сиңа ни булды?
Н и я з. Тыңлыйсызмы, яңа анекдот: ферма тавыклары зарлана башлаганнар. Әтәч картайган...
З ө һ р ә. Оят түгелме?!
Н и я з. Әйдәгез, алла хакы өчен, китик моннан.
З ө ф ә р. Кая?
Н и я з. Ресторанга!
З ө һ р ә. Нәрсә?!
Н и я з. Яки синең бүлмәңә. Бүген минем өчебез генә утырасым килә. Икегезне дә кочаклап.
З ө һ р ә. Юкны сөйләмә. Китмибез.
Н и я з. Мин биредә йөри алмыйм. Күзгеләр зур. Үземне күрәсем килми.
З ө һ р ә *(катгый)*. Яле, сөйлә, ни булды?
Н и я з *(бераздан)*. Минем сезнең кәефегезне бозасым килмәгән иде. Шушындый көндә, соңгы кичәдә...
З ө ф ә р. Я, я?
Н и я з. Дусларым, без бит ялгышканбыз. Безнең фәнни хезмәт дип йөргән нәрсәбез — чепуха, адашу, буш куык.
З ө ф ә р. Нәрсә?!
Н и я з. Методикабыз дөрес булмаган. Ялгыш юлдан барганбыз. Шуңлыктан ясаган нәтиҗәбез дә ялгыш. Нигезсез.
З ө ф ә р. Булмас. Мөмкин түгел.

Н и я з. Өч көн чыкмыйча лабораториядә яттым, сынау үткәрдем. Өч мәртәбә кабатладым, нәтиҗә шул бер үк — ялгыш. Менә пропорцияләр һәм тәэсирләре! *(Блокнотка теркәлгән язмаларын күрсәтә. Зөфәр дә, Зөһрә дә таныша. Икесенең дә кәефләре бозыла. Әлекке бәйрәм күтәренкелегенең эзе дә калмый.)*

З ө ф ә р. Ах, шайтан алгыры, ничек соң без әлегрәк бу турыда уйламаганбыз. Менә бәла, кирәк бит.

Озак пауза. Берсе дә сүз башлый алмый.

З ө һ р ә. Нишләргә соң инде?

Н и я з. Төенне үзебез төйнәдек, инде үзебезгә үк чишәргә кала.

З ө ф ә р. Сөйләп бирергәме? Ректоратта да, студентларга да? Без ялгышканбыз, гафу итегез инде, тиешсезгә шапырынып йөргәнбез, без мәгънәсез, ахмаклар икәнбез... Шулаймы?

Н и я з. Башка чара юк.

З ө һ р ә. Нинди көн булды соң бүген?!

З ө ф ә р. Паникага бирелмик әле. Фән юлы тип-тигез, тап-такыр гына булмый. Фән юлына маяклар кадалмаган. Ялгышырга да, адашырга да мөмкин. Бер табасың, ул ялгыш булып чыга, тагын эзлисең. Өзлексез эзләнү. Шуңа күрә дә аны иҗат диләр. Безнең ялгышырга да хакыбыз бар.

Н и я з. Әмма ялганларга — юк.

З ө һ р ә. Ялгышканыбызны ачыктан-ачык үзебез сөйләп бирергәме? Бар икән...

З ө ф ә р. Ашыкмагыз. Уйлап карыйк, фәнни түгәрәктә безне күтәрделәр. Зур тема, зур проблема өстендә эшлиләр дип. Өчәү бергә — кумәк эшлиләр дип. Институт газетасында мактап яздылар. Башкаларга безне үрнәк итеп куйдылар. Стимул! Димәк, башкалар безгә карап тигезләнәләр, алга омтылалар. Хәзер без чыгып, ялгышлыкны ачып салсак, ни була? Барысы да ялганга әйләнәчәк, җимереләчәк түгелме? Шулай икән, без тәрбия эшенә никадәр зыян китерәчәкбез. Бу политик мәсьәлә. Минемчә, гомуми файданы күздә тотып, без хәзергә дәшмәскә тиешбез.

Н и я з *(кызып)*. Бу бит, бу бит гаделсезлек философиясе. Беләм, җәмәгать алдына чыгып, ялгышлыкны икърар итү җиңел түгел...

Вальс агымы тагын кагылып үтә.

Кайда гына йөрсәң дә,
Ниләр генә күрсәң дә,
Җиңел юллар,
Җиңел юллар эзләмә.
Җиңел юл эзләмә...

З ө һ р ә *(икеләнеп)*. Дәшмәскә?

З ө ф ә р. Хәзергә дәшмәскә! Эшне дәвам иттерергә, дөрес юлын эзләргә кирәк. Табарга да яңа нәтиҗәне тәкъдим итәргә. Шул чакта инде элеккесенең ялгыш булганын әйтеп үтәргә дә булыр. Өчебезне дә шәһәрдә калдыралар, мөмкинлек булачак дигән сүз.

Н и я з. Ох, ошамый бу миңа. Тырышып-тырышып ялганга юл ачарга җыенабыз түгелме? Юк, тормышта мин беренче адымымны чигенеп башларга теләмим. Ялганга уралып, җанымны газаплап, изелеп яшәргәме?! Теләмим, булдыра алмыйм. Минем ирекле буласым килә. Һәртөрле фальштан, ялганнан, гаделсезлектән арынып, ирекле яшисем килә! Кешеләрнең күзенә туры карый алырлык булып. Икеләнер чак түгел, без дөреслекне ачарга тиешбез.

З ө ф ә р. Зөһрә, синең сүзең. Син хәл итәсең.

З ө һ р ә *(уйланып)*. Әйтергә? Үзебезгә җәза бирергәме? Ә бит без

изге юлда идек, теләгебез изге иде, кеше сәламәтлеге, кеше гомере өчен тырыштык. Без шуның өчен җәзаланырга тиешме инде?

Зөфәр. Әйе, изге эш өчен җәза бирмиләр!

Нияз. Зөһрә, мин синнән моны көтмәгән идем. Синең икеләнергә хакың юк.

Зөһрә. Ә эти?

Нияз *(тынып калды).* Профессор?

Зөфәр. Без бит үзебезне генә түгел, аны да уңайсыз хәлгә куябыз.

Нияз. Профессор...

Зөфәр. Дөрес, ул безнең хезмәтебезне ниндидер яңа ачыш дип күккә күтәрмәде, әмма бит ул безне яклады. Кыюлык өчен мактады, безгә ышанды, уңай бәя бирде. Язма рәвештә. Хәзер шуны аяк астына салыйкмы?

Нияз. Ул безгә аю хезмәте күрсәтте. Хәзер телефонга чакыртам да әйтәм мин аңа.

Зөһрә. Уйлама да! Рөхсәт итмим!

Зөфәр *(кисәтеп).* Карт авырып ята.

Нияз. Ах, әйе. Ярамый, врачлык этикасы юл куймый. Авыруга безнең ялганларга хакыбыз бар, ә борчырга юк.

Зөфәр. Димәк, хәзергә дәшмибез? *(Китә.)* Я?

Нияз. Дәшмәскә туры килә икән шул.

Зөфәр. Шулай дөрес булыр. Килештек.

Залда зәңгәр ут кабына. Биредә аерата куе зәңгәрлек җәелә.

Зөфәр. Я, онытыйк әле, ни әйтсәң дә, бүген безнең соңгы кичәбез. *(Өчесе дә җырга кушыла.)*

Биш алсаң да офтанма,
Өч алсаң да мактанма,
Юкка-барга шатланма.
Килачәгең — аккош юлы,
Белем синдә сандык тулы,
Канәгать бул юктан да.
Хыял булыр — юл башың,
Өмет булыр — юлдашың.
Күңел бит ул эзләнә.
Кайда гына йөрсәң дә син,
Нилар генә күрсәң дә син,
Җиңел юллар эзләмә.

Бер студент кыз керә. Кулында гитара.

Студент кыз. Зөһрә, баядан бирле сине эзлибез. *(Гитараны суза.)* Синең чыгыш. Сәхнәгә көтәләр.

Зөһрә. Ой, сулыш алырга ирек бирегез... *(Залга юнәлә. Тукталып.)* Юк, юк. Нияз, син барма. Син карап торсаң, мин каушаячакмын. Үтенәм. *(Китәләр. Нияз кала, әмма ул Зөһрәгә күз төшермичә булдыра алмый: штораны күтәрә — бөтен зал ачыла. Сәхнәдә Зөһрә. Үзе гитарада уйнап, үзе җырлый. Кушымтасына бөтен зал кушыла. Бары бер Нияз гына, Зөһрәдән күзен алмыйча, йотлыгып тыңлый.)*

Чыгасың да Идел ярларына,
Сөяләсең бөдрә талларына.
Чал Иделнең таңкә дулкыннары
Тәгәрәп килә синең алларыңа.
Трал-ля-ля-ля-ля-пам...
Трал-ля-ля-ля-ля-пам...
Дулкын-дулкын йөрәк хисләремне
Сибәр идем синең алларыңа.

Чыгасың да урман аланына,
Сокланасың шомырт, баланына.
Кошлар моңына кумелеп шаулый урман
Яфракларын коя алларына.
Трал-ля-ля-ля-ля-пам...
Трал-ля-ля-ля-ля-пам...
Яфрак түгел, йөрәк хисләремне
Сибәр идем йөргән юлларыңа.

Җыр бетә. Зал алкышка күмелә. Зөһрә бирегә килә. Дулкынланган.

Нияз. Әйбәт җырладың.

Зөһрә. Тыңладыңмыни? Ну сине!

Нияз. Кешеләргә күпме шатлык китерә аласың син.

Зөһрә. Ошаттыңмы? *(Зөфәр килә.)*

Зөфәр. Тәбрик итәм, Зөһрә. Браво, браво! Искиткеч!

Зөһрә. Чыннан дамы?

Зөфәр. Шәп. *(Кулын кыса.)*

Зөһрә. Шундый каушадым, шундый каушадым, белсәгез иде.

Зөфәр. Хәзер безнең өчебезне дә сәхнәгә чакырачаклар. Әзерләнеп торыгыз.

Нияз. Нәрсәгә?

Зөфәр. Әйткән идем ич, мактау белдергән приказга кул куелды дип. Шуны сәхнәдән укыячаклар.

Нияз. Ничек? *(Аңлап алып.)* Ә-ә... Күздән югалып торган идең аны. Яннарына барып шуны кичәнең программасына керттергәнсең икән. Оештырдың? Баягы сөйләшүдән соң?! Приказның безгә ялгыш бирелгәнен белә торып?!

Зөфәр. Син нәрсә! Үзләре сорадылар.

Нияз. Ә син шатланып риза булдың? Шуны бел, мин сәхнәгә чыкмаячакмын.

Янадан элеге студент кыз килә.

Студент кыз. Нияз, Зөфәр, Зөһрә, сезне сәхнәгә сорыйлар.

Зөһрә *(һаман да алкыш тәэсиреннән айнымаган хәлдә)*. Әйдәгез! Нияз, әйдә, чәнчелеп китсен, алыйк кәгазьләрен. Җир белән күк арасында асылынып тормасын.

Нияз. Зөһрә, шаяра торган эшме бу?

Зөһрә. Ә кем әйтте сиңа, шаяра дип. Минем бәлки чыннан да сәхнәгә чыгасым килә торгандыр. Кемнең макталасы килмәс!

Нияз. Үз сүзләреңне сөйләмисен.

Зөһрә. Ох, син бик принципиаль булып киттең әле.

Нияз. Алкышлардан башың әйләнгән, уңыштан исергәнсең. Сиңа башта айнырга кирәк.

Зөһрә *(нык үпкәләп)*. Рәхмәт! *(Йөрәге әрнеп.)* Ә мин тагын син мине алкышлаганга сөенәсеңдер дип уйлаган идем, ялгышканмын.

Зөфәр. Бәхәсләшә торган чак түгел. Әйдәгез, безне көтәләр.

Нияз. Мин бармыйм.

Зөфәр. Син нәрсә, шик тудырырга телисеңме?! Без сәхнәгә чыгып, син чыкмасаң — нәрсә уйлаячаклар? Син бит инде безнең белән килешкән идең, дәшмәскә риза булдың. Хәзер үз сүзеңнән кире кайтасыңмы? Безне — иптәшләреңне уңайсыз хәлдә калдырырга телисең? Бу түбәнлек.

Нияз. Минем сәхнәгә чыгарга ризалык биргәнем юк.

Зөфәр. Хәзер соң инде. Әйдә, чыгасың!

Нияз. Яхшы. Әйдәгез, киттек. Бик уңай момент. Чыгам да бөтен залга кычкырам, бөтен дөреслекне ачам да салам. Белсеннәр безнең нинди шарлатан икәнлекне!

Зөфәр. Нәрсә син! Ташла! Ярый, чыкмыйбыз. *(Бүлеп.)* Рәхмәт. Кемлегеңне күрсәттең. Онытырлык булмады. *(Зөһрәгә.)* Барып әйтәм, көтмәсеннәр. *(Китә. Вальс башлана, бу юлы тагын да көчлерәк, киңрәк. Зөһрә дә китәргә юнәлә.)*

Нияз. Зөһрә. *(Зөһрә туктала.)* Миңа синең белән сөйләшергә кирәк.

Зөһрә. Ә миңа кирәкми. *(Китмәкче.)*

Нияз. Зөһрә!..

Зөһрә. 23 ел Зөһрә!

Нияз. Бүген безнең бәйрәмебез.

Зөһрә. Син ул бәйрәмне бозарга да өлгерден инде.

Вальс көчәя, кульминациясенә җитә. Аның дулкыны бирегә дә бәреп керә. Кемдер Зөһрәне биергә үк алып китә.

Адашырсың, юл табарсың —
Күңел шулай омтыла да, әзләнә...

Вальс бер якыная, бер ерагая. Бераздан Зөфәр Зөһрәне тәрәзә буена алып килә. Зөһрәнең күңеле ачылган, ул шаркылдап көлә. Колоннага сөялгән Ниязны алар күрмиләр.

Зөфәр. Син миңа бүген соңгы сүзеңне әйтергә тиешсең. Безнең бүген соңгы кичәбез. Син әйтергә тиеш. Соңгы сүзеңне!

Зөһрә *(көлеп)*. Әйтәм, нигә әйтмәскә. Мин синеке. Син бит миннән башка яши алмаячаксың. Шулай булгач, сине коткарып калырга кирәк бит инде.

Зөфәр. Зөһрә!

Зөһрә. Аннан соң бит син миңа иң турылыклы ир булачаксың. Өрмәгән җиргә утыртмаячаксың. Күктән йолдызлар тотып бирәчәксең. Мин дөньяда бик бәхетле хатын булачакмын.

Зөфәр. Зөһрә дим!

Зөһрә. Син көнләшәсең, берәрсе белән сөйләшеп кенә торсам да кара янасың. Мин сиңа турылыклы хатын булырмын. Берәүгә дә күз төшермәм, бер генә ир заты белән дә исәнләшмәм, сөйләшмәм. Хәтта йөземне дә күрсәтмәм. Пәрәнҗә ябармын. Мин синең колың булырмын.

Зөфәр. Зинһар дим, җитәр!

Зөһрә. Син бит мине үлемнән коткаручы. Мин синең алда гомерем белән бурычлы.

Зөфәр. Юк, юк, юк! Син миңа бурычлы түгел. Миңа синең бурычлы булуың кирәкми. Миңа синең йөрәгең кирәк.

Зөһрә. Ә син ашыкма.

Зөфәр. Күпме көтәргә?! Син бүген соңгы сүзеңне әйтергә тиешсең: әйеме, юкмы?

Зөһрә. Әйе.

Зөфәр. Шаяртасың?

Зөһрә. Шаяртам.

Зөфәр. Әллә чыннан әйтәсеңме?

Зөһрә. Чыннан әйтәм.

Зөфәр *(ялварып)*. Зөһрә!

Зөһрә. Әйе, ихтимал, мин синеке булырмын. Син көт... Ха-ха-ха...

Зөфәр. Фәрештәм минем! Богиня! Ангел!..

Зөһрә. Акылсыз, ишетәләр.

Зөфәр. Ишетсеннәр, бөтен дөнья ишетсен!.. *(Зөһрәне әйләндерә, шул әйләнүдән вальска кушылып китәләр. Колонна артында Нияз күренә. Колоннаны кочаклый, күрәсең, йөрәге сыкрануын физик көч белән басарга тели. Вальс көчәя бара. Ибраһим күренә, ул һава суларга — тәрәзә янына юнәлә.)*

Нияз. Ибраһим абый!

Ибраһим. Син нишләп биемисең? Чү, сиңа ни булды, агарынгансың.

Нияз. Ибраһим абый, мин риза. Мин карар бирдем, авылга китәм, сезнең янга. Аласызмы?

Ибраһим. Бик шатланып. Дөрес итәсең. Үкенмәссең. Эш шарты тудырырбыз, ышандырам.

Зөһрә килә, житди.

Зөһрә *(Ниязның үзенә генә)*. Нияз, син миңа нәрсәдер әйтмәкче булган идең.

Нияз. Юк, ул болай гына. Кирәкле сүз түгел иде. Гафу ит.

Зөһрә *(әрнеп)*. Нияз!

Нияз. Нәрсә әйтергә уйлаганымны оныттым да инде. Ә, әйе, хуш, Зөһрә, без аерылышабыз. Мин шәһәрдә калмыйм, китәргә булдым.

Зөһрә *(тәмам аптырап кала)*. Ә?.. Китәсең? Бездән аерылып, группаны таркатып? Безнең бит уртак эшебез бар, аны дәвам иттерәсебез бар. Аның турында, иптәшләрең турында оныттыңмы?! Ә бергә-бергә корган планнар, идеалыбыз? Алар сиңа берни дә тормый?! Качасың?! Беләсеңме, бу ничек дип атала? Хыянәт, кешелексезлек!

Нияз. Нинди хыянәт булсын, ди. Безнең ул фәнни эшебез ялган булып чыкты бит, чепуха. Утка гына ягасы.

Зөһрә. Бар, кит! Әмма шуны бел, мин моны бервакытта да гафу итмәячәкмен. Үкенүен үкенерсең, соң булыр!

Нияз. Юк, үкенмәм, ялгышасың! Киресенчә, шушы минутта ук сине күрмәс өчен, синнән еракта булу өчен ниләр генә бирмәс идем мин. Күрәлмыйм мин сине! Бүтән бер вакытта да очрашмасам икән, тавышыңны, теләсә кемгә елмаюыңны, шаркылдап көлүләреңне ишетмәсәм, күрмәсәм икән. Китәргә, китәргә! Тизрәк, тизрәк! Туйдым! Гарык булдым! Күрәлмыйм!

Барысын да вальс бөтерел ала. Яшьлек ашкынулары, шаулашу-гөрләшү көчәя бара. Эчке пәрдә төшә, әмма вальс тукталмый, үсә-үсә ул буранлы давылның котырынуын сурәтләгән музыкага әверелә.

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Авыл. Урамнарны кар каплаган, өйләрнең түбәләре белән тәрәзәләре генә күренә. Буран. Больницаның дежур бүлмәсе. Олы тәрәзәләр. Ике ишек. Өстәл, медикаментлар шкафы, диван, урындык.

Нияз юлдан кайтып керә. Бүрегендәге карларын кага. Чишенә. Диванга утыра. Арыган. Шкафтан авырулар тарихын алып карый башлый. Дилбәр Галиевна керә.

Дилбәр *(күңеле күтәренке)*. О, Нияз Салихович, кайттыгызмы, ә мин борчылдым. Буранда адашмагае дип. Аргансыздыр.

Нияз. Булды бераз.

Дилбәр. Кичә клубта кино булды. Кызганыч, күрә алмадыгыз.

Нияз. Авыруны ташлап китәргә ярамады.

Дилбәр. Хәер, бүген күрше авылга барып карарга була. Теләсәгез үзем юлдаш булырмын.

Нияз. Эш күп.

Дилбәр. Әйбәт картина, «Брак по итальянски», карамый калмагыз. Минем аркада гына булса, бармам. Тагылып йөрергә яратмыйм.

Нияз. Юк... мин... арып торам.

Дилбәр. Яхшы, беркая да бармыйбыз. Кавказдагы апам «мускат» җибәргән. Миндә утырабыз. Өчәү генә. Сез, мин, мускат. Башка беркем дә юк. Бу озын авыл кичләрен кыскартып булмасмы. *(Халатын чишә.)*

Нияз. Куркам, минем белән ул тагын да озынрак тоелмагае.

Д и л б ә р. Көндезләрен эш белән үтә, сизмичә дә каласың. Ай, бу кичләре! Иксез-чиксез, тын һәм шыксыз кичләр. Ходай сабырлык бирсен. Киләсезме?

Н и я з. Беләсез, минем буш вакытларым юк диярлек.

Д и л б ә р *(кесәсеннән кәгазь чыгара)*. Язу калдырып киткәнсез икән.

Н и я з. Әйе, баш врач исеменә. Киткәндә үзен туры китерә алмадым.

Д и л б ә р. Теге кечкенә бүлмәне бушатуны сорыйсыз?

Н и я з. Андагы кайбер артык әйберләрне икенче бүлмәгә чыгарасы иде. Бер дә кирәкмәгәнгә җимерелеп беткән шкаф тора.

Д и л б ә р. Ул бүлмәдә лаборатория ясарга телисезме? Сынаулар үткәрергә? Ишеткән идем, институтта чакта ук фәнни тема өстендә эшләгәнсез дип. Шуны дәвам иттерәсезме?

Н и я з. Нигезеннән үзгәртеп.

Д и л б ә р. Яңа препарат эзлисез? Наркоз, новокаиннардан да эффектлыракны? Кеше шуны кабул итсә, операция ясалганын сизми дә калачак диме?

Н и я з. Шулайрак.

Д и л б ә р. О, ул чагында һәркем теләсә нинди операциягә курыкмыйча ятар инде. Һе, хыял дигәнең.

Н и я з. Айга очу сезнеңчә хыял түгелме?

Д и л б ә р. Хыял.

Н и я з. Очачаклармы соң?!

Д и л б ә р. Карыйм да мин сезгә, Нияз Салихович, гаҗәпләнәм. Кайдан килә сезгә шул кадәр энергия. Болай да күпме эш: авырулар, операцияләр, лекцияләр. Шулар өстенә фәнни хезмәт белән шөгыльләнү. Кайчан гына йоклыйсыз соң сез? Сокланам мин сезгә.

Н и я з. Рәхмәт, Дилбәр Галиевна.

Д и л б ә р. Ә ул бүлмәне, әлбәттә, бушатырга кирәк. Приборларыгызга, җиһазларыгызга урын сорала ич. Бушатырлар, бүген үк.

Н и я з. Рәхмәт.

Д и л б ә р. Тагын берәр ярдәм кирәк булса, шулай тартынмагыз, сорагыз. Кулымнан килгәнне эшләргә мин һәрвакыт әзер. Без больницабызда шундый галим булуы белән...

Н и я з. Сез арттырасыз.

Д и л б ә р. Эшегездә уңыш телим, Нияз Салихович. *(Ишек буенда туктала.)* Мин анда завхозга әйттем, бүлмәне хәзер үк бушатыр.

Н и я з. Рәхмәт сезгә, рәхмәт.

Д и л б ә р. Пожалуйста.

Н и я з. Ләкин Дилбәр Галиевна...

Д и л б ә р *(сагая)*. Тыңлыйм.

Н и я з. Сез ничек уйлыйсыз, үтенеч баш врач исеменә язылган, Ибраһим ага исеменә, шулай булгач, аны ул укырга, боерыкны да ул бирергә тиеш түгелме соң?

Д и л б ә р. Сез моның белән ни әйтергә телисез?

Н и я з. Сез кеше хокукын узләштерәм дип уйламыйсызмы дим?

Д и л б ә р. Ах, менә сез ни турында. *(Сөйләшүне уенга борырга теләп кеткелди.)*

Н и я з. Сез юкка мәшәкатьләнгәнсез, Дилбәр Галиевна. Миңа сезнең боерык бирүегез кирәк түгел. Аны кем бирергә тиеш булса, шул бирер. Баш врач. Әйдәгез, кеше вазифасына катнашмыйк инде.

Д и л б ә р. Аңладым мин сезне. *(Тынычлык сакларга теләп.)* Пожалуйста. Минем ярдәмем кирәк түгел икән, пожалуйста, ихтыярыгыз. Мин бары сезгә яхшылык эшләргә теләп кенә... Борчыган булсам, гафу итегез. *(Чыгып китә. Нияз нәфрәтләнеп кала. Тагын авырулар тарихын*

*актарырга керешә, графиннан су агыза башлый. Шул чакта агарынган Розалия килеп керә.)*

Розалия. Нишләдегез сез, нишләдегез, Нияз абый?! Дилбәр Галиевнага каты бәрелдегезме? Ул бит сезгә ярдәм итмәкче иде.

Нияз. Мин аның ярдәменнән баш тарттым. Бары шул гына.

Розалия. Харап иткәнсез икән. Беләсез ич инде, безнең больницада баш врач ул бит.

Нияз. Юк, Розалия, бездә баш врач Ибраһим абзый.

Розалия. Әй, Ибраһим абый бит ул формаль яктан гына, югарыдан куелу буенча гына. Ә нигездә — Дилбәр Галиевна. Бөтен больницаны дер селкетеп тора ич. Бөтенесе белән командалык итә. Бөтен хезмәткәр, хәтта Ибраһим абый үзе дә аңа буйсына ич.

Нияз. Бөтен хикмәт тә шунда: Дилбәр Галиевна мине дә — яңа килгән кешене дә — үзенә буйсындырмакчы. Ә мин аңа бармыйм. Гаделсезлеккә юл куюу булыр иде. *(Су эчмәкче.)*

Розалия *(стаканын алып куя).* Мин сез кайтышка чәй кайнатып куйган идем. *(Шкафтан термос чыгара.)* Әй, Нияз абый, нигә инде сезгә Дилбәр Галиевна белән әчелешле булырга. Белмисезмени аны, усал бит ул. Үз дигәнен итми калмас. Әнә хәзер дә сезнең яннан чыгуы булды, завхозга кушуы булды. Бар, аның боерыгына буйсынмыйча кара.

Нияз. Нинди боерык ул тагын?

Розалия. Сез сораган бүлмәдән җимерек шкафны чыгартасы урынга...

Нияз *(сабырсызланып).* Әйе?

Розалия. Сезнең үзегезнең өстәлегезне, приборларыгызны, бөтенесен, бөтенесен дә... *(күз яшенә тыгыла.)*

Нияз. Ну, Розалия!

Розалия. Коридорга чыгарып атарга кушты.

Нияз. Кайда? Ничек?! *(Ашыгып чыгып китә. Икенче ишектән Дилбәр Галиевна үзе килеп керә.)*

Дилбәр. Син нигә эшеңдә түгел? Гайбәт таратып йөрисеңме?

Розалия. Мин, Дилбәр Галиевна... Мин...

Дилбәр. Урыныңда бул. Авырулар сине көтсеннәр тагын.

Розалия *(сылтау табып).* Ә мин эш белән. Кайда соң әле? *(Нидер эзләгән була.)* Ә, менә кайда ята икән. *(Шкаф артыннан, Дилбәргә комачаулап, нәрсәдер ала да, бик җитди кыяфәттә, ашыгыч эш артыннан йөргән кешедәй, ишеккә атлый. Үзеннән канәгать. Дилбәр ышанырга да, ышанмаска да белмичә кала. Нияз килеп керә. Дилбәр белән бер-берсенә карашып, тукталып калалар.)*

Нияз. Сез... Сез ничек җөрьәт иттегез?!

Дилбәр. Биредә фәнни институт түгел, иптәш Нияз Салихович. Больница. Авыл больницасы. Галим буласыгыз килгәч, шәһәрдә калырга иде.

Нияз. Минем приборларны бүлмәдән чыгарттырып атарга сезнең ни хакыгыз бар?

Дилбәр. Бүлмә больницага кирәк.

Нияз. Ә сезгә?

Дилбәр. Нәрсә — миңа?

Нияз. Власть күрсәтү кирәкме? Боерык бирү?

Дилбәр. Ялгышасыз, Нияз Салихович. Мин боерык бирмим, киңәш итәм.

Нияз. Һәм сезнең киңәшегезне бер карышусыз үтиләрме?

Дилбәр. Тыңлыйлар. Күрәсең, ярата лар.

Нияз. Ә сез куркытып яраттырам, дип уйламыйсызмы? Мин сезне, врач буларак, ихтирам итәм. Хезмәтегезне яратып, тәгәл башкарасыз.

Авыруларга сез игътибарлы, вакытыгызны, көчегезне кызганмыйсыз. Белгеч буларак хөрмәт итәм мин сезне. Әмма...

Д и л б ә р. Әйтеп бетерегез.

Н и я з. Әмма бу холкыгыз! Үзегезне бөтен кешедән өстен куюыгыз, хәтта баш врач итеп тотуыгыз!

Д и л б ә р. Безнең больницаның үз традициясе бар. Һәм ул сез кылганга карап кына үзгәрмәс.

Н и я з. Юк, үзгәрер ул, Дилбәр Галиевна. Үзгәрергә тиеш.

Д и л б ә р. Карап карарбыз. *(Чыгып китә. Каршына Ибраһим абзый очрый.)*

И б р а һ и м *(бер чыгып киткән Дилбәргә, бер Ниязга карап алгач, чишенә-чишенә)*. Ни булды, бәрелештегезме? Күтеп йөри идем аны, болар бер эләгешерләр әле дип. Озак көттермәдегез.

Н и я з. Ибраһим абый, гадел эш түгел бу. Баш врач була торып, нигә сез аңа юл куясыз? Ул сезнең дәрәҗәгезне, кешелегегезне аяк астына сала.

И б р а һ и м. Һәй, коллега, нишләргә кушасың, талашып йөрергәме? Аннан башка да эш муеннан. Командалык итәсе бик килә икән инде, әйдә кылансын шунда, рәхәтен күрсен. Син аңа игътибар итмә. Нишләмәк кирәк? Райкомда да сүз кузгаткан идем, баш врач итеп аны билгеләргә кирәк дип. Күндереп булмады. Якын да килмиләр. *(Розалия керә.)*

Р о з а л и я. Нияз абый, әйберләрегезне кая куярга, коридорда ятмаслар бит.

Н и я з. Ибраһим абый, лабораториягә дип мин теге кечкенә бүлмәне сораган идем.

И б р а һ и м *(аптырап кала)*. Һем... ярар, мин Дилбәр Галиевна белән сөйләшеп карармын. Аңлатырмын. Бәлки, күндереп тә булыр.

Н и я з *(шаккатып, өзгәләнеп)*. Ибраһим абый, сез — баш врач?! Ярый, кирәк түгел, сөйләшмәгез. Лабораторияне мин үз квартирама күчерәм.

И б р а һ и м. Куяннар белән бер бүлмәдә яшәрсеңме?

Н и я з. Яшәрмен. Ә сез... Сезнең алай түбәнлеккә төшәргә хакыгыз юк. Аңлыйсызмы, хакыгыз юк. Гомерегез шушы больницада үткән, сез аны оештыргансыз, шушы хәленә җиткергәнсез. Бирегәге һәр нәрсәгә сезнең көчегез кергән. Халыкның хөрмәтен казангансыз, ихтирамын... Ә сез!.. *(Ибраһимның сәламәтлеге начарланып китте ахры, йөрәк янына кул куеп, сөялеп утырды.)* Ни булды? Тагынмы?

И б р а һ и м. Зарар юк. Үтәр, үтәр. Һава бозылдымы, сиздерә башлый.

Н и я з. Ой, ошамыйсыз сез миңа.

И б р а һ и м. Ошамасам, я алла, син кыз түгел, мин егет түгел.

Н и я з. Сезгә кичекмәстән операциягә ятарга кирәк. Сузмыйча.

И б р а һ и м. Үгет бирүе җиңел.

Н и я з. Ибраһим абый, җан кисәгем!..

И б р а һ и м. Әү, бәгырькәем!

Н и я з. Сәламәтлек белән исәпләшмәскә мөмкинме?! Сез бит үзегез врач.

И б р а һ и м. Кызганычка каршы.

Н и я з. Шәһәрдә олы хирурглар бар. Танылган, тәҗрибәле, ышанычлы.

И б р а һ и м. Сөйләмә дә, үгетләмә дә. Пычак астына ятар хәлем юк.

Н и я з. Ха, сугышларда ут эченә кереп йөргән кеше димәссең дә! Сугыш беткәнгә инде егерме ел. Егерме ел буе йөрәк янында осколка йөртә.

И б р а һ и м. Истәлек.

Нияз. Куркаклык! Алдырып ташларга батырлыгыгыз житми, куркак сез!

Ибраһим. Өстенә бастырдың. Операция дигән сүзне ишетүгә, тәнемә салкын су койган кебек була. Калтырана ук башлыйм.

Нияз. Һәм моны врач сөйли.

Ибраһим. Врач та кеше. Яшьтән үк ходайдан сораганым шул иде: теләсәң нишләт, әмма пычактан гына тунатма.

Нияз. Соң бит... кирәк булгач.

Ибраһим. Беләм, кирәк икәнен дә бик яхшы беләм. Ә булдыра алмыйм. Булмый. Әй, нәрсә ул кадәр борчылырга. Яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган, дигәндәй...

Нияз *(йөрәге белән кычкыра)*. Ибраһим абый!

Ибраһим. Ә менә син, хирург, әйтеп кара әле, ул операцияне миңа үзең ясар идеңме?

Нияз *(көтмәгән иде)*. Нигә — мин? Минем әле тәжрибәм шул кадәр генә. Андый катлаулы операция өчен шәһәрдә...

Ибраһим. Ә-ә-ә... Үзең ярырга да алынмыйсың, ә мин ярдырырга тиеш. Шул шул, *(җырга салып)* кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә. *(Халатын киеп ала, палаталарга чыгып китә. Нияз башын күтәрә алмыйча кала. Розалия, Ниязның уйларын бүлдерүдән куркып, урыныннан да кузгалмый.)*

Розалия. Нияз абый... Нияз абый...

Нияз *(Ибраһим сүзләрен кабатлый)*. Ә менә син үзең, хирург, бу операцияне ясарга алыныр идеңме? *(Бер үк вакытта Розалиягә дә, үзенә дә.)* Кешеләр безгә дөньяда иң газиз нәрсәләрен — гомерләрен ышанып тапшыралар. Кешеләр миңа ышанмасалар, авыр булыр иде. Ә менә үземнең үз көчемә ышанып житмәвем — авыррак. Кешеләр операциядән куркалар. Кирәк икәнен белсәләр дә куркалар. Бу табигый хәл. Хәтта врачлар да курка. Ә ул куркуны, авыртуны җиңәргә мөмкин бит. Мөмкин булырга тиеш. *(Тәрәзә аша тыштагы буранга карап тора, аннары форточканы ачып җибәрә. Бүлмәгә бөтерелеп давыл шаулавы кереп тула һәм ул әкренләп вальска әверелә. Ниязның уйлары еракка — вальс чайкалган залга — Зөһрә белән бергә уздырган кичәгә юнәлә. Вальс үсә бара, хәтта аңа кушылып җырлаган Зөһрәнең сүзләре аермачык ишетелә.*

> Кайда гына йөрсәң дә,
> Ниләр генә күрсәң дә,
> Җиңел юллар эзләмә,
> Җиңел юл эзләмә...

*Нияз кисәк форточканы яба. Хәтта штораларны төшерә. Бар да кинәт тына. Нияз онытылырга теләп утыра, әмма булдыра алмый.)*

Розалия. Нияз абый, чәй эчмисезме?

Пауза. Нияз озак дәшми. Аннан ниндидер карарга килә.

Нияз. Кәгазь китер миңа. Кәгазь.

Ут сүнә. Эчке пәрдә төшә. Вальс дәвам итә.

## ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Кышкы шәһәр нур эчендә балкый.

Зөһрә бүлмәсе. Жыйнак, пөхтә. Кич. Зөһрә кайтып керә. Пальтосын сала. Ак халатын сала. Өстәлдә яткан газеталар арасыннан хат эзли. Әмма хат юк. Зөфәр керә.

Зөфәр. Зөһрә, син әле киенмәгәнсен дә. Сонга калабыз.

Зөһрә. Мин, Зөфәр, театрга бара алмам, ахры. Кәефем юк. Башым авыртып тора.

Зөфәр. Алайса кыстамыйм.

З ө һ р ә. Син миңа карама, бар, берәр кызны ал да...

З ө ф ә р. Ну, ну! Алай шаярырга рөхсәтем юк. *(Кесәсеннән ике билет чыгара.)* Мин дә бармыйм. *(Билетларны ертa.)* Син ят, авырып китә күрмә тагын. *(Күен кесәсеннән машинкада басылган 7—8 битлек мәкалә чыгара.)* Зөһрә, шуны профессорга тапшырчы.

З ө һ р ә *(сөенеп)*. Мәкалә? Безнең уртак эшебезне дәвам иттерергә булдыңмы әллә?

З ө ф ә р. Юк, бу бөтенләй икенче тема.

З ө һ р ә *(сүрелде)*. Ә мин уйлаган идем тагын. Көткән идем... Ничектер, күңелсез килеп чыкты. Беренче уңышсызлыктан соң ук туктальп калдык. Таркалдык.

З ө ф ә р. Ул эш барып чыкмады бит инде, көчебездән килмәде. *(Зөһрә мәкаләне укымакчы)*. Ә юк, сиңа укырга рөхсәт ителми. Әллә ни түгел ул, кечерәк кенә бер мәкалә. Журналда урнаштырмакчы булалар. Профессор фикерен әйтсә...



Зөфәр — артист *Әзһәр Шакиров.*
Зөһрә — Татарстанның атказанган артисткасы *Асия Галиева.*

З ө һ р ә. Юк, Зөфәр, син моны әтигә бирергә тиеш түгелсең.

З ө ф ә р. Ник?

З ө һ р ә. Чөнки ул уңай бәя бирәчәк.

З ө ф ә р. Синеңчә ничек, мин кире бәя бирүчене эзләргә тиешме? Бу нинди логика?!

З ө һ р ә. Аңла, әти сине мине яраткан кебек ярата, үз итә. Син бит аның бердәнбер кызын үлемнән коткарган кеше. Җаныңны кызганмыйча, упкын төбеннән тартып алучы. Шулай булгач, ул синең мәкаләңне ошатмаса да яклап чыгачак.

З ө ф ә р *(уйга кала)*. Әйе, әйе.

З ө һ р ә. Ул миңа ничек караса, сиңа да шулай карый. Мин үз мәкаләмә этидән рецензия яздырып алсам, килешер идемени?!

З ө ф ә р. Әйе.

З ө һ р ә. Зөфәр, җиңел юл эзләмә. Минем сине көчле кеше итеп күрәсем килә.

З ө ф ә р. Син хаклы. Профессор мине үз баласы кебек күрә. Әлбәттә, ошатмаса да мактаячак. Ничек бу минем башыма килмәгән. Юк, юк, аңа бирергә ярамый. Гадел булмый. Юк, юк, бирмибез. *(Мәкаләне кесәсенә тыга.)* Вакытында аңлатуың өчен рәхмәт. Минем искә дә кермәгән. Я, мин киттем. Син ял ит.

З ө һ р ә. Ачуланма.

Зөфәр китә. Аның каршына Рафаэль очрый.

Р а ф а э л ь. Алма апа, ресторанда мин, беләсеңме, кемнәрне күрдем.

З ө һ р ә. Син әле шулай рестораннарга йөри башладыңмыни, малай башыңнан?!

Р а ф а э л ь. Малай! Бу малайга кызлар ход бирми инде. Бал тирәсендә безелдәгән чебеннәр кебек... Беләсеңме, кемнәрне күрдем: теге

чакта — су коенганда сиңа һөҗүм иткән, батыра язган исерек егетләрне. Икесен дә таныдым. Алар янында тагын, беләсеңме, кем бар иде? Сине шулардан коткаручы.

Зөһрә. Зөфәр?!

Рафаэль. Беләсеңме, алар электән танышлар, алар дуслар.

Зөһрә. Булмас. Ышанмыйм. Мөмкин эш түгел. Ялгыш күргәнсең.

Рафаэль. Шулайдыр, тавык күзе иде миндә.

Зөһрә. Тукта әле, син, малай актыгы, нишләп әле рәтләп күрмәгән, белмәгән килеш, сөйләшмәгән-сорашмаган килеш, олы кеше турында шулай теләсә нәрсә сөйләп йөрисең?!

Рафаэль. Ярый алайса, ярый, синеңчә булсын. Алар түгел икән, мин ялгышканмын...

Зөһрә. Колагыңны боручы юк!

Рафаэль. Әй, сиңа сөйләп торган мин җүләр... Менә сиңа хат!

Зөһрә. Хат? *(Рафаэль хатны бирә дә икенче бүлмәгә чыга.)* Хат. Нияздан! Адресын язмаган. *(Өстәл лампасын яндырып, хат укырга керешә.)*

Зөһрә. «Зөһрә, исәнме!..

*(Зөһрә йотлыгып укый, бөтен күңеле белән хат эченә кереп китә. Ул хатны язучының сүзләрен генә түгел, тавышын ишетә, хәтта үзен күз алдына китерә. Шунлыктан, Зөһрәдән өч-дүрт адым арттарак прожектор уты яктысында хат иясенең без үзен күрәбез, тавышын ишетәбез.)*

Нияз. Исәнме, Зөһрә! Бу хатны укыгач, син гаҗәпләнеп калырсың. Ләкин ышан, мин аны язмыйча булдыра алмадым. Үземне үзем кулга алырга, барысын да онытырга, онытырга күпме тырышсам да булмады, кулга каләм алырга мәҗбүр булдым.

Сине онытып буламы соң?! Зөһрә, мин яратам бит сине. Менә ничә ел инде син минем бөтен барлыгымны биләдең. Күңелемнән чыкмыйсың, уемнан китмисең. Әле бергә укыган чакта да мин синең күз карашыңнан үземнең язмышымны укып яши идем. Очраклы рәвештә генә бер елмайсаң да, ул көнне дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк иде.

Зөһрә *(хаттан күзен ала).* Бу сүзләреңне синең ничек көттем мин! *(Тагын укый башлый.)*

Нияз. Укуда, түгәрәк эшендә, чаңгыда ярышсак та, минем һәрвакыт алдынгы буласым килде. Кем өчен дисең? Синең өчен, синең игътибарыңны казану өчен. Хәтерлисеңме, бервакыт нинди биек трамплиннан сикердем. Син карап тормасаң, сикерер идеммени? Мин һәр эшемне сиңа багышладым, син илһамым минем, гомер юлыма нур сибеп баручы кояшым!

Зөһрә. Җүләрем.

Нияз. Беләм, син мине яратмадың. Мин синең кемне ратканыңны да беләм.

Зөһрә. Ә син бер нәрсә дә белмисең.

Нияз. Юк, мин сине гаепләп әйтмим, юк-юк, аллам сакласын. Ләкин ни генә булса да, син һаман да минем илһам чыганагым. Бүген исә мин моңа аерата мохтаҗмын.

Авыру кеше операция өстәленә кичен йокларга яткан кебек ятсын иде дә, иртән йокыдан уянган кебек торсын иде. Шул вакыт эчендә операция ясалганын ул үзе сизми дә калсын иде. Я, әйт, бу әлегә хыял түгелмени?! Ләкин безнең вазифабыз хыялны чынбарлыкка әверелдерү. Кыскасы, Зөһрә, мин үзебезнең уртак фәнни эшебезне дәвам иттерергә, сынаулар ясарга керешәм. Бу минем тормышымның максаты. Бәлки, бу проблеманы мин хәл итә дә алмам. Мин итмәсәм, башкалар итәр. Әмма кемдер башларга тиеш бит.

Зөһрә. Шулай күз йомып упкынга ташлана торган гадәтең бар синең. Шуның өчен дә мин сине...

Нияз. Менә ни өчен мин синең ярдәмеңә мохтаҗмын. Миңа синең минем һәр эшемне белеп торуың кирәк. Бүген башкарган эшләремне иртәгә синең ишетәчәгеңә мин бүген ышанган булырга тиешмен. Шул чагында мин үземдә тау-таш җимерерлек көч табачакмын. Онегин әйтә ич:

> «Но чтоб продлилась жизнь моя,
> Я утром должен быть уверен,
> Что с вами днем увижусь я...»

Мин дә шул хәлдә, Зөһрә.

Кыскасы, мин сиңа хат язып торачакмын. Атна саен, көн саен. Эшләгән эшләремнең нәтиҗәсен сиңа җиткереп барачакмын. Синнән бары бер генә нәрсә сорала: укып кына бар. Хәтта җавап язасы да юк. Хәер, син яза да алмаячаксың, мин сиңа адресымны бирмим.

Зөһрә. Ни өчен? Нигә син алай дисең, нигә?! *(Карар биреп.)* Ә мин табачакмын. Син сорамасаң да, үзем язачакмын. Үзем!

Нияз. Син минем өчен борчыла күрмә тагын. Мин сине гомергә югалтсам да, гомергә таптым. Без беркайчан да очрашмабыз.

Зөһрә *(әчке сөенеч белән кабынып)*. Ә мин очрашачакмын! *(Сер әйткән кебек.)* Мин үзем синең янына барачакмын. Илһам бирү өчен, ярдәм итү өчен, кирәк икән, кинәшем белән булышу өчен. Көтмәгәндә килеп чыгармын әле, менә күрерсең!..

Нияз. Без очрашмабыз, ләкин син һаман да минем йөрәгемдә. Хуш, сау бул, ерактагы кояшым, сау бул, минем бәхетсез бәхетем!

Зөһрә *(укый)*. Нияз, 17 нче январь.»

Пәрдә

## ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Яз. Авыл. Больницаның дежур бүлмәсе. Нияз операциядән чыга. Чишенә башлый. Розалия аңа ярдәм итә.

Розалия *(шатлыклы)*. Бар иде сукыр эчәк, юк булды сукыр эчәк. Шул кирәк аңа. Сукыр булмасын иде. Әйеме? *(Көлә.)* Ә сез, Нияз абый, көннән-көн остара барасыз.

Нияз *(аның да күңеле күтәренке)*. Әй-яй-яй, ялагайланмаска.

Розалия. Ә сез миңа ышаныгыз. Мин сезнең һәр хәрәкәтегезне күзәтеп барам.

Нияз. Белмим шул. Һәр операция алдыннан бер үк тойгы, әйтерсең, беренче мәртәбә ясыйм.

Розалия *(бик шатлыклы хәбәр әйткәндәй)*. Ә куян йокысыннан уянды.

Нияз *(бу хәбәр аңа нык тәэсир итте)*. Шулаймени, нигә әйтми торасың?

Розалия. Операция вакытындамы?! Уянды, ашарына биргән идем, ашый. Күңеле шундый күтәренке.

Нияз. Чынлапмы?

Розалия. Көлә, елмая.

Нияз. Сөйләшә дәме, нәрсә ди? *(Үзе дә сизмәстән, Розалияне күкрәгенә кочып ала. Нияз моңа игътибар итми, ә Розалия тынып кала: кочакладың бит.)*

Розалия. Ә Актырнак миннән йоклап калган иде.

Нияз. Ай да без, Розалия, ә! Эшләр бара бит. Берсен йоклатабыз, берсен уятабыз. Болай булса, препаратның да серен тиз ачарбыз без, ә?

Розалия. Минем ни катнашым бар.

Нияз. Син ярдәмчем минем, син булмасаң, ике кулсыз булыр идем.

Р о з а л и я. Әй, Нияз абый, шул арттырып җибәрә торган гадәтегезне!

Н и я з. Нигә, чыннан әйтәм. Син бит инде тәмам лаборантка булдың. Тик зарплата гына алмыйсың. Җитәкчен фәкыйрь булып чыкты. Үзенә дә юк, ярдәмчесенә дә.

Р о з а л и я. Бөтен зарплатагызны шул сынауларга тыгып бетергәч.

Н и я з. Ярый әле өйләнмәгәнмен. Юкса хатын ирек бирмәс иде. *(Сабын сорый.)* Алып бирче.

Р о з а л и я. Нәрсә, кәгазьме?

Н и я з *(аптырап калды)*. Нигә — кәгазь?

Р о з а л и я. Хат язарга. *(Икесе дә тынып калды.)* Әйтер идем инде үзегезне дә. Язасыз да язасыз, унбишләп булгандыр инде, ә ул ник бер генә җавап җибәрсен.

Н и я з. Каян алдың?

Р о з а л и я. Иптәш кызым почтада эшли. Мин барысын да белеп торам.

Н и я з. Ну, Розалия, чәбәкләргә кирәк сине. Азына башладың.

Р о з а л и я. Кош теле кадәр бер хат кисәге язып салса, кулы калмас иде. Дөресен генә әйткәндә, ул үзе килеп чыгарга тиеш. Сез шушындый эш башкарасыз, ә ул...

Н и я з. Җитте диләр сиңа. Аның турында бер сүз дә!

Ибраһим белән Дилбәр керә.

Д и л б ә р. Ә-ә, Нияз Салихович... Тәбрик итәм, тәбрик итәм. Ибраһим агабыз сезне үз урынына — баш врачлыкка тәкъдим итә икән ич.

Н и я з. Мин дә ишеткән идем, ничек ул алай?

И б р а һ и м. Ишеткәннәр дә. Һай, бездә чыбыксыз телефон эшли дә соң! Ничек өлгерәләр?! *(Кискен.)* Ә менә шулай: Ибраһим абыегыз картаеп бара, комы коела башлады. Җилкәсендәге кайбер йөген бүшатса да гөнаһ булмастыр. Шушындый яшьләр үсеп килгәндә... *(Җитди.)* Хәлемне беләсез. Сызланып чыккан төннәрем күп.

Н и я з. Хәлеңне беләбез, шуңа күрә дә сезгә кичекмәстән шәһәргә — операциягә!

И б р а һ и м *(дәвам итәргә ирек бирмичә)*. Каныктыгыз билләһи, операция дә операция. Башка сөйләр сүзегез юкмы әллә. Булмас ул операция, ходай биргән булса. Көтмәгез.

Н и я з. Баш врач булырга дисезме? Миңа? Юк, булмый. Аның өчен мин яшь әле, эш күрсәтәсем бар, ышаныч казанасым. Тәҗрибәм дә юк, дәрәҗәм дә шул кадәр генә.

И б р а һ и м. Эшләрсең. Тәҗрибәң дә булыр, башкасы да.

Н и я з. Хирург буларак та мин әле беренче адымнарны гына атлыйм. Дөресен әйткәндә, вакыты-вакыты белән мин әле үземә-үзем дә ышанып җиткермим. Үземнән-үзем канәгать түгел.

И б р а һ и м. Бик әйбәт. Бик белдекле булып, үзеннән канәгать булып йөргән кешеләрне җенем сөйми. Андыйлардан берәр мәгънәсезлекне көт тә тор. Менә шундыйлар инде җиде үлчисе урынга, бер үлчи дә ике кисә. Ә безнең эштә җитмеш мәртәбә үлчәргә кирәк.

Н и я з. Соңгы сүзем шул, мин риза түгел. Гафу итегез, мин авыру янына. *(Чыгып китә, аның артыннан Розалия дә чыга.)*

Д и л б ә р. Тыйнаклык күрсәтә, янәсе. Баш булырга теләми, имеш. Һе, көлеп үләрсең. Ә мин сездән, Ибраһим ага, моны көтмәгән идем. Үз урыныгызга кемне билгеләмәкче буласыз.

И б р а һ и м. Ялгышасыз, Дилбәр Галиевна, мин билгеләмим. Билгеләү дә алмыйм. Мин тәкъдим генә итәм.

Д и л б ә р. Кемне?! Килеп житмәгән, сыналып өлгермәгән. Хирург буларак та ышанычсыз, әнә ич, үзе әйтеп тора.

И б р а һ и м. Үзе ни әйтмәс.



Дилбәр — артистка *Гәүһәр Камалова.* Ибраһим — РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты *Габдулла Шамуков.*

Д и л б ә р. Сез, гомумән, Ниязны канат астына аласыз. Аның кыек эшләренә юл куясыз. Әнә, райфодан ревизия килде дә...

И б р а һ и м. Килмәде, китерттегез, Дилбәр Галиевна.

Д и л б ә р. Әйе, яшермим, китерттем. Чөнки мин законсызлыкка юл куя алмыйм. Тәртип икән, тәртип. Үзем дә бозмыйм, башкалардан да боздырмыйм. Больница акчасына, больницага керәге шул кадәр генә булса да, финанс статьясын бозып, төрле приборлар алына. Һәм алар белән Нияз Салихович үз квартирасында, үз хаҗәте өчен файдалана. Бу ни?!

И б р а һ и м *(кызып китә).* Нияз Салиховичның нинди эш өстендә утырганын бик яхшы беләсез. Ашкынып, ялын онытып, көн-төн эшләве дә сезгә мәгълүм. Шундый чакта да без аңа булышлык күрсәтмәсәк!

Д и л б ә р. Гәрчә больница эшенә турыдан-туры катнашы булмаса дамы?!

И б р а һ и м. Ул бит хирургия өлкәсендә яңа препарат эзли ләбаса. Эзләсен.

Д и л б ә р. Хыял.

И б р а һ и м. Хыяллансын. Яшьлеккә хас нәрсә. Берсе тапмаса, берсе табар.

Д и л б ә р. Беләм мин ул әкиятне. Үзем дә институт бетергәндә ординатурага, аспирантурага китәргә өметләнә идем. Нәрсә килеп чыкты?! Син дигәнчә генә булмый шул, тормыш төзәтмә кертә икән ул. Аның үз законнары бар. Эш, дежурство, лекция, местком, җыелыш — барысын да оештыр, барысына да өлгер. Муеннан чумдым. Шәхси тормышым бөтенләй юк. Ә нәрсә алдым? Әнә, кемдер минем турыда самозванка дип ычкындырган.

И б р а һ и м. Ялгыш ычкындырган. Үкенгәндер үзе дә.

Д и л б ә р. Нияз килгәнче, андый ялгышулар булмый торган иде.

Ибраһим нык дулкынлана, кирәкмәгән сүзләр ычкынмасын дип ахры, читкә китә, бүтән бер сүз дә дәшми.

Д и л б ә р. Мине хурлыйлар, ә сез юл куясыз. Больницаның бөтен эшен диярлек алып барам. Үзем өчен дә эшлим, сезнең өчен дә. Баш врач хокукын үзләштерә диләр, юк, беркемнең дә хокукын алганым юк. Мин җаваплылык алдым. Сез институтны кайчан тәмамлаган? Чирек гасыр элек. Бу вакыт эчендә белгәнеңне дә онытып бетерергә мөмкин. Ә мин яңа гына тәмамладым. Сез ничә ел укыдыгыз? Дүрт. Ә мин алты ел. Минә уйлап карагыз, шушындый ситуациядә минем җаваплылыкны сизмәскә хакым бар идеме?! Белмим, мин булмасам, нишләр идегез икән.

Нияз керә. Розалия күренә. Нияз тәрәзә буенда басып торган Ибраһимның, сиздермәскә тырышып кына, кулъяулыгы белән күз яшен сөрткәнен күреп ала. Сәбәбен аңлап, сүзсез кала.

Н и я з *(чиксез нәфрәт белән, әмма тынычлык саклап)*. Беләсеңме нәрсә, Дилбәр Галиевна... Әгәр дә сез ир затыннан булсагыз, мин сезне хәзер үк, шушы минутта ук дуэльга чакырган булыр идем. Һәм, ышаныгыз, соңгы сулышыма кадәр сугышыр идем. Ничек сез җөрьәт итәсез?! Сезгә дәваланырга кирәк. Кайчакта авыру гына түгел, үз характерындагы әшәке чирдән дә дәваланырга кирәк була. Үзегезнең һәр адымыгызга анализ ясап карагыз. Билләһи дип әйтәм, сез анда гаделсезлек табарсыз.

Д и л б ә р. Белмим, кемне дәваларга кирәктер. Карап карыйк. *(Җилкенеп чыгып та китә, тиз генә әйләнеп тә керә. Кулында кәгазь.)* Дәваларга икән, дәваларга. Менә рецепты язылган да. Кул куясы гына калган. *(Ибраһимга суза.)* Рәхим итегез, имзагызны!

И б р а һ и м. Бу ни? Приказ? *(Өстән-өстән генә укып.)* «Финанс тәртибен бозып, сметадан чыгып... больница приборларын читкә чыгарып, үз интересында файдаланган өчен... Нияз Салиховичка... кисәтү ясарга». Юк, мин моңа кул куя алмыйм.

Д и л б ә р. Ревизия нәтиҗәсе белән килешмәскә мөмкин түгел.

И б р а һ и м. Калдырыгыз.

Д и л б ә р. Ярар, үзегез чамалыйсыздыр.

Н и я з. Ибраһим абый, чәнчелеп китсен, куегыз, тынычлансын.

И б р а һ и м. Куймыйм. Минем рөхсәттән башка эшләнгән эш түгел.

Д и л б ә р. Приказга икегезнең фамилиягезне дә язарга идемени?

Н и я з *(түзәрлеге калмады)*. Ярар, бирегез, үзем куям. Күңелегез булсын. *(Приказны тартып ала да яза.)* Копия дөрес: имза. Менә стенага эләргә дә була.

Д и л б ә р. Кирәк булса эләрләр дә. Яман чир котырып, азып китмәсен өчен шифасы була аның. Профилактика. Сыналган дәва. Ә хәзер инде приборларны больницага китереп тапшырырсыз дип уйлыйм. *(Нияз телсез кала, бу кадәресен үк көтмәгән иде.)*

Н и я з *(берәздән, үзен кулга алып)*. Китерермен.

Д и л б ә р. Хәзер үк. Розалия, бар.

Р о з а л и я. Приборлар булмагач, сынаулар өзелә бит, Нияз абый!

Н и я з. Бар, Розалия, китереп тапшыр. *(Розалия ишеккә юнәлгән иде, шулай да Дилбәр алдында тукталды.)*

Р о з а л и я. Ой, кемгәдер үкенергә туры киләчәк килүен.

И б р а һ и м *(кисәтеп)*. Розалия!

Р о з а л и я. Ә мин бирәүдән дә курыкмыйм.

Розалия чыгып китә.

Д и л б ә р. Менә шулай, чибәр егет. *(Чыгып китә. Ибраһим белән Нияз бер-берсенә карашып алалар, җилкәләрен җыералар, әмма бер сүз дә сөйләшмиләр. Ишектә Фәйзи Шакировичның башы күренә.)*

Ф ә й з и. Мөмкин булырмы? *(Керә. Йомры гына, ир уртасы адәм.)* Дилбәр ханымның чыкканын көттем. Күзенә чагылмавың артыграк.

И б р а һ и м. Сиңа нәрсә, Фәйзерахман?

Ф ә й з и. Менә ничә ел инде шушы больницада завхоз булып эшлим, бер генә даруыгызны да кабып караганым юк. Ичмаса, кызык өчен генә дә йоттырмыйсыз.

И б р а һ и м. Менә мә, сайла: бусы — тән кычытканнан, бусы — йоклата торган, монысы — эчне нигыта, монысы — җибәрә...

Н и я з. Нидән зарланасың?

Ф ә й з и. Көнләшүгә каршы берәр әмәлен табалмассызмы дигән идем. Тәмам алҗытты бит явыз.

И б р а һ и м. О, көнчелек зур бәхетсезлек ул.

Ф ә й з и. Элегрәк, яшьрәк чакта, хатынны көнләп җәфа чиктем. Хәзер инде җыен юк-бардан. Берәрсенең мине уздырып җибәргәнен

күрдемме, шабаш, хәтта кытыгым ук килә башлый. Берәр даруы юкмы соң шуның?

Нияз. Кытык килгәннәнме?

Фәйзи. Операциясез булмастыр, ахры. Нерва җепләре чуалып китте микән, әллә үт куыгы сытылганмы? *(Ибраһим кеткелди.)* Нәрсә, ышанмыйсызмы? Шулай инде, сөйләп кеше ышандыра аламмыни мин. *(Ниязга борылып.)* Менә гел шушы хәл. Нишләргәдер инде, аптыраган. Дөресен сөйләсәм, ялганлый диләр, ялганласам — дөрес дип утыралар. Шуңа күрә, күбесенчә, алдарга кирәк булса, мин дөресен әйтәм, ә дөресен әйтергә кирәк булганда, тотам да ялганлыйм. Өстенә барып баса!

Ибраһим. Синә ничек ышанасың, телең бер нәрсә сөйли, күзең икенчене. *(Кеткелди-кеткелди чыгып китә.)*

Фәйзи. Менә малайны медицина институтына кертергә йөрим. Ни өчен дисез? Шул — кончелек. Башкаларныкы укый, минеке дә калмасын, янәсе. Берни эшләр хәлең юк. Хәстәрен алдан ук күрә башларга туры килә. Профессоры — танышыгыз, кызы белән дә бергә укыгансыз икән. Булдырсагыз, Нияз Салихович, сез генә булдырасыз инде аны. *(Нияз аңа аптырап карап тора.)* Гомер онытмас идем. Әлбәттә, анда бер профессор гына түгел, ишләре шактый булыр. *(Кесәсенә тыгыла.)* Мин эш кешесе. Тимерне кызуында сугарга яратам. Сез инде, зинһар, миңа ярдәм итегез. Үзегез белеп, кемгә күпме... *(Калын гына конверт чыгара.)*

Нияз. Нишләвегез бу сезнең!

Фәйзи. Майламасаң, арба да тәгәрәми.

Нияз. Сез мине кем дип беләсез?!

Фәйзи. Сезгә түгел, Нияз Салихович, андагыларга.

Нияз. Алыгыз. *(Конвертны этеп җибәрә.)*

Фәйзи. Шулай, шулай. Дөрес эшлисез. Дөрес, шулай эшләнә. *(Конвертны кире Нияз алдына сала.)*

Нияз. Карагыз әле, сез акылыгыздамы, юкмы. Сез...

Фәйзи. Тиргәгез, тиргә, әйтегез. Ныграк орышыгыз, шулай эшләнә.

Нияз. Калдырыгыз мине!

Фәйзи. Китәм, китәм. Сез мине белмисез, мин сезне. Шулай эшләнә. *(Чыгып китмәкче.)*

Нияз. Тукта! Теләсә кайда акча ташлап йөрергә байлыгың шулай чамасызмыни?

Фәйзи. Кирәк кадәр.

Нияз. Әҗәткә биреп торырга да кодрәтеннән киләме?

Фәйзи. Сораучысына карап.

Нияз. Менә, мәсәлән, миңа.

Фәйзи. О, сезгә һәрвакытта!

Нияз *(бер карарга килеп)*. Менә нәрсә, малаеңны институтка үзем әзерләрмен.

Фәйзи. Ай, рәхмәт. Сезнең кебек, Ибраһим абзый кебек кеше чыгарып булмасмы, дигән идем, шул дүрт күздән.

Нияз. Монда күпме?

Фәйзи. Өч багана.

Нияз. Алам. Әҗәткә.

Фәйзи. Әлбәттә, әҗәткә.

Нияз. Өч айдан артык тотмам. Кәтә алсаң.

Фәйзи. Әлбәттә, көтәм. Шулай, әҗәткә булмыйча нәрсәгә булсын. Дөрес итәсез, бик дөрес. Шулай эшләнә.

Нияз. Расписка биримме?

Фәйзи. Сез нәрсә, Нияз Салихович, җәберләмәгез.

Нияз. Кирәк урыны чыкты.

Фәйзи. Күреп торам ич. Ревизия дә бик төпченде. Аннан бу аждаһасы, Дилбәр Галиевнаны әйтүем, казынмаган урыны юк.

Нияз. Туктале, син кем өчен кайгыртып йөрисең: малаең өченме, әллә минем өченме?

Фәйзи. Икегез өчен дә. Эшегез авыр, Нияз Салихович, күреп торам. Барып кына чыга күрсен иде. Ярты юлда туктала күрмәгез. Әгәр дә мәгәр, барып чыкса, үзем дә операция ясатыр идем. Көнчелектән! *(Кеше кергәнен сизеп.)* Хуш булдык. *(Чыга. Розалия күренә.)*

Нияз. Розалия! Ибраһим абыйны күрмәдеңме?

Розалия *(ишек ачып)*. Коридорда.

Нияз *(кычкыра диярлек)*. Ибраһим абый! *(Ибраһим керә.)* Ибраһим абый, мин баедым. Приборлар өчен үзем түлим.

Ибраһим. Кайдан бу кадәр?

Нияз. Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына. Мәгез, Дилбәр Галиевна тынычлансын.

Ибраһим. Белмим шул, моннан соң тагын да котырынмаса.

Нияз. Үземнән бушагач, приборларны больницага бүләк итәрмен. Аларның кирәге булачак. Ә хәзергә... Розалия, син аларны алып килгән идеңме? Кире илтергә, кире, бөтенесен дә минем квартирага!

Розалия. Ура!... Болай булгач эш өзелми дигән сүз. Сынаулар дәвам итәчәк! Йөгердем!

Нияз. Йөгер.

Розалия чыгарга юнәлә, әмма Ибраһим сүзен ишетеп ишек буенда тукталып кала. Башкалар аны чыгып китте дип уйлыйлар.

Ибраһим. Ат таүга житкәч адымын кызулата. Сине әйтәм, бик ярсынып тотындың. Әллә инде таүга якынлашып киләсең?

Нияз *(җитди)*. Ибраһим абый, эшемнең нәтиҗәсе күренә башлады кебек. Җәнлекләрдә шактый сынау үткәрдем. Хәзер инде препаратның кеше организмына ничек тәэсир иткәнен, куркынычлы түгелме икәнлеген сынарга да вакыт житте кебек. Беренче чиратта, әлбәттә, үземдә сынап карамакчы булам.

Ибраһим. Уйламыйча эшли күрмә. Мондый чакта житмеш мәртәбә үлчәгәч кенә кисәргә кирәк. Ашыгырга ярамый.

Нияз. Мин аның нәтиҗәсенә тәмам ышангач кына тәвәккәлләячәкмен.

Ибраһим. Сак була күр.

Нияз. Эх, белсәгез иде, Ибраһим абый, яхшылык эшлисе килә. Кешеләрне куандырасы килә. Дөньяда шуннан да зур бәхет юктыр.

Нияз чыгып китә. Розалия, штора артыннан чыгып, Ибраһимны җиңеннән тотып алып кала.

Розалия *(агарынган)*. Ибраһим абый.

Ибраһим. Син каян килеп чыктың тагын?

Розалия. Куркыныч түгелме ул?

Ибраһим. Нәрсә?

Розалия. Нияз абый үзендә сынау ясамакчы була ич.

Ибраһим *(кетмәгән иде)*. Әйтәм ич, бездә стеналар да ишетә дип.

Эчке пәрдә төшә

*(Дәвамы киләсе санда.)*

*Рәдиф Гатауллин*

## Рениза

Бүй-бүй кофта... зәңгәр күлмәк...
Бантиклы чәч, зәңгәр күзләр.
Кыз биеми, гүя йөзә.
— Сез кем! — дидем мин.
— Рениза.

Өянкеләр сакка баскан,
Инеш буен томан япкан.
Яр сукмагы тарын тар да,
Серле дөнья ул — яшь парга...
Көн дә кичен икәү уза:
Берсе — мин, берсе — Рениза.

Бантиклы чәч, зәңгәр күзләр...
Кабынып, әйттең үпкә сүзләр.
Без аерылдык. Яшьлек уза.
Сине сагынам мин, Рениза!

Бу истәлек кенә түгел,
Бу — язмышлар турында җыр.
Я — ялгышлар турындадыр.
(Ә ялгышны төзәтү авыр.)
Ни булса да,
Онытылмаска туган бу җыр!

Син ерак та түгелсеңдер,
Минем юлдан йөрисеңдер;
Очрашырбыз, күңел сизә:
Бантиклы чәчең үскәндер, —
Зәңгәр күз ачыла төшкәндер, —
Бәлки йөзеңдә моң йөзә.
Танымасам, — син кем! дисәм,
Әлеккечә әйт:
— Ре-ни-за!

## Идеал

Әйе, син идеал түгелсең.
Идеал ерак. Ә син якын.
Идеал — гомер буе эзләп табыла
һәм табылмый,
ә мин сине таба алдым, һәм тиз таптым.
Чәчләреңнән сыйпыйм синең,
күзләреңә карыйм.
Башым — тезләреңдә.

Колак салам жылы, реаль сүзләреңә.
— Ә соң идеал! Таптыммы аны, югалтыммы!
Әллә сине күргәч, инде юандыммы!
Идеал!
— Ул һаман да бар.
Ләкин ерак...
Ул — ут, йолдыз —
алда яна,
һаман янар!
Ерак булмаса идеал,
Башка исем йөртер иде:
— Гөл, тәрәзә... рифма өчен әйтик: одеял...
Юк, син идеал түгелсең.
Тормышым син, бәхетем син.
Идеал исә — сүнмәс хыял.
Киләчәгем —
якыным түгел.
Идеал — мәңгелек кыз, образ —
дусым яки хатыным түгел!

●

Кадерлем, Кояш кызы син,
гөлләрнең сеңелесе син.
Чәчләрең белән шаярган
җилләрдәй күңеллесең.
Кадерлем, Кояш кызы, син —
бәхетнең бер туганы.
Шатлыкның нәкъ ай кебеге —
түгәрәге, тулганы.
Кадерлем, якты уем син;
Мин дә шул Кояш улы,
сөюем дә шул нурлардан,
күңелемдә Кояш тулы.
Гөл кебек күз сирпеп көлдең
тормышым юлларына.
Җәяүләп килгән бәхетем син,
кушылдың җырларыма.
Язмышым, Кояш кызы син,
көннәрнең алгысына
бергәләп чыгыйк: мин риза
Кояшлы язмышыма!

●

Мин — элекке һаман. Ә бит —
Үзем кебек күреп ышандым да
Дусларыма, азмы ялгыштым.
Дошман түгел, алдаган дус бирде
Иң ачысын миңа сагышның.
Реаль дөнья белән бәрелешеп,
Йөрәк инде азмы кыйналды! —
Мин элекке һаман:
Мин Дон Кихот,

Гомерлеккә алган идеаллы.
Дуслар хискә саран булды кайчак,
Яшеренделәр алар, мин түгел...
Алар акыллы иде.
Мин беркатлы,
Беркатлы да инде киң күңел!
Мин һаман шул: туктар чакта ашыгам.
Ашыгасы җирдә тукталам.
Мин яшеренми сөям,
мактыйм, тиргим,
Матурлыкка һәрчак сокланам.
Мин элекке. Эзлим һаман, табам
Һәм арына барам ялганнан.
Дусларымнан бәлки алданырмын,
Дусларымны үзем алдамам!

## Әгәр...

Әгәр мәхәббәт эшендә
шундый кенәгә туса;
жалоба, мактау, тәкъдимнәр
языла торган булса.
Жалоба язган кенәгә
җирдән зур булыр иде...
Мактау сүзләре җыелса —
океаннар тулыр иде.
Яңа туфан калкыр иде
тәкъдимен язса Кеше...
Әллә нинәр булыр иде,
аллага шөкер! — мәхәббәт
һәркемнең яшерен эше.

*Михаил Шолохов*

# КҮТӘРЕЛГӘН ЧИРӘМ

*Романнан өзек*

Июнь башларында, җәйгә хас булмаганча, күз күнендәге кебек, яшенсез, җилсез, тыныч яңгырлар ява башлады. Иртәләрен көнбатыш яктагы сыртлыклар артыннан күлсу-күк болыт калкып чыга һәм, үсә, җәелә барып, ярты күк йөзен каплап ала, болытның кара-кучкыл итәкләре дәһшәтле булып агара, аннары кисеядәй юка аскы сәләмәләре даладагы курган өстендә торган жил тегермәненең түбәсенә тиярдәй булып түбән төшә; кайдадыр өстә, биектә, чак-чак ишетелерлек юаш калын тавыш белән күк гөлдерәп-гөлдерәп куя һәм шуның артыннан шифалы яңгыр ява башлый.

Яңа сауган сөт шикелле җылы яңгыр тамчылары, томанлы тынлыкта яткан җир өстенә төшеп, кибеп тә өлгермәгән күбекле күләвекләргә ак куыклар булып тамалар; бу җәйге сирәк яңгыр шундый тыныч, шундый юаш, хәтта чәчәкләр дә башларын имиләр, ишек алдында йөргән тавыклар да ышыкка йөгермиләр, каралты-кура тирәсендә, юешләнеп каралыбрак киткән читәннәр буенда мәш килеп тарана-тарана җим эзлиләр, ә яңгырга чыланып беркадәр мәһабәтлекләрен җуйган әтәчләр, яңгыр яуганга да карамастан, чиратлашып, сузып-сузып кычкыралар, аларның шаулатып кычкырган көр авазларына яңгыр суында коенган чыпчыкларның чыркылдашуы, яңгыр һәм тузан исе аңкытып ягымлы булып яткан җиргә таба атылып-атылып очкан карлыгачларның чыелдашулары кушыла.

Шунсы гаҗәп: Гремячий Логта һәр әтәчнең үзенә хас тавышы бар икән. Төн уртасы җиткәч, иң алдан уянып, әтәчләр кычкыруын Любишкиннар әтәче башлап җибәрә. Ул, тырыш, яшь рота командиры шикелле, яңгырап торган көр тавыш белән сузып кычкырып җибәрә; аңа полковникларныкыча олы сымак калын тавыш белән Агафон Дубцовлар әтәче җавап кайтара; шуннан соң инде биш минутлап бөтен хуторда тоташтан әтәчләр кычкырган тавыш шаулап тора, иң соңыннан гына, йокысыннан уянгач, ко-ко килеп кунакчада көчле канатларын шапылдата-шапылдата, генералларча карынкы юаш тавыш белән, командирларча тамак ярып, Майданниковларның хутордагы иң карт, симез кызыл әтәчләре үкереп җибәрә.

Гыйшык тотучылар һәм каты авырулардан кала (Нагульнов боларның икесе бер иш дип карый иде), Макар үзе хуторда иң соңгы кеше булып йокыга китә. Ул, төнге ял сәгатьләре исәбенә, тырышып-тырышып инглиз телен өйрәнә. Аның бүлмәсендә урындык аркасына киндер сөлге элеп куелган, почмакта салкын кое суы салынган кувшин тора. Гыйлем дигәнең бик авыр бирелә Макарга. Әнә ул, тиргә баткан, чәчләре тузган, күлмәк изүләрен чишеп җибәргән килеш, тутырып ачып куелган тәрәзә буендагы өстәл янында тел өйрәнеп утыра,

тирләгән маңгаен, култык асларын, күкрәген, аркаларын сөлге белән сөртә, вакыт-вакыт, тәрәзәдән тышка сузылып, рәхәтләнеп эһелди-эһелди, кувшиннан башына салкын су да коеп ала.

Өстәлдә тонык кына булып бишле лампа янып утыра, гәзит кәгазеннән ясап куйган абажурга төнге күбәләкләр килеп бәрелә, стенаның теге ягында хуҗа карчык хырылдап йоклап ята, ә Макар үзе өчен бик кирәкле булган әлеге коточкыч авыр телне әкренләп сүзләп-сүзләп җиңә килә... Беркөнне ул төн уртасында, ял итәргә туктагач, тәрәзә төбенә тәмәке тартырга килеп утырды һәм шунда беренче тапкыр чын-чынлап этәчләр хоралын ишетте. Макар, шаккатып, бик бирелеп тыңлап торды да: «Парадтагы кебек бит бу, дивизия смотрындагы шикелле! Гаҗәп тамаша!» — дип куйды.

Шуннан бирле ул һәр төнне этәчләр кычкырганны көтеп ала башлады, чут-чут итеп сандугачлар сайраганны күңеле белән өнәмичә, таң этәчләренең командирларча аваз салып кычкыруларын рәхәтләнеп тыңлап тора торган булды. Бигрәк тә аңа генералларча калын тавышлы Майданниковлар этәче ошый, аның тавышы гомум этәчләр хорында соңгы аккорд булып яңгырый кебек иде. Тик бер көнне аның күңеленә ошаган гадәттәгечә кычкыру тәртибен бер дә көтмәгәндә хулиганнарча бозып җибәрделәр: Майданниковлар этәченең куәтле калын тавышыннан соң якында гына, сарайның теге ягында, күрше Аркашка Менок йортында, малайларча чая тавыш белән яшь кенә бер этәч сәламәсе кычкырып куйды һәм шуннан соң, бугазына нидер төелеп, байтак вакыт тавык шикелле кыткылдап азапланды. Аннары, тынгач, Макар әлеге этәч сәламәсенең, канатларын шапылдата-шапылдата, кунакчага җайлабрак кунаклап маташуын ишетте: үз тавышыннан үзе сискәнеп, кунакчадан егылып төшмәгәем, дип курыкты, күрәсең.

Бу хәл күрәләтә тәртип бозу һәм үзеңнән зур дәрәҗәлеләрне бөтенләй санга сукмау иде. Макар күз алдына китергәнчә, бу хәл чын генералдан соң сакау телле берәр надан бүлекчә командирының генералны төзәтеп, сөйли башлавы кебек иде. Макар мондый тәртипсезлеккә түзеп кала алмады, караңгыга карап: «Отставить!..» — дип кычкырды да, авыз эченнән сүгенә-сүгенә, тәрәзәне шап иттереп ябып куйды.

Әлеге хәл икенче, өченче төнне дә кабатланды. Макар, хуҗа карчыкны сискәндереп, тагы ике тапкыр, караңгыга карап: «Отставить!» — дип кычкырды. Таң этәчләренең кайсысы кайчан тавыш бирергә тиешлеге дәрәҗә зурлыгы буенча тезелгәндәй, тәртип белән, килешле, матур итеп кычкырулары бөтенләй бозылды. Һәм шуннан соң Макар төн уртасы узгач ук йокларга ята башлады... Хәзер ул әллә нинди инглиз сүзләрен ятлап, өйрәнеп утырырлык хәлдә түгел иде инде. Уйлары һаман шул эрсез этәч тирәсендә чуала иде. Бу этәч тормышта да, хуҗасы кебек, мәгънәсез, җүнсез бер нәрсәдер дип уйлады Макар. Шул гаепсез кошны күңеленнән кабахәт, паразит, мактанчык дип сүкте. Майданниковларның этәченнән соң кычкырып маташкан бу күрше этәче аны тәмам чыгырыннан чыгарды: инглиз телен өйрәнү сәләте бөтенләй кимеде, аның көннән-көн кәефе китә барды... Мондый тәртипсезлеккә чик куярга вакыт иде!

Дүртенче көнне иртән ул Аркашка Меноклар ишек алдына килеп керде һәм, коры гына исәнләшеп, хуҗага:

— Кая, этәчеңне күрсәт әле, — диде.

— Нигә кирәк булды әле сиңа ул этәч? — диде Аркашка.

— Кыяфәтен күрәсем килә.

— Ни шайтаныма кирәк сиңа аның кыяфәте?

— Давай күрсәт! Минем монда синең белән гәпләшеп торырга вакытым юк! — диде Макар, ачуы кузгала башлап.

Ул тәмәке төрә торган арада, Аркашка, кулына чыбык тотып, амбар астыннан бер көтү тавык куалап чыгарды. Шулай буласы билгеле инде!

Макар дөрес уйлаган икән: матур-матур чуар каурыйлы, җиңел акыллы дистәләгән мут тавык арасында тычкан тиресе төсле күк каурыйлы өтек кенә бер әтәч бөтерелеп йөри иде. Макар нәфрәтле бер чырай белән әтәчкә күз йөртеп алды да Аркашкага таба борылып:

— Суеп ташла син бу әтәч сәләмәсен! — диде.

— Нәрсә суйыйм мин аны?

— Шулпага, — диде Макар.

— Ни сәбәптән суйыйм? Минем бөтен йортка бер әтәч бит ул, тавыклар янында да бик йөри.

Макар, авызын кыйшайтып, мыскыллы гына көлеп куйды:

— Тавыклар янында йөрүдән башка сәләте юкмы? Һи, исең киткән! Анысын аның җүләр дә булдыра.

— Соң, ул әтәчтән бүтән эш соралмый да бит, анын белән бакча сукаларга җыенмыйм, бер тәрәнле сабанны да тарта алмый ул...

— Ярый, юкны сөйләнеп торма! Кирәк чагында мин үзем дә юк-бар сөйләүне булдырам...

— Минем әтәчнең сиңа ни зыяны тиде соң? Юлыңа аркылы төшкәнме, ниме? — диде Менок, түземсезләнә башлап.

— Синең бу әтәчең җүләр ул, бернинди тәртип белми.

— Нинди тәртип ул тагы? Синең хуҗаның бакчасына керәме, ниме?

— Бакчага керми ансы, болай, гомумән...

Макар нинди тәртип турында әйткәнен аңлатып бирергә уңайсызланды. Аякларын аерып баскан килеш, күзе белән әтәчне ашардай булып, беравык дәшми торды, аннары күңеленә ниндидер бер уй төшеп, җанланып китте:

— Беләсеңме, күрше: әйдә әтәчләрне алмашыйк?

— Синең атсыз-җирсез хуҗалыгыңа әтәч каян килсен ул? — диде Менок, кызыксына башлап.

— Табарбыз ансын, бу өтектән җүнлерәген табарбыз.

— Әйдә, алайса китер, әтәчең ярардай булса, алмашырбыз, мин үземнекенә ябышып ятмыйм.

Ярты сәгатьтән соң Макар, үтеп барышлый гына сугылгандай, Аким Бесхлебновлар йортына килеп керде. Аларның байтак кына тавыклары бар иде. Тегене-моны сөйләшкән булып, Макар ишек алдында йөргән тавыкларны караштырды, әтәчләрнең ничек кычкыруына игътибар итте. Бесхлебновларның биш әтәчләре дә сайлап алгандай бик буйлы, матур каурыйлы, ансыннан да бигрәк: бишесенең дә тавышы көчле, килеш-кыланышлары да бик җилле иде. Саубуллашып китәр алдыннан гына Макар:

— Карале, хуҗа, бер әтәчеңне сатмассыңмы миңа, ә? — диде.

— Рәхим итәсең, иптәш Нагульнов, шулпада пешкән тавык ите бик тәмле була бит ул, теләсәң кайсын ал, хатынның тавыклары күп!

— Юк, миңа әтәч кенә кирәк. Шуны салырга бер капчык та биреп тор.

Бераздан соң инде Макар Аркашка Меноклар ишек алдында капчык авызы чишеп маташа иде. Алыш-бирешкә бик хирес Аркашка, бу эшкә бик сөенеп, кулларын угалый-угалый сөйләнеп тора иде:

— Карап карыйк, кузырың ниндидер бит, бәлки өстәү дә сорарбыз әле. Әйдә, тизрәк чиш инде, маташма! Мин хәзер үземнең әтәчне тотам. Сугыштырып карыйбыз: кемнеке җиңә, шуңа мәгәрич тия. Валлаһи, шунсыз алмашмыйм да! Синеке нинди рәк соң? Зурмы? — диде.

Макар, чиләнеп беткән төенне теше белән чишә-чишә:

— Гвардеец! — дип мөгрәп куйды.

Аркашка, бер кулы белән чалбарын тотып, кетәклеккә йөгерде. Озакламый аннан күкле-яшелле әтәч тавышы ишетелде. Аркашка, коты алынган әтәчне куенына кыстырып, бирегә таба килгәндә, Макар, авызы чишелгән капчык өстенә иелеп, җилкәсен кашып тора иде: «гвар-

дееҗ» канатларын салындырып капчыкта ята, әҗәл газабыннан бөрләгәндәй алсу күзләрен акайткан иде.

— Ни булган моңа? — дип аптырап сорады Аркашка.

— Осечка булган!

— Чирле нәрсәкәймени?

— Осечка булган дип әйтеп торам бит.

— Әтәчнең нинди осечкасы булсын? Әлләниләр сөйлисең син!

— Әтәч түгел, аңгыра адәм, үзем осечка биргәнмен. Монда алып килгән чакта капчыкта кычкырып маташа, халык алдында мине хур итмәкче була — идарә яныннан узып бара идем, — ну, мин моның чак кына башын бордым... Әз генә борган шикелле идем, баксаң, менә ничек килеп чыккан икән. Бар, балта китер, үлеп әрәм булмасын.

Макар башы чабылган әтәчне читән аркылы ыргытты да баскыч тирәсендә эшләп йөргән хуҗа хатынга:

— Әй, апасы! Суынганчы йонын йолкып ташла, иртәгә шуны салып аш пешерерсең! — дип кычкырды.

Аркашкага ләм-мим сүз әйтмичә, янадан Бесхлебновларга китте. Аким баштарак: «Болай син минем бөтен тавыкны тол калдырырсың!» — дип карышып маташкан иде дә, аннары икенче әтәчен дә сатып җибәрде. Макар кире килеп, Аркашка белән алыш-биреш ясадылар, ә берничә минуттан соң инде Аркашканың теге әтәче, башы чабылып, читән аша ишек алдына очты, моңа бик кәефе килгән Макар исә шуның артыннан ук хуҗа хатынга:

— Ал шул мыркыргырыны, апасы! Ул тәртипсез ләгънәтне йолкы да казанга сал! — дип кычкырды.

Бик кирәкле зур бер эш эшләгән кеше шикелле, урамга чыгып китте. Макарның алар ишек алдына килеп әтәч җаны кыеп йөрүенә шаккаткан Аркашка хатыны, исе-акыллары китеп, аның артыннан башын чайкап карап калды. Аркашка исә, хатынының сүзсез аптырап торуын күреп, имән бармагын маңгаена куеп боргалады да пышылдап кына:

— Акылыннан авыша башлаган! Әйбәт кенә кеше иде бит үзе югыйсә. Тәмам акылы ычкынган, башкача түгел. Төннәр буе күпме утыра бит мескен! Шул каһәр суккан англи телләре белән тәмам барып чыккан инде! — диде.

Шул көннән соң ялгызлыкка бирешми яшәгән Макар төннәрен әтәчләр кычкырганны янадан берниндп комачаусыз тыңлый башлады. Ул хатын-кыз, бала-чагалар белән бергә көн озын басуда утау утый, ә кичен кысыр кәбестә ашы һәм сөт белән генә тамак ялгый да кулына инглиз теле дәреслеген алып утыра һәм төн уртасы җиткәнне көтә иде.

Озакламый бу эшкә Щукарь карт та кушылды. Беркөнне кич ул әкрен генә ишекне шакыды да:

— Керергә рөхсәтме? — дип сорады.

— Кер. Ни йомыш белән килдең? — дип, Макар аны шактый төксе чырай белән каршы алды.

— Ничек дип әйтим инде... — дип аптырабрак калды Щукарь. — Бәлки, үзеңне бик сагынганмындыр, Макарушка. Тукта, мәйтәм, уты бар, кереп хәлен белеп чыгыйм әле, дидем.

— Син, нәрсә, мине сагынырга хатын-кызмы әллә?

— Карт кеше бит ул кайвакыт хатын-кыздан да тегеләйрәк сагынучан була. Минем эшне үзең беләсең, бик кысыр эш: һаман да шул айгырлар карау. Ул телсез хайваннардан туеп, гарык булдым инде! Әйтик, син аңар тәмле теленне әрәм итеп сүз кушасың, ә ул сиңа ләм-мим бер сүз дәшми, керт-керт солы ашавын гына белә, койрыгын гына селкә. Аннан миңа ни мәгънә? Җитмәсә тагы, каһәр суккан теге кәҗә тәкәсе! Кайчан йоклый ул бәҗәк, ә, Макарушка? Төнлә йоклыйм дип күзне генә йомасың, килә дә житә бит, мөртәт. Мин йоклап ятканда ничәмә тапкыр өстәмә тоягы белән китереп басканы бар! Котларымны

ала, шуннан соң инде, күземне төртеп чыгарсаң да, күзгә йокы керми. Шундый каһәр суккан әшәке бер бөҗәк — кешегә һичбер тынгылык бирми! Төн буе әле абзарда, әле печәнлектә йөри. Макарушка, әйдә суйыйк шуны?

— Бар, әйдә, юк сүз сөйләп торма монда! Идарә кәҗәләренә мин хуҗа түгел, аларга Давыдов баш, аның янына бар.

— Ходаем, мин бит кәҗә тәкәсе турында сөйләшергә дип килмәдем, просто хәлеңне белим дип кенә кердем. Миңа да берәр мавыктыргычлырак китап бир әле. Мин синең янда, ярыктагы тычкан кебек, тып-тыныч утырырмын. Сиңа да күңелле, миңа да күңелле булыр. Бертек тә комачауламам!

Макар бераз уйланып торды да риза булды. Щукарьга рус теленең аңлатмалы сүзлеген тоттырып:

— Ярар алайса, утыр, тик, кара аны, эчеңнән генә укы, ирененңне дә чапылдатма, йөткермә дә, төчкермә дә — кыскасы, бернинди тавыш чыгарма. Тәмәкене минем команда буенча гына тартабыз. Мәсьәлә аңлашылдымы? — диде.

— Барысына да ризамын, ә менә төчкерү мәсьәләсендә ничегрәк икән? Әгәр дә, әйтик, искәрмәстән, шайтан коткысы белән, төчкерәсем килсә, ул чагында нишләргә? Минем эш шундый бит: борынга гел печән чүбе тула. Кайвакыт йоклаганда да төчкерәм. Ул чагында нишләрбез икән соң?

— Пуля кебек, чоланга атылып чык!

— Эх, Макарушка, мин инде бернигә яраксыз, күгәргән пуля хәзер! Чоланга йөгереп чыгып җиткәнче мин ун тапкыр төчкереп, биш тапкыр борын сеңгерәм.

— Әй син, картлач, ашыга төш!

— Бер кыз шулай кияүгә чыгарга ашыккан да, ди, кияү табылмаган, ди. Шунда бер яхшы бәндә килеп чыгып, кызга ярдәм иткән, ди. Беләсеңме, никахсыз-нисез дә кыз нинди булган, ди? Бик әйбәт хатын булган, ди! Минем белән дә шулай булуы бар шул: ашыгырмын да йөгергән чакта гөнаһлы булып куярмын, аннары мине моннан куып ук чыгарырсың, аксы инде көн кебек ачык!

Макар көлеп җибәрде:

— Әй син ипләбрәк ашык, авторитетыңны саклабрак йөр. Кыскасы, дәшмә-сөйләшмә, мине эшемнән бүлдермә, укып, культуралы карт бул.

— Тагын бер генә сорау бирергә мөмкинме? Кашыңны җыерма инде, Макарушка, соңгы соравым.

— Я? Тиз бул!

Щукарь карт утырган урынында уңайсызланып кыбырсый-кыбырсый сөйләнергә керешә:

— Беләсеңме, нинди нәрсә: нәрсә дип, әллә нәрсә дә түгел инде ул үзе, шулай да андый эш өчен карчыкның миңа бик яман кәефе китә: «Йокларга бирмисең!» — ди. Ә минем анда ни гаебем бар?

— Мәсьәләне кыскарак тот!

— Менә шул мәсьәләне әйтәм дә шул. Минем, бүсердәнме, бүтән авыруданмы, бик яман эчем үкерә, яшен болыты шикелле гөлдери! Ул чагында нишләрбез соң? Монда да эштән аеру буладыр бит?

— Чоланга йөгер, бернинди яшен яшьнәү, күк гөлдерәү булмасын! Мәсьәлә аңлашылдымы?

Щукарь сүзсез генә баш какты да, авыр сулап куеп, сүзлекне ачты. Төн уртасы җиткәч, ул Макар җитәкчелегендә, аның аңлатмаларыннан файдаланып, гомерендә беренче тапкыр әйбәтләп этәчләр кычкырганны тыңлады, ә өч көннән соң икәү, иңгә иң терәлеп, корсаклары белән тәрәзә төбендә ятканда, Щукарь карт таң калып:

— Ярабби, ярабби! Гомерем буе шул этәчләрнең койрыкларына басып йөрдем, сабый чагымнан ук тавыклар арасында үстем, ә шулар-

нын шундый да матур тавышлы икәнен белмәгәнмен. Ну, хәзер ихласландым инде! Макарушка, әнә теге Майданниковлар мөртәтә ничек сузып кычкыра бит, ә? Хас генерал Брусилов инде, койган да куйган! — дип сөйләнде.

Макар кашын җыерды, бик үк ихласланмыйча, пышылдап кына җавап кайтарды:

— Таптың, — диде. — Менә син безнең генералларны тыңлап карасаң икән, картым, — менә аларда чын тавыш, ичмасам! Нәрсә ул синең Брусиловың? Беренчедән, ул элекке патша генералы — димәк, минем өчен шикле әдәм ул, икенчедән, күзлекле бер интеллигент. Аның тавышы да теге без суеп ашаган Аркашкалар әтәченеке шикелле генә булгандыр. Тавышны да политик яктан аера белергә кирәк. Әйтик, мәсәлән, безнең дивизиядә бер калын тавыш бар иде — бөтен армиягә бер тавыш иде! Эт җан булып чыкты бит шул: аклар ягына качты. Шул тавыш минем өчен хәзер дә яхшы тавыш дисеңме? Булмый гына торсын! Хәзер ул минем өчен яхшы тавыш түгел, кабахәт бер сатлык җан тавышы!

— Макарушка, әтәчләргә политика кагылмый түгелме соң? — дип, Щукарь карт өркә-өркә генә сорау бирде.

— Әтәчләргә дә кагыла! Майданниковлар әтәче урынында берәр кулак әтәче булса, мин ул паразитны гомеремдә дә тыңламас идем! Ни шайтаныма хаҗәт миңа ул кулак койрыгы!.. Ярый, сөйләштек — булды! Син үз китабыңны укырга утыр, мин үз китабымны, ахмак сорауларың белән мине борчыма, югыйсә кудым-чыгардым!

Шулай итеп Щукарь карт ихлас күңелдән әтәч тавышы яратучы булып китте. Майданниковлар әтәчен барып карарга да Макарны ул котыртты. Алар, эш белән йөргән сыман, Майданниковларның ишек алдына килеп керделәр. Кондрат үзе кырда пар сөрә иде. Макар аның хатыны белән сөйләште, сүз арасында гына сорагандай: «Нигә син утауда түгел?» — диде, ә үзенең күзе ишек алдында түшен киереп эре генә йөргән әтәчтә иде. Әйбәт кенә килеш-килбәтле, матур кызыл каурыйлы бер әтәч иде бу. Макар әтәчтән бик канәгать булды. Капкадан чыкканда тынсыз-өнсез калган Щукарьга терсәге белән генә төртте дә:

— Я, ничек? — дип сорады.

— Килеш-килбәте дә тавышына бик туры килә. Әтәч түгел, архирей бу! — диде Щукарь.

Картның мондый чагыштыруын ошатмаса да, Макар сүз әйтмәде. Алар инде идарә йорты янына җитеп киләләр иде, шул вакыт Щукарь, күзләрен алартып, Макарның гимнастерка җиңеннән тотты да:

— Макарушка, суюлары мөмкин бит! — диде.

— Кемне? — диде Макар.

— Ах алла, мине түгел лә инде, әтәчне! Суячаклар, валлаһи! Чын әгәр, суячаклар!

— Ни өчен суячаклар? Ни сәбәптән? Нәрсә сөйлисең син — һич аңламыйм!

— Нәрсәсен аңламаска? Картаеп-череп беткән бер әтәч бит инде ул, яше белән миңа кордаш тиешле, шәт, картрак тадыр әле. Мин ул әтәчне малай чагымнан бирле беләм!

— Алдашма, бабай! Әтәч житмеш ел яшәми, табигать законнарында ул турыда бер сүз дә язылмаган. Белдеңме?

— Барыбер карт инде ул, сакалындагы каурыйлары агарып беткән. Әллә күрмәдеңме? — дип кызып бәхәсләште Щукарь.

Макар ялт кына кире борылды. Һәм эре-эре атлап шундый кызу китте, аның артыннан ияргән Щукарь карт вакыт-вакыт юргалый үк башлый иде. Берничә минуттан алар тагы Майданниковлар ишек алдына килеп керделәр. Макар Лушкадан истәлеккә калган челтәр кырыйлы хатын-кыз кулъяулыгы белән тирләгән маңгаен сөртә, Щукарь

карт ярты көн буе төлке куган ау эте шикелле әлсерәп сулу ала, алсу тел очыннан сакалына вак кына селәгәй тамчылары тама иде.

Кондратның хатыны, ачык кына елмаеп, болар янына килде.

— Берәр нәрсәгезне онытып калдырдыгызмы әллә?

— Сиңа шуны әйтергә онытканмын, Прохоровна: әтәчеңне суясы булма.

Щукарь карт, көянтәдәй бөгелеп, бер кулын алга сузды һәм, каралып беткән имән бармагын йөртеп, мышный-мышный, көч-хәл белән:

— Алла сакласын берүк андый эштән!.. — дип куйды.

Макар ризасыз бер кыяфәттә картка күз кырые белән генә карап алды да сүзен дәвам иттерде:

— Без аны синнән колхоз өчен нәселгә дип сатып яки алмаштырып алырга уйлыйбыз, ник дигәндә, килеш-килбәте белән бу әтәч зат нәселле булырга тиеш, аның бабалары, бездә яңа токым үрчетү өчен, Англиядән яки Голландиядән үк китерелгән булуы ихтимал. Борын өсте орылы галански ата казлар буламы? Була. Бәлки, бу әтәч тә галански милләттәндер, — син аны белмисең бит? Ну, мин дә белмим, шулай булгач, аны һич суярга ярамый.

— Нәселгә ярарлык түгел бит инде ул, бик карт, без аны троицага суймакчы идек, үзебезгә яшьне алмакчы идек.

Бу юлы инде, Щукарь карт, әйттемме мин сиңа? — дигәндәй, Макарга терсәге белән төртеп алды, ләкин Макар аның төртүенә игътибар итмәде, хуҗа хатынга үзенекен сөйли бирде:

— Картлык гаеп түгел ул, без аны нәселгә куярбыз, аракыда җебетеп бодай ашатырбыз, шуннан соң тавыклар янында бөтерелеп йөри башлар ул — тәтеннәр чыгарыр! Кыскасы, шул: мондый кыйммәтле әтәчне бер ничек тә юк итәргә ярамый. Мәсьәлә аңлашылдымы? Аңлашылса, бик яхшы! Ә Щукарь бабай сиңа бүген үк яшь әтәч китереп бирер.

Макар шул көнне үк Демка Ушаков хатынынан әтәч сатып алып, Щукарь карттан Майданниковларга илттерде.

Соңгы комачаулык та бетте кебек иде инде. Ләкин хуторда, Макар Нагульнов ни өчендер берәмләп-берәмләп тә, күпләп-күпләп тә кешеләрдән әтәч сатып ала икән, шуларга әллә ничаклы акча түли, имеш, дигән сүз таралды. Мәзәк яратучан Размётнов мондый хәлгә игътибарсыз каламы соң инде? Дустының бу сәер хикмәтләрен ишеткәч тә, ул үзе барып тикшерергә булды һәм кич соң гына Нагульнов янына квартирына килде.

Макар белән Щукарь карт, калын-калын китаплар өстенә иелеп, өстәл янында утыралар иде. Филтәсе кирәгеннән артык чыгарылганга, лампалары төтәп утыра. Бүлмә эчендә корым очып йөри, лампа пыяласына кигезгән кәгазь абажурдан көйгән кәгазь исе таралган иде. Бүлмә башлангыч мәктәпнең беренче классында матур язу дәресе вакытындагы шикелле тып-тын иде. Размётнов шакымый гына килеп керде дә бераз ишек төбендә йөткеренгәләп торды, ләкин укуга чумганнарның берсе дә аңа игътибар итмәде. Шуннан соң ул, елмаюын көчкә тыеп, каты гына тавыш белән:

— Иптәш Нагульнов биредә торамы? — дип сорады.

Макар, башын күтәреп, Размётновның йөзенә текәлде. Юк, төнге кунак эчмәгән-исермәгән, шулай да, көлүен тыя алмаганга, иреннәре кыймылдап-кыймылдап китә иде. Макарның күзләре тонык кына ялтырап, кысыла барды. Тыныч кына тавыш белән ул:

— Андрей, кызлар янына аулак өйгә бар син, минем бушка әрәм итәргә вакытым юк, — диде.

Размётновның күтәренке кәефен уртаклашырга аның бер дә исәбе юк иде. Моны сизеп, Размётнов эскәмиягә утырды, тәмәке кабыза-кабыза, җитди итеп:

— Юк, чыннан да әйт әле: син ул этәчләрне нәрсәгә сатып алдың? — дип сорады.

— Токмач ашы белән кәбестә шулпасына салырга. Әллә син мине ул этәчләрдән хутор кызларына мороженый ясый дип беләеңме?

— Мороженыйга дип уйлавын уйламадым да, ләкин бик гаҗәпкә калдым: нәрсәгә монар шул хәтле этәч кирәк булды икән, мәйтәм, һәм ни өчен этәч, мәйтәм?

Макар көлемсерәп куйды:

— Токмач ашында пешкән этәч кикриген бик яратам — менә шуңа ул. Син минем этәч сатып алуыма гаҗәпләнгәнсен, ә мин менә, Андрей, шунсына гаҗәпләнәм: нигә утауга йөрмисең икән син?

— Мина анда нишләргә кушасың соң син? Хатыннарга күз-колак булыргамы — аның өчен бригадир бар бит.

— Күз-колак булырга түгел, үзең утау утарсың.

Размётнов, кулын селкеп, көлеп җибәрде.

— Хатыннар янында эт какысы йолкып йөриммени? Юк инде, гафу итәсең, агай-эне! Чүп утау ирләр эше түгел ул. Шуның өстенә, мин андый-мондый гына кеше дә түгел, бәлки авыл Советы председателе.

— Әллә ни зур түрә түгел дә. Тирәңә күрә генә түрә! Нишләп мин бүтәннәр белән беррәттән эт какысы йолкып йөрим дә, син йөри алмыйсың?

Размётнов җилкәсен сикертеп куйды.

— Йөри алмаудан түгел, ә просто казаклар алдында дәрәҗәмне төшерәсем килми.

— Әнә Давыдов бер эштән дә тартынмый бит, мин дә шулай, ә нигә син фуражкаңны кыңгыр салып кына көн озын үзеңнең Советыңда утырасың, я булмаса, майланып беткән кәгазь портфелеңне култыгына кыстырасың да тиктомалга хутор буйлап йөрисең? Семья хәле турындагы белешмәне секретарең гына язып бирә алмыймыни? Андый гадәтеңне ташла син, Андрей! Иртәгә үк беренче бригадага барып, граждан сугышы геройларының ничек эшләгәнен хатыннарга күрсәт!

— Акылыңнан ук яздыңмы син, әллә шаяртасың гынамы? Үтер шушында, — барыбер бармыйм, — дип, Размётнов ачу белән тәмәке төпчеген атып бәрде дә эскәмиядән сикереп торды. — Кеше көлдереп йөрергә теләмим! Чүп утау ул ирләр эше түгел! Бәлки, тагы бәрәңге төбе өяргә дә кушарсың?

Макар, карандаш кисәге белән өстәлгә тыныч кына суккалап:

— Партия нинди эш кушса, барсы да ирләр эше. Мәсәлән, мина: Нагульнов, бар, контрларны кыр, — дип әйтәләр икән, мин рәхәтләнеп барам! Бәрәңге төбе өй, дип әйтәләр икән, рәхәтләнеп булмаса да, барамын. Бар, сыер сау, дип әйтәләр икән, тешем кысып булса да, барыбер барам! Ул мүркыргыры сыерны имчәкләреннән тартып-йолкып булса да барыбер савам, булдыра алган кадәр эшләргә тырышам!

Размётновның ачуы бераз сүрелә төшеп, кәефе ачылыбрак китте.

— Нәкъ синең куллар инде сыер сава торган. Син аны шундук тартып егасың бит! — диде ул.

— Ексам, кире торгызырмын, әмма җинеп чыкканчы, соңгы тамчы сөтен сыгып чыгарганчы савармын. Беләеңме? — диде Макар һәм, каршы җавап та көтмәстән, уйчан бер кыяфәт белән сүзен дәвам иттерде: — Ул турыда уйла әле син, Андрюха, үзеңнең ир булуың, казак булуың белән артык масайма. Безнең партиялелек намусыбыз анда түгел, минемчә. Өченче көн шулай районга яңа секретарьга күренергә барам. Юлда Тубянскойның ячейка секретаре Филонов очрый. «Кая сәфәр тотасың, райкомга түгелме?» — ди бу. Райкомга, мин әйтәм. «Яңа секретарь янынамы?» — ди. Әйе, мин әйтәм. «Алайса, әйдә атыңны безнең басуга бор, ул анда», — ди. Камчы сабы белән юлдан сулга күрсәтә. Карасам: мәш килеп печән чабалар, алты лобогрейка урдыра.

Сез, нәрсә, котырдыгызмы әллә, ник болай печәнгә иртә чыктыгыз? — дим. Бу әйтә: «Безнең анда печән җире түгел, кырлыкура, шайтан таягы ише чүп үләннәре генә, — ди. — Әнә шуны силоска урдырырга булдык», — ди. Үзегез урдырырга булдыгызмы? — мин әйтәм. «Юк, кичә секретарь килде, безнең басуларны карап йөргәндә, шушы кырлыкура басуына килеп чыкты да: бу кырлыкураны нишләтәбез? — дип әйтә, ди. — Парга сөрәбез, дибез, — ди. — Секретарь көлде дә әйтә ди: сөреп ташлау җүләрлек булыр, силоска урдырсаң, акыллы эш булыр дип әйтә», — ди.

Макар, сүзеннән туктап, Размётновка сынап карап тора башлады. Размётнов түземсезләнеп:

— Син аны күрдеңме соң? — дип сорады.

— Күрмичә! Юлдан кереп, ике чакрым чамасы баргач, карасам — ике арба тора, бер бабай утта ботка пешереп маташа; үгез кебек таза бер егет арба астына кереп яткан да, үкчәсен кашып, чыбык белән чебен кугалап ята. Секретарьга охшамаган. Үзе ялан аяк, бите табак кебек. Секретарьны сораган идем дә егет көлеп куйды. «Ул иртәдән бирле минем урында лобогрейкада йөри, әнә басуда, күрәсеңме, ул ташлап бара», — ди. Мин, иярдән төшеп, атны арбага бәйләдем дә урдыручылар янына киттем. Беренче лобогрейка узды. Монсына салам эшләпәле бер бабай утырган — тир белән мурып беткән ертык күлмәк, арба маена буялып беткән киндер ыштан кигән. Әлбәттә, секретарь түгел. Икенчесенә чәчен кырдырган яшь кенә егет утырган, — күлмәген салып ташлаган, тәне тирләгән — майлаган кебек, кояшта палаш шикелле ялтырый. Әлбәттә, бусы да секретарь түгел. Секретарь урдыргычта шәрә тән утырып йөрмәс, мин әйтәм. Басу буена күз салсам, калганнары да күлмәксез! Менә сиңа хикмәт, мин әйтәм, бел кайсысы секретарь икәнен! Интеллигент кыяфәтеннән танырмын әле дип, барысын да карап уздырдым, — юк бит, каһәр суккыры, тәки таный алмадым! Барысы да бил тиңентен ялангач, барысы да бакыр биш тиен кебек бер төсле, берсенең дә маңгаена секретарь дип язылмаган. Менә сиңа интеллигент кыяфәте! Барысы да интеллигент. Менә син озын чәчле, сакаллы попны кыркып, мунчада юынган солдатлар арасына кертеп җибәр әле — ул попны таба алырсыңмы? Монда да шул хәл бит.

Моңарчы тып-тын утырган Щукарь карт кыяр-кыймас кына:

— Макарушка, син дин әһелләренә кагылма инде, гөнаһ булыр! — дип куйды.

Макар аңа таба усал гына итеп күз атып алды да сүзен дәвам иттерде:

— Арбалар янына әйләнеп кайттым да теге егеттән сорыйм: урдыручыларның кайсысы секретарь? — мин әйтәм. Ә бу ямьсез танау әйтә: секретарь күлмәксез, ди. Мин әйтәм: күзеңне сөртебрәк карале, чебен таплап бетергәндер, урдыручыларның бер бабайдан башкалары барысы да күлмәксез бит, дим. Егет арба астыннан чыгып, кысык күзләрен угалады да шаркылдап көләргә кереште! Мин дә карагач көлеп җибәрдем: мин арбалар янына кире килгән арада әлеге бабай да күлмәге белән эшләпәсен салып ташлаган — киндер ыштаннан гына, иң алдан кырдырыпмы-кырдырып бара, такыр башы ялтырап-ялтырап китә, чал сакалын җил җилфердәтеп аркасына кайтарып сала. Кырлыкура арасыннан аккош кебек йөзеп бара. Менә, мин әйтәм, тамаша бу! Райком секретаре боларга шәһәр модасы алып килгән — дала буйлап шәрә тән гизеп йөриләр, мондый килешмәгән эшкә бөршәеп беткән картны да котырткannaр. Әлеге табак битле егет мине шулар янына алып килеп, секретарьны күрсәтте. Мин лобогрейка кырыеннан моның янына килдем дә, мин, мәйтәм, фәлән-фәлән булам, райкомга сезнең белән танышырга баруым иде, дим. Бу көлеп куйды, атларын туктатты да: «Әйдә, утыр, ат тотарсың, урдырабыз, ул арада синең белән танышып та

алырбыз, иптәш Нагульнов», — ди. Ат тоткан егетне утыргычыннан төшереп, аның урынына үзем утырдым, атларны атлаттым. Ну, дүрт бүй әйләнеп килгәнче танышып та беттек... Мировой егет икән! Бездә андый секретарьның булганы да юк әле. «Мин сезгә Ставрополь якларында ничек эшләгәннәрен күрсәтим әле, — ди. — Сездә балагына лампас тоткан чалбар кияләр, ә бездә шәбрәк итеп урдыра беләләр»,— ди, үзе көлә. Мин әйтәм: кем алдан эшен бетерер бит — ансын карарбыз әле: мактанчык мактаныр, агач атка атланыр, мин әйтәм. Барысын да аз-азлап сорашып чыкты бу. Шуннан соң: «Бар, иптәш Нагульнов, өенә кайта тор, озакламый сезгә дә барып житәрмен», — ди.

— Тагы нәрсәләр әйтте? — дип сорады Размётнов, жанланып китеп.

— Шуннан бүтән әллә ни әйтмәде. Ә, әйе, Хопров турында сорашты: ул активист идеме, түгелме? — ди. Нинди активист булсын, мин әйтәм, активист түгел, әдәм имгәге иде, дим.

— Ә ул нәрсә ди соң?

Әче алма ашаган шикелле, иреннәрен бөрештереп торды да, — әллә сүз әйтүе булды, әллә тамак кыруы булды, — «һм, һм» дип кенә куйды, ачык итеп берни дә әйтмәде.

— Хопров турында каян ишетте икән ул?

— Зәхмәт белсен. Район ГПУсыннан әйткәннәрдер.

Размётнов дәшми генә тагы бер тәмәке төреп тартты. Бик бирелеп ни турындадыр уйланып утырды, хәтта Нагульнов янына ни өчен килгәнлеген дә онытып жибәрде. Киткән чакта, саубуллаша-саубуллаша, Макарның күзләренә туп-туры елмаеп карады да:

— Баштагыларның барысы да үз урынына утырды! Иртәгә таң сызыла башлау белән беренче бригадага китәм. Тыныч бул, Макар, утау хакына белемне кызганмам. Тик белеп тор: якшәмбе көнне минем алга ярты литр аракыңны чыгарып утырткан бул! — диде.

— Утыртам, утыртам, — яхшы утасаң, бергәләп эчәрбез. Тик иртәгә иртәрәк кузгал, хатын-кызга эшкә чыгу үрнәге күрсәт. Ярый, хуш иттек! — дип калды Макар һәм яңадан китабына чумды.

Төн урталары тирәсендә, хуторны баскан тирән тынлыкта алар Щукарь карт белән икәү, беренче әтәчләрнең шундый шәп кычкыруларына соклана-соклана, тантанага бирелеп тыңлап тордылар.

Щукарь карт, таң калып, хисләнүеннән сакаулана-сакаулана:

— Архирей соборындагы кебек бит! — дип куйды.

Макар исә, хыялга бирелгән бер төс белән, корымлы лампа пыяласына карап:

— Атлы гаскәр жырлап барган кебек, — дип куйды.

Аларның әтәч тавышы белән мавыгулары әнә шулай башланып китте, шушы мавыгуы аркасында бервакыт Макар чак-чак кына үлемнән калды..

* * *

Давыдов бригадага киткәндә, аны Размётнов кына озатып калды. Шунда баручы жигүле ат туры килде: сукачыларга колхоз амбарыннан азык-төлек, семьяларыннан төрле киемнәр илтәләр иде.

Давыдов тапталып, тузып беткән күн итекләрен арбадан салындырып, картларча бөкрәеп утырган, — салкын гына бер кыяфәт белән тирә-юньгә карангалый. Иңенә салган пинжәге астыннан калак сөякләре тәртеп тора, чәчләрен дә күптән алдырмаган: бөтерелеп үскән кара чәчләре баш артына ук төшереп кигән кепкасы астыннан коңгырт таза муенына, майланып каткан пинжәк якасына хәтле төшеп тора. Давыдовның бөтен кыяфәте ничектер ямьсез һәм кызганыч иде...

Размётнов, аның өстенә карап, сызланган шикелле йөзен чыта-чыта: «Кара, ничек суырган бит аны Лушка! Каһәр дә суккан хатын инде! Шундый егетне әдәм карамаслык итеп эштән чыгарган бит! Гый-

шык дигәнең әнә нишләтә ул безнең агай-энене: кеше төсле бер кеше иде, ә хәзер кәбестә кучәненнән дә тегеләйрәк булган», — дип уйланды.

Кем дигәндә дә Размётнов «гыйшыкның нишләткәнен» бик яхшы белә инде. Марина Поярковапы, үз башыннан узган тагын кайбер хәлләрне исенә төшергәч, ул ачынып авыр сулап алды, аннары күңелле генә елмаеп куйды да авыл советындагы хәлләрне белешергә китте. Ярты юлны узгач, Макар Нагульнов очрады. Ул гадәтенчә хәрбиләрчә итеп бик ыспай, җыйнак киенгән иде. Размётновка, сүзсез генә, күрешергә дип кул бирде дә урам буйлап китеп барган җигүле атка таба башы белән ымлап:

— Иптәш Давыдовның кыяфәтен күрдеңме? — диде.

— Нишләптер ябыгыбрак киткән әле ул, — дигән булды Размётнов.

— Аның хәлендә чакта мин дә көннән-көн ябыга бара идем. Әйтеп тә торасы юк инде — егет бик сыек! Тот та табутка тык! Миндә фатирда торганда Лушканың хәтәр нәрсәкәй икәнен күрде бит, шул семья контрасы белән аның күз алдында көрәштем бит мин, ә хәзер, менә сиңа мә, килде дә капты! Ничек кенә капты әле! Бүген үзен күргәч, беләсеңме, йөрәк-бәгырьләрем телгәләнеп китте: ябыккан үзе, гаепле кеше төсле гел читкә карана, ә чалбары, валлаһи, ул мескеннең кай җиренә эләгеп торадыр! Күз алдында харап була бит егет! Минем ул иске хатынны кыш көне үк раскулачиваниегә кертеп, Тимошка Рваныс белән бергә салкын якларга сөрергә кирәк иде. Бәлки, анда бераз уты сүрелер иде, ичмасам.

— Ә мин сине белмисеңдер дип уйлаган идем...

— Һа! «Белмисеңдер», имеш! Бөтен кеше белгәндә мин белмиммени? Күземне йомып йөриммени? Миңа ансы Лушка кем белән өстерәлсә дә барыбер, әмма ул, зәһәр елан, минем Давыдовка орынмасын, минем кадерле иптәшемне харап итмәсен. Хәзерге моментта мәсьәлә әнә шулай тора!

— Синең аңар алдан ук әйтәсең калган, ник әйтмәдең?

— Миңа әйтүе уңайсыз ич! Көнләшүдән әйтә, фәлән-төгән дип уйлавы бар. Бу мәсьәләдә син менә читрәк кеше, ник үзең әйтмәдең соң? Нигә син аны ныгытып кисәтеп куймадың?

— Шелтә бирепме? — диде Размётнов елмаеп.

— Җүнле-рәтле йөрмәсә, шелтәсен башка җирдә дә алыр ул. Ләкин безгә, Андрей, аны иптәшләрчә саклап калырга кирәк, бүтән сузарга ярамый. Лушка — шундый зәһәр елан ул, Давыдов аның белән мировой революциягә хәтле яшәү түгел, бөтенләй дөньядан ычкынуы бар. Я әҗәл чахоткасы алыр, я булмаса берәр төрле шуңа охшаш сифилис эләктерер — көт тә тор! Мин, ул Лушкадан котылгач, дөньяга өр-яңадан туган кебек булдым: бернинди венерик авырудан да курыкмыйм, инглиз телен бик әйбәтләп өйрәнәм, бернинди укытучы-мазарсыз да үз башым белән күп нәрсә белдем, партийный эшләрне дә әйбәт алып барам, башка эшләрдән дә баш тартмыйм. Кыскасы, буйдак булып калгач, аяк-кулларым да азат, зиһенем дә саф. Ә Лушка белән торганда, аракы эчмәсәм дә, көн саен аракы махмыры башка капкан шикелле була иде. Без революционерлар өчен хатын-кыз ул, агай-эне, чын афиун! Мин бу сүзләрне эре-эре хәрефләр белән уставка яздырыр идем дә һәрбер партийный, һәрбер чын коммунист һәм теләктәш кеше бу бөек сүзләрне көн саен йоклар алдыннан һәм иртән торгач ач карынга өч кабат укып чыксын иде. Аннары, менә кадерле иптәшебез Давыдов шикелле, бер чорт та андый тозакка килеп капмас иде. Үзең уйлап кара, Андрей, шул каһәр суккан хатын-кыз токымыннан тормышта күпме яхшы кеше зыян күрде бит! Исәбе-хисабы юк! Шулар аркасында күпме акча житешмәүчелек булды, күпме кеше эчүгә сабышты, шулар аркасында нинди яхшы егетләр партийный линия буенча күпме шелтә алды, күпме халык төрмәдә утыра — котчыккыч тамаша бит!

Размётнов уйга калды. Бераз вакыт алар үткән тормышларын, гомер юлларында очраган хатын-кызларны исләренә төшерә-төшерә, сөйләшми генә бардылар. Макар Нагульнов борын тишекләрен киереп, юка иреннәрен кысып, сафта атлаган кебек, күкрәген киергән хәлдә, шып-шып басып атлап бара. Бөтен килеш-кыяфәте белән үк ул хатын-кызны якынына да җибәрмәс шикелле иде. Размётнов исә әле елмаеп куя, әле ахылдап кулын селкә, әле аксыл бөдрә мыек очын бөтереп җибәрә, әле, тук ата мәче шикелле, күзләрен елтыратып кыса, вакыт-вакыт, бик ачык итеп берәр хатын-кызны хәтеренә китерә иде, күрәсең, — мул гына аракы эчеп җибәргән шикелле, тамак кыргалый һәм озак кына тынып торганнан соң:

— Ай-һай-һай! Менә ичмасам шәп хатын иде! Ах, каһәр суккыры!..— дип авыз эченнән сөйләнеп куя иде...

Гремячий Лог, сөзәк калку артына күмелеп, кайдадыр артта калды, һәм күз күреме җитмәслек киң, иркен дала Давыдовны үз эченә йотты. Төрле үләннәрнең, кибеп җитмәгән кара балчыклы җирнең һушларга китәрлек тәмле исен күкрәк тутырып исни-исни, ул ерактa тау-тау тезелеп киткән каберлекләргә озак кына карап барды. Күкселләнеп торган шул каберлекләр кай яклары беләндер давылда айкалган Балтыйк диңгезе дулкыннарын хәтерләтте, һәм Давыдов шул вакыт йөрәгенә килеп тулган рәхәт бер сагыш хисләрен тыя алмыйча, көрсенеп, яман сулап куйды, яшьләнгән күзләрен читкә алды... Аннары тик кенә карап бара торгач, күктәге кечкенә генә бер кара төртке күзенә чалынды. Каберлек түбәләрендә яшәүче дала бөркете, мәһабәт бер ялгызлыкта, биек салкын күктә, әкрен-әкрен генә тәбәнәгәя биреп, әйләнеп оча иде. Ул киң, тумпак очлы канатларын җәеп салган да какмыйча-селтәмичә, әнә шунда, болытлар астында, җиңел генә очып йөри, каршы искән җил аның тонык кына ялтыраган кара каурыйларын сөякчел көчле гәүдәсенә кысып, комсызланып ялый. Бөркет янтаебрак көнчыгышка таба борылганда кояш нурлары аңа каршыдан һәм астан төшә, һәм шул вакыт бөркетнең аксыл каурыйлы канат асларыннан, җем-җем итеп кабынып, шундук сүнә-сүнә, ап-ак очкыннар чәчелә сыман иде.

...Иксез-чиксез дала. Борынгы курганнар зәңгәр томанга өртелгәннәр. Күктә каракош оча. Искән җилдә селкенеп үләннәр кыштырдый... Ялыктыргыч дәрәҗәдәге бу чиксез далага сагышланып күз йөртә торгач, очсыз-кырыйсыз сахрада Давыдов үзен бик кечерәеп, йотылып-югалып калгандай хис итте. Бу минутта аның Лушкага булган гыйшкы да, аралары бозылу кайгысы да, аның белән көрешү өмете дә бик вак һәм мәгънәсез нәрсәләр булып тоелды... Күңелен ялгызлык хисе, бөтен тере дөньядан аерылганлык тойгысы биләп алды. Бик күптән инде, төннәрен корабта «күзәтче» булып басып торган чакларында да шушыңа охшашлы хис кичергәне бар иде аның. Алары әллә кайчангы чаклар шул инде! Күптән күреп, онытылып бетә язган төш шикелле генә.

Кояш инде сизелерлек кыздыра башлады. Көньягыннан искән йомшак җил көчәя бара. Тигезле-тигезсез ташландык дала юлында әкрен генә чайкалгалап бара торгач, Давыдов, үзе дә сизмәстән, башын салындырып, йокымсырап китте.

Аңа ябык, арык атлар туры килде, олаучысы да — олы яшьләрдәге Иван Аржанов дигән колхозчы — аз сүзле, хутор халкы фикеренчә, бераз диванарак бер кеше иде. Әле күптән түгел генә үз кулына тапшырылган бу атларны ул бик кызгана иде, шуңа күрә алар бригаданың кыр станына хәтле юл буе диярлек атларны атлатып кына бардылар. Яртı юлда Давыдов, йокысыннан уянгач, хәтта түзмәде, усал гына итеп:

— Иван агай, ярминкәгә чүлмәк төяп бармыйсыңдыр бит? Ватыл-

магае дип куркасыңмы әллә? Нигә һаман атлатып кына барасың? — дип әйтеп тә карады.

Аржанов, башын читкә борып, шактый вакыт дәшми барды, аннары шыгырдавык бер тавыш белән:

— Нинди «чүлмәк» алып барганымны мин үзем беләм. Син, колхоз председателе булсаң да, мине тиктомалга чаптырта алмассың, шаярма, брат! — дип җавап кайтарды.

— Кем сина «тиктомалга» ди соң? Ичмасам, тау түбән юрттыргала! Иөк белән бармыйсың бит, буш барасың, факт!

Аржанов, шактый дәшми барганнан соң, теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды:

— Кайчан атлап кына барасын, кайчан юртып китәсен хайван үзе белә ул, — диде.

Давыдовның чынлап торып ук инде ачуы кузгала башлады. Ул, ачуын яшермичә:

— Әйттең сүз! Алай булгач, син нәрсәгә соң? Ни өчен кулыңа дилбегә тоттырганнар? Син ни өчен арбада утырып йөрисең? Кая, дилбегәне үземә бир! — диде.

Бу юлы инде Аржанов ачылыбрак җавап кайтарды:

— Бу дилбегәне минем кулга ат тотар өчен биргәннәр, атлар тиешле җиргә генә барсыннар өчен тоттырганнар. Әгәр минем арбага утырып йөрүем сиңа ошамый икән, мин төшеп, арба янынннан җәяү дә бара алам, әмма дилбегәне сиңа бирмим, шаярма, брат!

Давыдов, үзенә карамаска тырышкан бу олаучының йөзенә күз салырга чамалап:

— Нигә бирмисең? — дип сорады.

— Ә син үз дилбегәңне минем кулга тоттырасыңмы соң?

— Нинди дилбегә? — диде Давыдов, аңлап җиткермичә.

— Нинди булсын! Бөтен колхоз дилбегәсе синең кулда ич, халык синең кулга бөтен хуҗалык белән идарә итү эшен ышанып тапшырган. Син шул дилбегәне миңа бирәсеңме? Бирмәссең. «Шаярма, абзыкаем!» — диярсең әле. Менә мин дә шулай: мин бит синең дилбегәңне сорамыйм. Шулай булгач, син дә миннән сорама!

Давыдов пырхылдап көлеп җибәрде. Күңелендә баягы ачуының әсәре дә калмады. Шуннан соң ул:

— Ярый алайса, әгәр дә хуторда янгын чыкса, сулы мичкә белән дә шушындый әдәм хуры тизлегендә барырсыңмы? — дип сорады, кызыксынып җавап көтә башлады.

— Янгын сүндерергә минем ишеләрне сулы мичкә белән җибәрмиләр...

Шул вакыт Давыдов, Аржановка күз салгач, беренче тапкыр аның яңагын җыерчыкландырып, тыелып кына көлемсерәп баруын күрде.

— Нинди кешеләрне җибәрәләр соң, синенчә?

— Синең белән Макар Нагульнов ишеләрне!

— Нигә алай?

— Хуторда сез икегез генә чаптырып йөрергә яратасыз бит, үзегез дә йөгерә-чаба яшисез...

Давыдов, кулы белән тезенә сугып, башын артка ташлап, рәхәтләнеп бер көлеп җибәрде. Көлүеннән туктап та җитмәстән, тагы сорады:

— Алайса, әгәр чыннан да янгын чыга калса, Макар белән без икәү генә сүндерергә тиеш булабызмы инде?

— Түгел, нигә алай булсын! Сез Макар белән икәү, атларны җанфәрманга чаптырып, ак күбеккә батырып, су ташыйсыз, сүндерүен без колхозчылар сүндерәбез, — кайсыбыз чиләк белән, кайсыбыз багор, балта белән. Ә янгын сүндергәндә Размётнов башлык булачак, шуннан бүтән кеше юк.

Давыдов, исе китеп:

«Менә сиңа дивана агай!» — дип уйлап куйды. Бераз сүзсез баргач:
— Ә нигә син Размётновны янгын башлыгы итеп куясың соң? — дип сорады.
— Үзең акыллы гына егет кебек, үзең шуны да аңламыйсың. — диде Аржанов, ачыктан-ачык көлеп. — Тормышында кеше нинди булса, янгын вакытында да шундый должность бирелергә тиеш аңа, холыкфигыленә карап. Менә сез Макар белән йөгерә-чаба яшисез, көн-төн тынгылык күрмисез, башкаларга да тынычлык бирмисез, шулай булгач, сез инде, иң житез, иң өлгер буларак, бернинди тоткарлыксыз, су китереп торырга тиешсез, янгынны сусыз сүндереп булмый бит, дөресме? Андрюшка Размётнов ул — жайга гына юртып яши, чыбыркы күрсәтмәсәң, артыгын узмый-атламый... Шулай булгач, аның эше атаман дәрәжәсендәге кешегә нишләргә кала? Кулын бөеренә куя да боерып-кушып тора, акыра-жикерә, ыгы-зыгы куптара, кешеләрнең аяк астында бутала. Ә без, ягъни халык диюем, хәзергә жайга гына, адымга гына атлап яши бирәбез, шулай булгач, без артык ашыкмыйчакабаланмыйча эшебезне эшләргә, янгын сүндерергә тиешбез...
Давыдов уч төбе белән Аржановның аркасына шапылдатып сугып алды да аны үзенә таба борды; якыннан гына аның хәйләле елмаеп кысылган күзләрен, сакал баскан ягымлы йөзен күрде. Елмая төшеп:
— Хәйләкәр кеше икәнсең син, Иван агай! — диде.
— Ансы, Давыдов, син үзең дә хәйләкәрлеккә миннән ким түгел! — дип көлеп жавап кайтарды Аржанов.
Алар атларны һаман да акрын гына атлатып бара бирделәр. Давыдов, әйтүнең барыбер файдасы юклыгын күреп, Аржановны инде ашыктырмаска булды.
Ул әле арбадан жиргә төшеп, янәшә атлап барды, әле яңадан менеп утырды. Колхоз хәлләре, башкалары турында сөйләшкән саен, Давыдов олаучы Аржановның акылы зәгыйфь кеше түгеллегенә ышана барды; ни турында гына сөйләшмә, ул тәпле, акыллы итеп фикер йөртә, ләкин һәр нәрсәгә аның үзенә бер төрле, үзенә генә хас карашы, үз калыбы, үз бәясе бар иде.
Еракта бригаданың кыр станы һәм стан янындагы кухнядан жеп шикелле нечкә генә бөтерелеп чыккан төтен күренгәч, Давыдов:
— Юк, чынлап сорыйм, Иван агай, син гомер буе атларыңны шушылай атлатып кына йөрисеңме? — дип сорады.
— Әйе.
— Алайса, мондый сәер гадәтең барлыгын ник алданрак әйтмәдең? Сиңа утырып бармаган булыр идем, факт!
— Ни өчен мин үземне-үзем алдан мактап куйыйм? Менә хәзер минем ничек йөргәнне үзең күрдең бит инде. Минем белән бер тапкыр барсаң, икенче барасың килмәс.
— Нишләп син андый булдың соң? — диде Давыдов көлеп.
Аржанов, туры жавап бирмәстән, болай дип сөйләп китте:
— Элекке заманда минем бүр куршем бар иде, балта остасы иде, шуның өстенә бик эчкече иде. Алтын куллы кеше иде инде, ә үзе бик ямаи эчә торган иде. Түзеп йөри-йөри дә, аннары рюмка гына иснәсен, шуннан ычкына иде! Бөтен өстендәген, шыр ялангач калганчы, сатып эчеп бетерә иде, дус кеше.
— Ну?
— Ә менә улы авызына тамчы да алмый иде.
— Ә син уратмыйчарак, туры әйтеп сөйлә әле.
— Шуннан да тагы нинди туры кирәк инде, дус кеше. Минем әти мәрхүм бик яман аучы иде, атта йөрү дигәндә аннан да яманрак иде. Гаскәри хезмәттә чакта полкта ат чабышында, кылыч уенында, джигитовкада һәрвакыт беренче призларны алып килгән. Гаскәри хезмәттән кайткач та станицадагы ат чабышларында ел саен приз ала торган

иде. Туган атам булса да, әйтим: әшәке кеше иде, мәрхүм! Бик мут, купшы казак иде... Һәр көнне, иртән торгач, утта кадак кыздырып, шул кадак белән мыегын бөдрәләтер иде. Кеше каршында, бигрәк тә хатын-кыз алдында бик купшыланып йөрергә ярата иде... Ә атта йөрүен әйт син! Андый булырга ходай язмасын! Әйтик, мәсәлән, берәр йомыш белән аңа станицага барып кайтырга кирәк, ди. Гаскәри атын абзардан алып чыгып, иярли иде дә атлану белән үк чаптырып китә иде. Атын ишек алды буйлап чаптырып килеп, читән аркылы гына сикерә, артыннан җил уйнап кала иде. Гомерендә дә юрттырып яисә атлатып кына йөрмәде. Станица белән ике ара — егерме дүрт чакрым җир — шунда атын җан-фәрманга чаптырып барыр, чаптырып кайтыр иде. Әнә шул чаялыгы-тәвәккәллеге аркасында ат белән куян куып тотарга ярата иде. Бел: бүре түгел, куян бит! Кырлыкура арасыннан куянны куып чыгарыр иде, чокырдан бүлеп алып, куып житәр иде дә, я чыбыркы белән сугып үтерер иде, я аты белән таптатыр иде. Шундый каты чаптырып барганда, егылып, ничә тапкыр имгәнгәне булды, ләкин комарлыгын ташламады. Шуның аркасында хуҗалыгыбыздагы атларны үтереп бетерде. Мин белгәндә генә дә алты атны харап итте, кайсын яндырып үтерде, кайсысының аягын имгәтте. Әни белән безне тәмам бөлдерде! Бер кыш эчендә генә дә атланган ике атын үтерде. Каты чабып барганда сөрлегеп егыла да туң җиргә бәрелеп хәрап була! Карасак, эти ияреп жилкәсенә салган, җәяү кайтып килә. Әни, үле озаткандай, чеңләп еларга керешер иде, ә этигә чүп тә булмый! Ыңгырашкалап бер өч көн ята да, тәнендәге күгәргәннәре дә бетеп җитми, бу тагы ауга җыена башлый...

— Атлары егылып үлгәч, үзе ничек исән калган соң?

— Ат авыр санлы хайван ул. Чабып барганда егылса, җиргә төшкәнче ике-өч тапкыр баш аркылы әйләнә. Ә этигә нәрсә? Өзәңгесен ычкындыра да карлыгач кебек очып кына төшә. Ну, җиргә килеп бәрелә инде, аңына килгәнче һушсыз ята, аннары тора да җәяүләп өйгә сыпырта. Бик тәвәккәл нәрсә иде, шайтан! Аның сөякләре дә тимердән ясалган кебек иде.

— Көчле егет булган! — дип куйды Давыдов сокланып.

— Көчлесен көчле иде дә, үз башына житәргә дә көч табылды шул...

— Ә нәрсә булды?

— Үзебезнең хутор казаклары үтерделәр.

Давыдов, тәмәкесен кабыза-кабыза, кызыксынып:

— Ни өчен үтерделәр аны? — дип сорады.

— Миңа да тарттыр әле, дус кеше.

— Тәмәке тартмыйсың ич син, Иван агай?

— Чынлап тартуын тартмыйм да, вакыт-вакыт шаярып тарткалыйм. Әле күптәнге хәлләр искә төшкәч, авыз эчем кибеп, тәмсезләнеп китте... Ни өчен үтерделәр, дисеңме? Сәбәбе булган инде, димәк...

— Шулай да?

— Бер хатын — сөяркәсе аркасында үтерделәр. Ул хатынның ире бар иде. Ну, ире боларның эшен сизеп алган. Эти белән бергә бер очрашырга йөрәге житмәгән: эти буйга зур булмаса да, бик яман көчле иде. Шуннан соң теге хатынның ире үзенең ике энесен котырткан. Бу хәл масленица алдыннан булды. Болар өчәүләп этине инеш буенда сагалап торганнар... Ярабби, ничек кенә кыйнамаганнар алар аны! Күсәк белән дә, ниндидер тимер белән дә кыйнаганнар... Иртән этине өйгә китереп салганда, ул аңына килмәгән иде әле, тәннәре чуен кебек каралып-көеп беткән иде. Төн буе һушсыз-иссез боз өстендә яткан. Жинел булмагандыр шул, ә? Боз өстендә яту дим! Бер атнадан соң сөйләшә, әйткәнне аңлый башлады. Кыскасы, аңына кайтты. Ике ай буе урыннан тормады, кан төкереп ятты, сөйләшкәндә дә бик әкрен сөйләшә иде.

Бөтен эч әгъзасы имгәнгән иде. Дуслары, хәлен белергә килгәч: «Кемнәр кыйнады сине, Федор? Әйт әле...» дип сорап карыйлар иде дә, әти бер сүз дәшми, чак кына елмаеп, күзе белән генә ымлый, әни өйдән чыккач, пышылдап кына: «Хәтерләмим, дуслар. Бик күп ирләр каршында гаепле мин», — ди торган иде.

Әни, аның алдына тезләнеп, ничәмә тапкыр: «Федюшка бәгырем, үзеңне кемнәр кыйнаганын миңа гына әйт, ичмасам. Алла хакы өчен әйт, кемнәр корбаны өчен гыйбадәт кылганымны белеп торырмын!» — дип ялварып та карады. Әти, сабый бала юаткан кебек, кулын әнинең башына куеп чәченнән сыйпый да: «Кемнәр кыйнаганны белмим. Караңгы иде, таный алмадым. Арттан башыма китереп суктылар, аяктан ектылар, боз өстендә үземне кемнәр тукмаганны күрми калдым...» — ди, яисә тыныч кына елмая да: «Синең, җаным, үткән-беткәннәрне исеңә төшерәсең киләме? Гөнаһымны үзем кылдым, җавабын да үзем бирермен...» — дия торган иде. Үзен тәүбә иттерергә поп чакырдык, попка да берни әйтмәде. Бик каты серле кеше иде!

— Ә син аның попка әйтмәгәнен каян беләсең?

— Мин караватастына качып тыңлап тордым. Әни кушты. «Ванятка, бар, карават астына кереп, тыңлап тор әле, үзен кемнәр кыйнаганны батюшкага әйтмәсме», — диде. Ләкин әти кемнәр кыйнавы турында бер сүз дә әйтмәде. Попның соравына каршы бер биш тапкыр: «Гөнаһлымын, батюшка»,— дип кенә җавап кайтарды, аннары: «Митрий ата, теге дөньяда атлар бармы?» — дип сорады. Поп курыкты, күрәсең: «Ни сөйлисең, ни сөйлисең, алла колы! Анда нинди атлар булсын! Җаныңны коткару хакында уйла!» — диде. Ул әтине бик озак үгетләп, тәүфыйкка китерергә тырышты, әти дәшми генә ятты да шуннан соң: «Анда атлар юк дисеңмени инде? Кызганыч икән! Югыйсә, мин анда да ат көтүчесе булып ялланыр идем... Ат булмагач, минем анда хаҗәтем юк. Алайса, үлмим инде, сиңа сүзем шул!» — диде. Поп аны ашыкпошык кына причастиеләде дә, бик кәефе бозылып, ачуы чыгып, кайтып китте. Мин ишеткәнемнең барысын әнигә сөйләгәч, әни елап җибәрде, «Әтиең гөнаһлы булып дөньяда яшәде, гөнаһлы булып дөньядан да кичәр инде!» — диде.

Яз көне, кар беткәч, әти урыннан торды, ике көн өй эчендә йөргәләде, өченче көнне, карасам, өстенә сырган сюртугын, папахасын кия, «Ванятка, бар әле, байталны иярләп бир әле», — ди. Ул вакытны йортыбызда өч яшьлек бер байталыбыз гына калган иде. Әни әтинең ни әйткәнен ишетте дә еларга кереште. «Федя, синең хәзер атка атланырлык хәлең юк бит! Аягыңда көчкә басып торасың! Үзеңне кызганмасаң, ичмасам, балаларың белән мине кызган!» — диде. Әти көлде дә: «Анасы, минем гомеремдә дә ат атлатып кына йөргәнем булмады. Ичмасам, үләр алдыннан ияргә атланып, ишек алдыннан атлатып кына әйләним. Бер-ике әйләнәм дә өйгә керәм», — диде.

Мин чыгып байталны иярләдем дә баскыч төбенә китердем. Әни әтине култыклап алып чыкты. Әтинең ике ай буе сакал-мыегы кырылмаган иде, өй эче караңгы булгач, аның кыяфәте ничек үзгәргәнлеге күренми иде. Кояш яктысына чыккач, йөзенә күз салган идем, үзәк бәгырьләрем өзелеп китте. Ике ай элек әтинең чәче-сакалы чем-кара иде, ә хәзер сакалы яртылаш чаларган, мыегы да шундый булган, ә чигәсендәге чәчләре кар кебек ап-ак.. Әгәр ул хәлсез, мескен бер кыяфәт белән елмаймаган булса, бәлки, мин еламаган да булыр идем, — шунда тыелып кала алмадым... Әти миннән тезгенне алып, атның ялына тотынды, сул кулы аның сынган иде, әле яңарак гына ялганып киткән иде. Мин аны күтәреп атландырыйм дигән идем дә, — кушмады. Бик тә горур кеше иде инде! Хәлсезлеген дә яшерергә тырыша иде. Билгеле инде, аның, таза чагындагы шикелле, ияргә очып кына атланасы килә иде, тик алай барып чыкмады шул... Өзәнгегә басуга,

сул кулы сыгылып китеп, бармаклары ычкынды да аркасы белән җиргә килеп төште... Әни белән икәү этине өйгә күтәреп керттек. Моңа хәтле әле ул кан төкергән генә булса, хәзер инде тамагыннан чаптырып кан ага башлады. Әни кичкә хәтле тагарак яныннан китмәде, канлы сөлгеләрне юып өлгерә алмый иде. Попны чакырдык. Төнлә ул этигә собор йоласы ясады. Шул хәтле дә нык кеше булыр икән эти! Собор йоласыннан соң өченче тәүлек дигәндә генә тынычсызланып, караватында чабаланып ята башлады, аннары сикереп торды да тонган күзләре белән әнигә көлемсерәбрәк карап әйтә бу: «Собор йоласыннан соң җиргә ялан аяк басарга ярамый, дип әйтәләр, ярамаса да, мин бераз басып торыйм әле... Мин бу җирдә үз аягым белән дә, ат аягы белән дә бик күп йөрдем, бер дә бу җирне ташлап китәсем килми... Анасы, кулыңны бир әле, синең кулың бу дөньяда бик күп эш эшләгән бит...» — диде.

Әни, аның янына килеп, кулыннан тотты. Эти, чалкан ятып, бераз тынып торды, аннары пышылдап: «Минем аркада күпме күз яше дә сөрткән...» — диде дә, йөзе белән стенага таба борылып ятып, вафат булды, теге дөньяга Василий угодник атларын көтәргә китте...

Аржанов авыр истәлекләр тәэсиренә бирелде, күрәсең, — озак кына сөйләшми барды. Давыдов йөткеренгәләп алып:

— Иван агай, карале, этиеңне теге нинең... ну, әйтик, аның теге хатынының ире... һәм иренең энеләре кыйнаганны син каян беләсең? Алардыр дип чамалап кына әйтүеңме? — дип сорады.

— Нишләп чамалап әйтим! Үләренә бер көн калгач, эти миңа үзе әйтте.

Давыдов утырган жиреннән хәтта күтәрелә төште:

— Ничек инде ул — әйтте?

— Ничек әйтсен — тотты да әйтте. Иртән әни сыер саварга чыгып китте, мин мәктәпкә барыр алдыннан, өстәл янында дәресләремне укып утыра идем, бер вакыт ишетәм — эти миңа: «Ванятка, яныма кил әле», — дип пышылдый. Килдем. «Якынрак иел әле», — ди. Иелдем. Әкрен генә әйтә бу: «Менә нәрсә, улым, син инде хәзер унөченче яшең белән барасың, мин үлгәч, йортка хуҗа булып калырсың, исеңдә тот: мине Аверьян Архипов белән аның ике энесе: Афанасий белән кылый Сергей кыйнадылар, ди. Алар мине шундук үтерсәләр, мин аларга ачу сакламас идем. Аңымда чакта мин аларга инештә шулай дип әйттем дә. Шунда Аверьян миңа әйтте: «Синә җинел үлем булмас, эт җан! Гарип көенчә үз каныңны түйганчы йотып яшә әле, аннары дөмегерсең!» диде, — ди. — Шуның өчен мин ул Аверьянга үч саклыйм, — ди. — Әҗәлем баш очымда гына торса да, мин аңа барыбер үч саклыйм, — ди. — Син кечкенә әле, зур үскәч, минем газапланып үлгәнемне онытма, Аверьянны үтер! — ди. — Бу сүзләрне беркемгә дә әйтмә — әниеңә дә, берәүгә дә әйтмә. Әйтмәм дип тәүбә ит», — ди. Мин тәүбә иттем, тик еламадым, этиемнең муенындагы тәресен үптем...

— Фу, чорт, элекке заманда Кавказдагы чиркәсләр шикелле! — дип, Давыдов Аржанов сөйләгәннәрдән тәэсирләнеп әйтеп куйды.

— Чиркәсләрдә — әдәм йөрәге, ә русларның йөрәге урынында ташмыни? Бөтен кеше дә бер төсле ул, дус кеше.

— Шуннан ничек булды соң? — диде Давыдов түземсезләнеп.

— Этине күмдек. Зираттан кайттым да ак өйдә ишек яңагына аркам белән сөялеп, баш очымнан карандаш белән сызык сыздым. Ай саен буемны үлчәп, тамгалап бара башладым: тизрәк зур үсеп, Аверьянның башына житәсем килә иде... Шулай итеп, мин йортта хуҗа булып калдым, — ул чагында миңа нибары унике яшь иде, миннән башка, әниинең тагы береннән бере кечерәк жиде баласы бар иде. Эти үлгәннән соң әни гел авыргалый башлады. Күпме нужа, күпме газап, михнәт күрдек без, ярабби! Эти нинди җүнсез кеше булса да, типтерә дә белә, эшли дә белә иде. Берәүләр өчен ул әшәке кеше иде, ә безгә,

әни белән балаларга — үз кеше, якын кеше иде: ул безне ашата, киендерә, безнең өчен яздан алып көз житкәнче басуда тир түгә иде... Ул чакта җилкәләрем ябык, сыртым сыек булса да, миңа бөтен хуҗалыкны үз өстемдә күтәреп барырга, олы ирләр шикелле эш эшләргә туры килде. Әти исән чакта без дүрт бала мәктәпкә йөри идек, әти үлгәч, дүртебез дә мәктәпне ташларга мәҗбүр булдык. Ун яшьлек сеңелем Нюрканы әни урынына аш пешерергә, сыер саварга куштым, энеләрем миңа хуҗалыкта булыша башладылар. Ләкин мин ай саен ишек яңагына буемны үлчәп, тамга салып барырга да онытмый идем. Тик ул елны мин бик начар үстем: кайгы-хәсрәт, нужадан чын-чынлап үсә алмадым. Ә Аверьянны, камыш арасыннан кош күзәткән бүре баласы шикелле, гел күзәтеп тордым. Мин аның һәр адымын белеп тора идем; кая киткән, каян кайткан, — барысын да белеп тора идем...

Якшәмбе көннәрне яшьтәшләрем җыелышып төрле уеннар уйный торган иде, ә минем уйнарга вакыт юк, мин — өйдә өлкән кеше. Мондый көннәрне алар мәктәпкә китә, ә мин абзарга чыгып терлекләр карыйм... Шундый авыр тормышта яшәвемә бик гарьләнә идем, бик кимсенә идем. Шулай итеп мин тора-бара үземнең яшьтәшләремнән читләшә, аралашмый башладым. Телсез таш кебек, бер сүз сөйләшмим, кеше арасына чыкмыйм. Шуннан инде хуторда минем турыда, Ванька Аржанов акылга таман, диваналанган, — дип сөйли башладылар. «Ләгънәт суккырлары! Минем урынга сезнең үзегезне куясы иде! Акылыгыз нишләр иде икән аннары?» — дия идем эчемнән. Шуннан соң инде мин хутордашларымны бөтенләй дошман күрә башладым; берсен дә күрә алмый идем!.. Тагын бер папирос бир әле, дус кеше.

Аржанов ипсез генә итеп папиросны кулына алды. Бармаклары дерелдәгәне сизелеп тора иде. Ул, күзен йомып, иреннәрен мәзәк кенә чөмәкләндереп, авызын чапылдата-чапылдата, Давыдов папиросыннан озак кына ут көйрәтеп азапланды.

— Ә Аверьян нишләде соң?

— Нишләсен ул Аверьян? Үз ирегенчә яши бирде. Әти белән йөргән өчен хатынын кичерә алмады, үтергәнче кыйнап, бер елдан гүргә кертте. Көзге якта икенче хатынга — үзебезнең хутордан яшь кенә бер кызга өйләнде. Мин шул чакны эчемнән генә уйлап йөрим: «Ну, Аверьян, яшь хатының белән озак яши алмассың...» — мин әйтәм.

Әнигә сиздермичә генә акча җыя башладым, ә көз көне якындагы ссыпкага бармыйча, бер үзем Калач шәһәренә киттем, шунда бер йөк бодай сатып, базарда кулдан бер көбәкле мылтык белән ун штук патрон сатып алдым. Кайткан чакта мылтыкны сынап та карадым, өч патронны әрәм иттем. Бик начар ата торган мылтык булып чыкты. Чакмасы пистонны бер бәрүдә үк тишә алмый, өч патронның икесе осечка бирде, өченчесе генә атты. Өйгә кайткач, мылтыкны амбар кыегына яшереп куйдым, мылтык алганымны берәүгә дә әйтмәдем. Шуннан соң инде Аверьянны сагалап йөри башладым... Бик озак җай туры килмәде. Я кешеләр комачаулый, я башка бер сәбәп аркасында тегене атып булмый иде. Шулай да бер җаен китердем! Хикмәт шунда: минем аны хуторда үтерәсем килми иде! Покрауның беренче көнендә ул станицага ярминкәгә китте, бер үзе, хатыныннан башка гына. Мин, аның үзе генә киткәнен белгәч, соенечемнән чукынып алдым, югыйсә икесен дә үтерергә туры килгән булыр иде. Тәүлек ярым ашамыйча, эчмичә, йокламыйча, юл буендагы чокырда аны сагалап яттым. Шул чокырда, Аверьян станицадан үзе генә кайтсын иде, дип ялынып-ялварып алладан сорадым. Хода-тәгалә мин баланың гозеренә колак салды! Икенче көнне кичкырын карасам — Аверьян бер үзе кайтып килә. Моңарчы мин әллә ничә атлы арба уздырдым, ничә тапкыр, еракта җигүле атлар күренгәч, бу — Аверьян атлары түгелме, дип, йөрәгем дөп-дөп сикерде... Минем турыга килеп җитүгә, чокырдан

сикереп чыктым да: «Арбаннан төш, Аверьян абый, аллага дога кыл!» — дидем. Йөзе моның көл кебек агарып китте. Атларын туктатты. Озын буйлы, таза казак иде үзе, ә мине нишләтә ала ул? Минем кулда — мылтык. «Нишләмәкче буласың син, елан?» — дип кычкыра бу миңа. «Арбаңнан төшеп, җиргә тезлән! Нишләргә җыенганымны хәзер белерсең!» — мин әйтәм. Йөрәкле әдәм иде, дошман! Арбадан сикереп төште дә буш кул белән миңа ташланды... Мин моны, менә шушы кырлы курага чаклы, якын ук китердем дә терәп диярлек атып җибәрдем...

— Әгәр мылтыгың атылмаган булса?

Аржанов елмаеп куйды:

— Атылмаган булса, мине теге дөньяга, әти янына атлар көтешергә җибәргән булыр иде.

— Шуннан соң ничек булды?

— Мылтык атуга, атлар өркешеп чабып киттеләр, мин урынымнан да кузгала алмый басып тора бирдем. Аякларым атламый, үзем, җилдә тетрәнгән яфрак кебек, дер калтырыйм. Аверьян янымда гына җирдә үлеп ята, ә мин шуңа таба бер адым да атлый алмыйм, аягымны күтәрәм дә кире басам, егылып китмәгәем дип куркам. Шундый курку алды үземне. Аннары, көч-хәл белән исемне җыеп, янына килдем, битенә бер төкердем дә чалбар, пинжәк кесәләрен актарырга керештем. Янчыгын алдым. Егерме сигез сум кәгазь акчасы, биш сумлык бер алтын тәнкәсе, ике-өч сум вак акчасы бар иде. Аларын инде мин соңыннан, өйгә кайткач санадым. Бүтән акчасына яшь хатынына күчтәнәчләр алган, күрәсең... Янчыгын бушатып, шунда юлга ташладым да үзем чокырга төшеп сыздым. Бик куптәнге хәл булса да, кичә генә булган кебек, бөтенесен хәтерлим әле. Мылтык белән патроннарны чокырга күмеп калдырдым. Кар төшкәч, төнлә барып, казып алдым да, хуторга алып кайтып, мылтыкны кеше бакчасына карт өянке куышына яшереп куйдым.

Давыдов усал гына итеп:

— Акчасын ник алдың? — дип сорады.

— Ә нигә?

— Ник алдың, дип сорыйм?

— Акча кирәк иде. Ул чагында без бик нужа белән яши идек.

Давыдов, арбадан сикереп төшеп, байтак кына дәшми барды. Аржанов та сөйләшмәде. Аннары Давыдов:

— Шуның белән беттеме? — дип сорады.

— Юк, бетмәде әле, дус кеше, — диде Аржанов. — Тикшерүче властьлар килеп, казынмаган, актарынмаган җирне калдырмадылар... Тәки берни таба алмый киттеләр. Мин үтергән дип кемнең башына килсен? Шуннан соң озакламый Аверьянның энесе кылый Сергей урман кисәргә баргач, салкын тидереп, авырып үлде: үпкәсе шешкән булган. Шул чагында мин бик борчыла башладым: мәйтәм, Афанасий да үз үлеме белән үлеп китсә, этинең «дошманнардан үч ал» дигән фатихасы вөҗүткә ашмый калыр микәнни?.. Шуннан ашыга башладым...

— Туктале, — диде Давыдов, аны сүзеннән бүлдереп. — Әтиең сиңа Аверьян турында гына әйткән бит, ә син өчесен дә юк итәргә булдыңмыни?

— Әти ни әйтмәс... Әти үзенә, мин үземә. Менә шуннан соң ашыга башладым мин... Афанасийны кич өендә ашап утырган чагында тәрәзәдән атып үтердем. Шул төнне мин соңгы тапкыр ишек яңагына буемны үлчәдем дә шундагы тамгаларны чүпрәк белән сөртеп ташладым. Ә мылтык белән патроннарны суга ташладым; аларның хәзер кирәге юк иде инде... Мин эти теләген дә, үз теләгемне дә җиренә җиткердем. Аннары инде озакламый әни үләргә ятты. Төнлә мине янына чакырып алып: «Ванятка, аларны син үтердеңме?» — дип сорады. Яшермәдем:

«Мин үтердем, әнкәй», — дидем. Әни миңа бер сүз дә әйтмәде, уң кулымны тотып, үзенең йөрәк турысына гына куйды...

Аржанов дилбегәне селеккәләүгә, атлар кызурак атлый башладылар. Шуннан соң ул, балаларныкы төсле саф соры күзләре белән Давыдовка карап:

— Хәзер инде минем ни өчен атта кызу йөрмәгәнемне сорап, бүтән төпченмәссеңме? — дип куйды.

— Аңлашылды,— диде Давыдов.— Иван агай, сиңа үгез җигеп, су ташырга гына кирәк икән, факт.

— Шулай дип үзем дә Яков Лукичка ничә тапкыр әйттем инде, тик ул күнми. Соңгы чиккә хәтле миннән көлмәкче була ул...

— Нигә алай?

— Мин малай чагымда ук аларда ел ярым ялланып эшләгән идем.

— Алаймыни!

— Шулай шул, дус кеше. Ә син Островновларның гомер буена хезмәтче яллап килүләрен белми идеңмени? — диде Аржанов, аннары күзен хәйләле генә кыса төшеп: — Ялладылар инде, дус кеше, ялладылар... Моннан дүрт ел элек, налоглар белән кыса башлагач, тынды, чагарга җыенган елан кебек, бөтерелеп җыелды, әгәр дә хәзер колхоз булмаса, налоглар азрак булса, Яков Лукич кемлеген күрсәтер иде, беләмсең! Иң явыз кулак ул, ә сез шул зәһәр еланны куеныгызга керттегез...— диде.

Давыдов озак кына дәшми барды, аннары:

— Без ул хәлне төзәтербез, Островновны тиешенчә тикшерербез, ә син шулай да, Иван агай, әкәмәтле кеше,— диде.

Аржанов, күзләрен каядыр еракка төбәгән килеш, елмаеп куйды:

— Ул әкәмәт дигәнең бит — ничек дип әйтим... Менә, мәсәлән, чия агачы үсеп утыра, аның бик күп ботаклары бар. Мин бардым да шуның бер ботагын чыбыркы сабына кисеп алдым,— чия сап-тазарак була,— шул чия дә әкәмәт булып үсеп утыра иде — әллә ничаклы ботаклары, яфраклары бар, шундый матур иде,— шул ботакны юнып ташлагач, менә ул нинди булып калды...— дип, Аржанов утыргыч астыннан кибеп, корышып беткән коңгырт кабыклы чия таягы алып, Давыдовка күрсәтте...— Менә нинди булып калды ул! Карарлык җире дә юк бит! Кеше дә шулай: бер дә әкәмәтлекләре булмаса, ул менә шушы ялангач чыбыркы сабы шикелле булыр иде. Әнә Нагульнов нинди дер чит тел өйрәнә — әкәмәт кеше; Крамсков карт егерме ел буе шырпы тартмалары җыя — әкәмәт кеше; син Лушка Нагульнова белән йөрисең — син дә әкәмәт кеше; берәр исерек урамнан барганда абынып китә дә аркасы белән читәнне сыдырта — бу да әкәмәт. Дус кеше, председатель, менә син кешенең шул әкәмәт якларын бетер әле, аннары ул шушы чыбыркы сабы шикелле ялангач, бик күңелсез булып калачак.

Аржанов чыбыркыны Давыдовка сузды да, баягыча уйчан бер кыяфәттә елмаеп:

— Менә шушыны кулыңа тотып, бераз уйланып кара әле, бәлки, синең дә зиһенең ачылып китәр...— диде.

Давыдов, ачуы килеп, Аржановның кулын этеп җибәрде:

— Маташтырма әле! Мин ансыз да уйлый, аңлый беләм! — диде.

Шуннан соң алар, станга барып җиткәнче, сүз сөйләшмәделәр.

*Яхъя ХАЛИТОВ тәрҗемәсе.*

———♦———

*Фәнис Яруллин*

## Якташлар

Шигырь өчен тарих битләреннән
Батырларның исемен эзләмим.
Якташларым, нефть табучылар,
Шигыремдә дәшәм сезгә мин.
Сез чыгарган җылы җир сулышы
Яна хәзер һәрбер калада.
Прометейлар безнең якта яши,
Прометейлар — сезнең арада.

## Яши алмыйм шунсыз

Озак йөрсәм, ялыктыра башлый
Болыннар да, матур урман да.
Сандугачлар хәтта туйдыра бит
Бертуктаусыз сайрап торганда.
Йолдызларның нуры кими кебек
Озак йөрсәм якты төннәрдә.
Һәрвакытта алда торса әгәр,
Ямьсезләнә кебек гөлләр дә.
Тиз туйсам да кайбер нәрсәләрдән,
Бер нәрсәгә артык комсыз мин —
Кешеләрдән һич тә туя алмыйм,
Яши алмыйм бер дә шунсыз мин.

●

Җилкәмдәге авырлыкны салган идем
Ак каенга, чыдамады, төште сыгылып.
Биргән идем аны аккан болытларга
Күтәралмый яңгыр булып яуды болыт.

Аннан инде бөтен булган борчуларны
Яшермичә сиңа сөйләп бирдем, әнкәм.
Хәйран калдым, син күтәрдең, сыгылмадың,
Бар нәрсәдән көчле икән синең җилкәң.

## Башыңны күтәр әле

Яфраклар җиргә таралган,
Яфраклар җирдә оча;
Йөзләрең нигә каралган!
Эчләрең нигә поша!

Төймәләреңне чишкәнсең,
Күлмәгең тармы әллә!
Күкрәкләреңә сыймаслык
Хәсрәтең бармы әллә!

Өзелгән яфрак шикелле
Бәрелеп-сугылма син.
Башыма кайгы килде дип,
Тормыштан суынма син.

Кайгылар алар вакытлы:
Килер дә китәр әле.
Каршыңа шатлык килмиме!
Башыңны күтәр әле.

## Туган авылым

Туган авылым минем — бер планета,
Мин иярчен — шунда әйләнәм.
Ахры, әнкәм мине табу белән
Киндегемнән җиргә бәйләгән.

Бераз күрми торсам, ашыгып кайтам,
Әйтерсең лә минсез эш туктый.
Беләм юкса, миннән башка да һич
Сабаннарда төрән тутыкмый.

Болыннарда һаман яшел үлән,
Бакчаларда пешә алмалар.
Басуларда һаман үсә игеп,
Тик ел саен үсә яңалар.

Белсәм дә мин шулай икәнлеген
Кайтып-килеп йөрим — әйләнәм.
Ахры, әни мине киндегемнән
Шушы туган җиргә бәйләгән.

# Дуслар җыры

*Татарстан һәм Башкортстан — ике кардәш, күрше республикалар. Табигый шартлар да, тормышлар да охшаш, әдәбият, сәнгать өлкәсендә дә күп кенә уртаклыгыбыз бар. Бу ике республика әлеДән-әле аралашып, тәҗрибә уртаклашып, кунак булышып яши. Узган ел Татарстан язучыларыннан бер төркем Башкортстан хезмәт ияләре арасында чыгышлар ясап, очрашулар үткәреп кайтканнар иде. Бу елның июнь аенда Язучылар союзының Әлмәт бүлеге башкорт язучыларын каршы алачак. Шул уңай белән без журналыбызның бу санында башкорт әдәбиятыннан үрнәкләр бирәбез.*



**Мостай Кәрим**

## Әнием чирләгәндә

Әнием ятып чирли.
Белсәгезче
Миңа ничек кыен икәнен.
Моңа хәтле күрмәдем мин аның
Хәтта ятып черем иткәнен.

Таңда торсам — учагында уты,
Төндә кайтсам — көйри күмере.
Исеме дә аның Вазифа шул,
Һәм вазифа — бөтен гомере.

Бер кич әйтте: «Куй шул
даруларны...
Үзең озак утыр янымда.
Бергә яшәп, сирәк күрешәбез
Без бәндәләр исән чагында.

Васыятем юк сиңа, мирасым юк,
Үгет алыр яшьтән үткәнсең.
Калдыгыз өч бөртек бер башакта,
Арада син чалсың, өлкәнсең.

Йөрәгемә туктаусыз ук ата
Авыр уйларымның гаскәре,
Чөнки миннән кала сиңа күчә
Ике дөньяның да хәстәре.

Син юламан булдың. Юлда булдың,
Сагышыма сагыш ялгадың,
Ярты гомерем узды сине көтеп,
Син китә, дип, куркып — калганы.

Юк, юк, сукранмыймын. Мин бит сине
Үзем шундый итеп яраттым.
Кавырсынына да тел тидермәм
Рухыңдагы чая канатның.

Өч яшеңдә атка меңгерделәр,
Син чытырдап ялга ябыштың,
Ә мин чәчләремне учлап алдым, —
Сиңа куәт бирәм, имештер...

Тап шул вакыт йөрәк-бавырымның
Бер тамыры кинәт өзелде:
Атка менден — кулдан киттең бала,
Тәкъдир саклый күрсен үзеңне!

Шуннан машиналар, ярапланнар
Сине миннән алып качтылар,
Мин аларны каргамадым, алар
Сине кире алып кайттылар.

Урманнарга чыктым сагынудан
Чыдамнарым беткән чакларны.
«Мостафа-а!» — дип кычкырдым мин
сиңа,
Рәхмәт,
Урман җавап кайтарды.

Чирле идең читтә. Төшкә керми
Җәфаладың шулай бер заман.
Таңнан торып Әсхәпләргә керәм,
Керәм дә шул зарны зарланам.

Әсхәп әйтә бер көн: «Таң алдыннан
Мостафаны күрдем төшемдә,
Акбуз атта чаба, имеш, үзе,
Ап-ак күлмәк, имеш, өстендә...»

Әсхәп алдый, ә мин алданамын.
Икебез дә әрнеп елыйбыз.
Акбуз аткай белән ак күлмәкне
Исән күрешүгә юрыйбыз.

Син сугышта чакта
Кышлар суык,
Кар-буранлы булды — зәһәрле.
Сине уйлап дер-дер калтырандым.
Кара көздән язга кадәрле.

Күз алдымда торды: син гел генә
Бураннарга каршы барасың.
Билдән карга бата-бата-бата,
Бутаннарга юллар ярасың.

Шундый бер төн мин, далага чыгып,
Җилгә каршы юлсыз атладым.
Киттем, киттем. Какъ түбәне үттем,
Эзләремне карлар каплады.

Бирешмимен, һаман барам, барам.
Каршы җилләр җанны өзәрлек.
Үзем барам, үзем аваз салам:
Түз, түз, бала! Адәм түзәрлек!..

...Менә шулай, тезмә-тезмә булып,
Барысы да килде хәтергә.
Күрәсең, бер җайда кеше үзенең
Әйтер сүзен тиеш әйтергә.

Васыятем юк сиңа, мирасым юк,
Үгет алыр яшьтән үткәнсең.
Калдыгыз өч бөртек бер башакта,
Арада син чалсын, өлкәнсең...»

Әсәем!
Мине күптән җиңгән булыр иде
Каршы җилләр, каты яралар,
Син тормасаң әгәр, калкан булып,
Хәвеф белән минем арада.

Бирешмәче, зинһар, бирешмәче,
Савыга күр инде, әсәем!
Тагы бераз синең ышыгыңда
Хәвеф-хәтәр күрми яшәем.

## Айсылуның күз яшьләре

Уналтысы тулган Айсылуны
Аккошларга тиңләү аз төсле,
Ул үзе бит аккош төркемнәрен
Безгә алып килгән яз төсле.

Уналтысы тулган шул Айсылу,
Ап-ак халат киеп өстенә,
Таңны кичкә, язны көзгә ялгап,
Тау ягында кошлар үстерә.

Ә бер көнне көзге чебешләрне
Барлаганда...
икәү тулмады.
Шуны белгәч, мөдир Әбделкадыйр
Үрле-кырлы килеп дулады.

Авыр сүзләр, яман сүзләр әйтте,
Пычрак сүзләр әйтте балага.
Нурлар чәчеп торыр ике күздән,
Ике чишмә булып, яшь ага.

Акланырлык урыны юк кызкайның,
Бөтен гаеп аның ягында;
Әбделкадыйр ни әйтсә дә хаклы —
Әбделкадыйр дәүләт сагында.

Күпме кирәк ап-ак туй күлмәген
Пычрак атып кына тапларга?

Күпме кирәк сабыйның пакь күңелен
Кара сөрем белән капларга?

Еламачы, Сылу, тукта инде,
Онытырга тырыш җәберне.
И кешеләр! Кайчак без соң әле
Нигә шулай каты бәгырьле?..

Булачагын, була язганнарын
Исәпкә без төгәл алабыз.
Каз югалса, оран таратабыз,
Чебеш үлсә, сөрән салабыз.
Исәпләрне төгәл алабыз.

Ә кырылып калган кәефләрне,
Ә нахакка тамган яшьләрне
Исәпләргә вакыт түгел микән? —
Кемнән көтик андый хәстәрне?

Айсылуның түккән күз яшенә
Чын бәһаләр куйсам мин әгәр,
Әйтер идем:
ул — заяга аккан
Алтын чишмәләргә бәрабәр.
Күз яшьләрен юкка түкмәек.
Алар да бит дәүләт байлыгы,
Ул байлыкны әрәм итмәек.



**Зәйнәп Биишева**

## Җырларым

Тук песидәй җылы мич башында
Аунап-мырлап тукады бу җырларым.
Эш өстендә кайнап үтте елларым.
Юл уңае туып үсте җырларым.
Бәлки, шуңа ширбәт кебек түгелдер,
Бәлки, шуңа назлы гөлдәй түгелдер,
Эштә ярсып, ургып туды җырларым.
Җырлар булып түгелеп барды елларым.

Күзгә катык, көмеш кашык янында
Тумады бу йөрәк каны — җырларым.
Көне — алтын, өне — ялкын елларым.
Эш өстендә туып үсте җырларым.

Вакыт җитәр. Мин дә бер чак арырмын.
Диңгез юган кыя сымак авырмын.
Дулкын булып, таралып калыр җырларым,
Кайта-кайта кагып күңел ярларын.

## Башкорт теле

Моң чишмәсе, сандугачтай җырчы ла син,
Сыгылма бил, талчыбыктай нечкә лә син,
Аллы-гөлле гөлчәчкәдәй нәфис тә син,
Әй, илһамлы, әй, кодрәтле, башкорт теле.
Күп вакытлар син җырладың курай моңын,
Күп вакытлар син җырладың көрәш юлын,
Инде азат, шат. Җырлыйсың җиңү җырын.
Әй, бәхетле, әй, хөрмәтле, башкорт теле.
Иң элек миңа син өйрәттең Ленин сүзен,
Иң элек миңа син күрсәттең дуслык юлын,
Минем өчен син бит тормыш — бәхет үзең,
Мәңге яшә, әй, сөекле башкорт теле —
Атам теле, анам теле — минем телем.

— — □ — —



**Шәриф Биккол**

## Нигә, иркәм?

*Җыр*

Онытылам Идел буйларында,
Уйлар дулкынына күмелеп.
Нигә һаман, иркәм,
Синдә генә икән,
Синдә генә икән күңелем?
Йомшак кулың сөя кебек мине,
Чәчләремә тисә таң җиле,
Кушымта.
Дөнья балкып китә, күзләреңнән
Җылы караш торса сибелеп.
Кушымта.

Белсәң икән башка һичкемнең дә
Йөрәгемә якын түгелен.
Кушымта.

## Соңгы трамвай

*Җыр*

Озатып килдем җан кисәгемне,
Серләшә торгач, төн дә авышкан.
Сискәнеп киттек кинәт яңгыраган:
«Бу — соңгы трамвай!» — дигән тавыштан.
Соңгы трамвай килә,
Соңгы трамвай,
Туйга барган сымак ашыга.
Күңелемә сеңеп калган урыннар
Өзлексез чаба минем каршыга.
Трамвайга табан йөзә тын бакча,
Куптәнге бер кич һаман исемдә:
Очраттым мин башта иркәмне
Менә шушы күркәм бакча эчендә.

Уң якта калды тыныч бер урам,
Онытмыйм күңел шундый иртәне:
Шунда иң беренче тойдым иркәмнең
Ирене ничек кайнар икәнен.
Талпына сымак минем каршыга
Төзелеш барган яңа матур йорт.
Шул булыр, бәлки, бер көн иркәмне
Кәләшем итеп алып кайтыр йорт.
Соңгы трамвай килә,
Соңгы трамвай,
Туйга барган сымак ашыга.
Күңелемә сеңеп калган урыннар
Өзлексез чаба минем каршыга.



*Кәтибә Киньябулатова*

## Язмыш

Дөнья булгач, булыр шатлыгы да,
Кайгысы да торыр атлыгып.
Бөтенесен кабул итәм, дөнья,
Карама тик миңа ятсынып.

Шатлыгын да, хәтта кайгысын да
Өеп-өеп китер алдыма...
Ни булса да китер, тарсынма,
Тик өлешсез генә калдырма.

Авыр булсын, әйдә, тау шикелле, —
Күтәрәм мин аны, күтәрәм.
Кайсыларын салам иңнәремә,
Кайсыларын башка күтәрәм.

Әгәр булса ана сагышы,
Күз яшьләре икән баланың —
Йөрәкләрем аша үткәрәм...
Тик миннән соң туган кешегә
Җиңел булсын, дим дә күтәрәм.

## Бик күп кирәк

Күп кирәкми, дисең, кеше өчен?..
Бик күп кирәк, уйлап карасаң,
Таудай кирәк, күл, диңгездәй кирәк,
Әгәр шулай әйтү яраса.
Бик күп кирәк —
Мең-мең йолдыз төсле,
Алтын комы төсле сүзләрнең,
Хуш исədәй чәчкә-гөлләрнең,
Нуры төсле көньяк җилләрнең.
Бик күп кирәк, кирәк кешегә,
Менә миңа, минем ишегә.
Юк, ул әйбер яки мал түгел,
Алтын-көмеш яки дан түгел,
Ул күп әйбер — йөрәк җылысы,
Хыялларга тулы бай күңел.

---



*Әнгам Атнабаев*

## Ышаныч

И ышаныч!
Әкият таңнарыннан,
Хыяллардан туган ышаныч,
Сабый бала кебек гел сафлыктан,
Яктылыктан торган ышаныч.

Шул ышаныч белән алдандым да,
Алдалым да бугай кешене.
Тәмле дидем әрем ачыларын,
Бигрәк ачы дидем төчене.

Кайчагында караны ак дидем,
Кара дидем кардай ап-акны.
Түмгәкне дә биек тау дип йөрдем,
Акыллы дип йөрдем ахмакны.

Үкенечле алданулар белән
Яраланган еллар кызганыч.
Ләкин миндә һаман исән әле
Сабый бала кебек ышаныч.

Сабый бала кебек әкиятләргә,
Хыялларга һаман ышанам.
Ераклыктан якынлыкны көтәм.
Җылы язны көтәм кышлардан.

Түмгәкләрне тау итәсем килә,
Ак итәсем килә караны,
Юкларны да бар итәсем килә,
Юк итәсем килми барларны.

Аналар бит безне бу дөньяга
Шул ышаныч белән яраткан.
Шул ышаныч белән алдамасак,
Алданмасак иде кабаттан.



*Әнвәр Бикчәнтәев*

# КОЙРЫКЛЫ ТЕЛ

*Хикәя*

Гадәттә, галим кешене бер караудан танып була: ул яшел яки соры эшләпә кия, галстуксыз йөрми, портфельдән аерылмый. Бу сыйфатларның барысы да Хәбир Мәхмүтовичта, әлбәттә, бар иде. Шуның өстәвенә, ул кара зонт күтәреп чыга, ә аяз була калса, — кәкре башлы таякка таянып йөри иде.

Әмма Хәбир Мәхмүтовичның кыска буйлы булуын һәм шуның белән аның бик кимсенүен әйтергә туры килә. Истә калырлык башка сыйфатлары юк. Аның йөзе хакында күп сөйләп торасым килми, Уфадагы башка биш йөз алтмыш мең дүрт йөз кырык ике йөз арасында бер ягы белән дә хәйран калдырырлык түгел. Хәбир Мәхмүтовичны атна саен диярлек очратып торсам да, алдап әйтмим, аның күзләренең төсе һич тә истә юк, бәлки, аларга игътибар бирмәгәнмендер...

Әле сөйләгәннәр — аның тышкы кыяфәте. Шушы төстә ул өйдән чыга, урам буйлап йөри, үзе укыткан техникумга килеп керә. Гомергомергә бер үк кыланыш кабатлана иде.

Иллә мәгәр, һәр кешенең бер караудан күрелмәгән сыйфатлары да була бит әле. Хәбир Мәхмүтович та алардан мәхрүм түгел иде. Кайсы берәүләр галим кешенең үзенә генә хас булган гадәтләрен «холык үзенчәлеге» яки аның җитешсезлеге дип карыйлар.

Ләкин минем Хәбир Мәхмүтовичка авыр сүз әйтәсем килми. Шулай да, ул озын сөйләргә, койрыклы фикер йөртергә ярата иде булмый. Шуның аркасында аңа гомер буена башыннан төрле могҗизалар кичерергә туры килде.

Моннан егерме ел элек ул гыйльми кандидат дәрәҗәсен алыр өчен 321 битле хезмәт язып, аны Мәскәүгә җибәргән иде. Ярты ел дигәндә җавап килде, анда: «Диссертациягезнең күләме бик зур булганлыктан, төп фикерегез ярылып ятмый, — диелгән иде. — Кыскартып карагыз, бәлки, шул чакта хезмәтегезнең бәһасе ачыклана төшәр...»

Хәбир Мәхмүтович кыскартырга дип утыргач, кулъязманың күләме 517 биткә җитте. Озакламый Ленинград каласыннан, аның хезмәте белән танышкан галимнәрдән мондый хат килеп төште: «Шактый ук кыскартканнан соң гына, кулъязманы аңлап булыр дигән өмет туды...»

Шуннан соң Хәбир Мәхмүтович үзенең диссертациясе өстендә биш тапкыр эшләде һәм аны төрле-төрле биш калага җибәреп карады. Бөтен җирдән дә: «Кыскартырга!» дигән хәбәр килгәч, ул үзенең хезмәтенең күләмен тора-бара 3222 биткә җиткерде. Тик шунысы үкенечкә калды, мондый зур кулъязманы укырга теләүчеләр табылмый башлады.

Әгәр дә бу сыйфат гыйльми өлкәдә генә сизелеп калса, аны ярты бәла дип кенә исәпләргә мөмкин булыр иде. Озын һәм буталчык сөй-

ләү көндәлек тормышта да гадәт булып киткәч, ул тулы бәлага әйләнде.

Хәтта алты яшьлек Дәръял исемле улы белән сөйләшкәндә дә «Үзеңне акыллы тот» яки «Намуслы бул!» дип бер сүз белән әйтү урынына, ул болай дип сөйли башлый:

— Беләсең килсә, — ди ул, — борын-борын заманда атаклы полководецларны хөрмәтләп, тантаналы рәвештә олылаганда, аны колесницага утыртып, башкала урамнарыннан йөртеп чыга торган гадәт булган. Шул вакытта аның янында басып торган бер кол: «Эреләнмә!» — дип кычкырып йөргән. — «Син үзеңнең нибары кеше генә булуыңны һичкайчан да исеңнән чыгарма!» Язмыш үзгәрүчән ул дип искәртер өчен, колесницаның артына кыңгырау белән камчы тагып җибәргәннәр, чөнки алар элек җәза кораллары булып исәпләнгән... Менә шушы гыйбрәтне син дә, Дәръял, исеңнән чыгарма! Яме?

Үзе эшләгән техникумда да ул сөйләүдән тыела алмавы белән дан ала. Әгәр бер укытучы: «Тегеләй эшлимме?» — дип киңәш сорап мөрәҗәгать итсә, «Әйдә, тәвәккәл ит!» — дип әйтү житә бит инде. Ләкин Хәбир Мәхмүтович мондый мөмкинчелектән тулысынча файдаланып кала, әйтәсе сүзен әйтеп бетермичә туктамый.

— Моннан ике меңме, өч меңме ел элек Рим башында берьюлы ике консул торган, — дип башлап китә ул. — Тарихчыларның әйтүенә караганда, аларның берсе батыр, икенчесе куркак булган, имеш. Бервакыт Римгә каршы сугыш башлангач, ике консул да гаскәрләр белән житәкчелек итә башлыйлар. Аларның берсе бер көнне, икенчесе икенче көнне командующий вазифасын үтәгән. Батыр консул житәкчелек иткәндә, гаскәрләр алга таба бара торган булганнар, куркакның нәүбәте житкәч, алар чигенгәннәр. Шулай итеп гаскәрләр бер урында таптанып торганда, дошман армиясе урый барып, Римне яулап алырга да өлгергән... Менә син, энем, шушы ике башлы Римгә охшый күрмә!

Шулай да Хәбир Мәхмүтовичның иң ялыктыргыч сүзләре җыелышларда сөйләнә. Алардан бөтен коллектив арып-талып беткән инде. Гадәттә ул бер сүзне ун тапкыр кабатлый, биш минутта әйтеп өлгерә торган фикерне илле минут буена чәйни. Аның нәрсә әйтәсен халык алдан белеп тора инде, чөнки ул һәрбер чыгышын:

— Акылсызлык — табигать тарафыннан бирелгән байлык булса да, аны еш файдаланып хыянәт итәргә ярамый, — дип башлый.

Әлбәттә, халык көлә. Ләкин ул иптәшләренең нидән көлүе белән кызыксынып тормый, туйганчы сөйли дә һәрбер чыгышын болай дип тәмамлый:

— Кием безне җылытмый, без үзебезне үзебез җылытабыз.

...Бу хикәянең ахыры шул: ярты төн житкәч тә, Хәбир Мәхмүтович, йокларга яткан бичәсе янына басып, ләззәтләнә-ләззәтләнә сөйләргә тотына. Ә бичәсе:

— Хәбир, зинһар өчен ят инде, йокы килә! — дип ялына.

Ләкин галим кешегә илһам килгәч, аны туктатыр көч табылмый.

— Мәхәббәт ул дүрт төрле була, — ди Хәбир Мәхмүтович. — Беренчесе — дәртле мәхәббәт, икенчесе — һәвәслек, өченчесе — мин-минлектән туган тойгы, дүртенчесе инде — бик якынлык...

Һаман әле аны инсафка утыртырга теләп, бичәсе үтенә бирә:

— Житәр инде! Утны сүндер дә ят! — ди.

— Озак яуланган мәхәббәт ир кеше өчен кимсенү булса, киресенчә, хатын-кызга дан гына өсти,— дип сүзен дәвам итә.

— Ятасыңмы, юкмы?

Нәкъ шул минутта Хәбир Мәхмүтович Хуҗа Насретдин белән булган вакыйганы исенә төшерә:

— Мәгълүм булуынча, Хуҗаның ике бичәсе булган,— ди ул.— Бервакыт карт бичә белән яшь бичә үзара бәхәсләшеп киткәннәр дә: «Безнең кайсыбызны күбрәк яратасың?» — дип, Хуҗага бәйләнә башлаганнар. Алардан котылу өчен: «Икегезне дә»,— дип җавап биргән ул. Бичәләр ул җавап белән генә канәгатьләнмәгәннәр, мондый сорау куйганнар: «Менә без өчебез дә бер көймәдә барабыз дип фараз итик. Кинәт көймә бата башлый. Я, әйт әле, кайсыбызны алданрак коткарыр идең?» Шул чакта Хуҗа олы бичәсенә борылып: «Кара әле, син үзең дә бераз йөзә беләсең түгелме соң?» — дип сораган, имеш...

Хырылдап йоклап киткән бичәсен күреп, Хәбир Мәхмүтович беразга гына сүзсез кала. Шуннан ул:

— Чак кына түзә алмады, — дип мыгырдый, — яңа гына йоклап киткән, ахрысы. Ни эшләргә? Уята башласаң, гауга күтәрәсен көт тә тор. Башка чара юк, тагы да аерым ятмый булмый. Әле дә диван бар әле, шунысы уңайлы. Ул булмаса, ни эшләр идең?

*Ибраһим Абдуллин*



# МИН НИЧЕК ИР КЕШЕГӘ ӘЙЛӘНДЕМ...

*Хикәя*

Кырык тугыз ел буе үземне ир кешегә санап йөргән идем. Исемем дә ирләрнеке — Мөнир. Анкетада да «җенесе» дигән графага ир кеше дип яза торган идем. Малайларым да моңа чаклы, аллага шөкер, «әти» дип эндәштеләр, ә менә шушы каһәрле йортка күчкәннән бирле (каһәрле дип, бер дә каһәрле түгел инде, газы, ваннасы, җылы суы, кайнар суы — һәммәсе дә бар) бичәгә әйләндем дә киттем бит. Безнең йортта яшәүче хатыннар үземне: «Аның шикелле ипле, аның төсле басынкы, хатын җанлы ирне барлык Башкортстанны эзләп чык, таба алмассың. Хәзерге кызлар да шундый тыйнак булмый. Аңа «почетлы ир» дигән исем бирергә, «Работница», «Азат хатын» журналларында карточкасын бастырып чыгарырга кирәк», — дип мактыйлар. Әгәр ишек алдында гомуми җыелыш була калса, чыдап торырлык та әмәл юк. Космонавтлардан кала иң мәшһүр бер геройга әйләнәм дә китәм. «Тартмый, эчми, келәмен үзе кага, чүп чиләген чыгарып түгә, хатынын курортка ялгыз җибәрә. Ә безнекеләр?..» «Сөйләмә инде... «Шәмсетдин күле»нә үнике көнгә генә ялгызымны җибәрде, анда да бер ел җанымны ашады. Имеш, күл буе ул сүнгән йөрәкләргә дә ут кабыза. Имеш, җырда да бит, күл буена кил, дип җырлана». «Ә безнеке, әйкәем, шартлап ярыласыңмыни, кичә дә ләх булып кайткан. Имеш, прорабларының туган көнен «юганнар». Прорабныкын юу, инженерларныкын юу, бичәңнекен юу, үзеңнекен юу... Алайса, ел буе «юышып» кына яшәмәк кирәк бит. Уңмадым, уңмадым ирдән, әйкәем». «Ии, синең әле,

ичмасам, эчсә дә, ята да йоклый, тавышы да, тыны да чыкмый. Ә минеке бит төне буе керфек какмый, үз-үзе белән сөйләшеп чыга. Йоклап китсә, хырылдавыннан люстра селкенә башлый». «Күршекәем, синең бер дә генә ирең зарлапырлыгың юк эле. Гомер эчендә бер эчә». «Ә ир булса, бер дә эчмәсен ул. Әнә Мөнир абый эчми дә, тартмый да». «Ә бүген хатыны аягына нәрсә кигән, күрдегезме? Импортный җылы итек. Югославиянеке, ахры, бик модный. Вәт ир дисәң дә ир, ичмасам. Бер магазинда сатмадылар, ә хатынына табып кидергән. Чөнки ул хатын җанлы. Безнең юньсез ирләребез кебек түгел...»

Уф-ф... Менә юкка гына мактыйлар бит үземне. Безнең йортта торучы ирләр миннән артык булмасалар да, бер дә ким түгел. Эчү ягына килгәндә, гафу итегез, булдыра алмыйм. Гастрит. Врачлар кушмый. Ә инде импортный җылы итекне... мена икмәк тотып ант итәм — валлаһи-билләһи, минем тамчы да гаебем юк. Бичәкәемнең ахирәте Ленинградка командировкага баргач алып кайткан...

Ләкин мин боларны егерме ике квартирага кереп, егерме ике хатынга һәм егерме ике иргә бәйнә-бәйнә сөйләп бирә алмыйм бит инде, иптәшләр. Әйдә, тел сөяксез, сөйләсеннәр, дип кул селтәр идем дә йөри бирер идем, ләкин шул тел бистәсе бичәләрнең ирләре күрә алмый бит үземне. Күрсәләр дә, күрмәмешкә салышып китәләр, инде маңгайлар маңгайга бәрелешсә, читкә борыла алмыйлар, «сәлам» дигәнне аңлатып ияк кагып кына үтәләр. Сизеп торам, әгәр рөхсәт итсәләр, алар мине юлбарыс кәҗә бәрәнен өзгәләп ташлаган кебек өзгәләрләр иде. Шулай итеп, мактауга түзеп, ирләр бойкотына чыдап, башымны иеп кенә йөри бирәм. Ләкин көннәрнең берсендә түзә торган нервым чак-чак шартлап өзелмәде. Бер көн кәефләнеп сызгыра-сызгыра эштән кайтып килəм. Ишек алдында спорт яратучы ирләр транзистор приемниктан хоккей ярышын тыңлап, күңел ачып утыра. Алтынчы квартирада яшәүче Хәләф дигән слесарь: «Шырпың бармы, Мөнир абый?», — дип сорамасынмы. Кемдер, абайламый калдым, ни эшләп аның шырпысы булсын, ул Мөнир түгел, Мөнирә дип әйтә салды. Кинәт, граната шартлагандай, бердәм көлү ишетелде. Аяк астымдагы җир җимерелә башлады, күз алларым караңгыланып китте. Әлеге кешенең үзегенә үтәрлек каты сүз әйтәсем килде, ләкин, барлык нервыларымны йодрыкларыма учлап тоттым да, башымны иеп, өйгә кереп киттем. Төн уртасына чаклы йоклый алмый, җәфаланып яттым. «Хәзер нишләргә инде бу ирләр белән? Әллә... әллә квартираны алмаштырыргамы? Башка урамга күчәргәме? Әллә...»

Шундый ачыну-пошыну уты белән янып йөргән көннәрдә, күптән күрешмәгән фронтовой дустымны очраттым. Башта, гадәттәгечә, хәлəхвəл сорашу, үткән хәлләрне искә алып көлешү, аннан... Аннан...

— Очрашу шатлыгыннан әллә берәр йөзне төшерәбезме, Мөнир дускай? — диде бу.

— Юк, юк, гастрит, — дип мыгырдандым. — Алайса, бер-ике кружка сыра каплыйк. Сыра эчкәннән инде әллә...

— Әлбәттә, гастритыңа берни дә булмаячак.

Ач, арыган көе эчкәнгәме, әллә өч ел авызга шәрап заты кермәгәнгәме, ике кружка сырадан исердем дә киттем бит, әй. Баш җиңелчә әйләнә, тамак кытыклана — җырлыйсы гына килә. Һәм, үзем дә сизмәстән, капка төбенә җиткәч, «Утыр әле яннарыма...» дип кычкырып җырлап җибәргәнмен. Гөнаһ шомлыгыма каршы, анда ике хатын басып тора икән. Берсе: «Һи-и, әллә Мөнир абый эчеп алган инде», — дип авызын ерды. Икенчесе: «Танавың тоймыймыни, авызыннан аракы мичкәсенең исе аңкып тора бит», — дип чыраен сытты. Ә мин әллә оялуымнан, әллә күзем томаланудан аяк астындагы кирпечкә абынып, сөртенеп киттем һәм очып барып төштем.

Икенче көнне эшкә барганда безнең йортта яшәүче ирләр, әллә кайдан ук елмаеп: «Мөнир дуска кайнар сәлам!» — дип кулларын күтәреп исәнләштеләр. Хатыннар гына: «Барлык ирләр дә бер чыбыктан сөрелгән ул», дип чыш-пыш киләләр килүен, ләкин мин хәзер андый чыш-пышларга игътибар итә торган кеше түгел. Миңа иң мөһиме ир кеше исемен йөртү. Ир!

*Фәрит Исәнгулов*



# БАЛАЛАРЫМ, ГАЗИЗЛӘРЕМ!

*Хикәя*

Безнең төзелеш конторасының баш бухгалтеры Ибраев үз эшенә бик бирелгән кеше булып чыкты. Әйтте — эшләде. «Була», — дидеме — син «булмас» дип шикләнеп йөргән нәрсә дә була. «Булмый»,— дидеме, ул соравың белән кабат якын да йөрмә. Тупас кеше түгел ул. Ихлас сөйләшә. «Булмый», — дигәндә, ни өчен булмаганын төпченә башласаң, ул дәлилләр китереп аңлатыр да сине ышандырып чыгарыр. Бактың исә, аның «була» дигәндә дә, «булмый» дигәндә дә төп таянычы — ышандыру көче икән.

Ибраевның әлеге шул ышандыру көче дигән сәләте гомерне страховать итү турындагы соңгы җыелышта аеруча ачык күренде. Бу мәсьәләне караганда, әлбәттә, исәп-хисап, акча эшләренә иң якын мөнәсәбәттә булган кеше — бухгалтер димче-докладчы итеп билгеләнгән иде.

Ул сүз сөйләп озак вәгазьләп тормады, туп-туры мисалларга күчте:

— Галимә апай, бишенче каттан сезнең башыгызга кирпеч төште ди: шап! Тын да ала алмыйсыз...

— Тәүбә, әстәгъфирулла! — диде Галимә апай, күзләрен очып, ярдәм сорагандай, тирә-яктагыларга ялварып карады.

— Әйе, әйе, — дип тагы да җитдирәк дәвам итте бухгалтер. — Ну, кирпеч кенә үтерә дә алмасын, ди. Алайса, бер тонналы тимер балка — гөрес! Җыештырып җирләргә әгъзагызның бер кисәге дә калмады... Әгәр дә ки сезнең гомерегез страховкаланган булса, ирегез, балаларыгыз, шатланышып барып, каерып страховка акчасын алыр, күмү расходлары күренми дә калыр...

— Аб-ба-а, сез, Ибраев агай, бигрәк... — дип сүз кыстырды сварщик Галләм.

— Юк, юк, һичбер алдау юк, барысы да законлы, — дип, аңа карап сүзен ялгады докладчы. — Менә, Галләм энем, син, ай-һай, хәтәр эштә

эшлисең. Иртәгә, очкын чәчрәп, тома сукыр калдың, ди. Страховкаң булса, әлбәттә, сумманы тоташ түгел, бер өлешен аласың. Ул да бер кесә акча. Төкерми дә рәхәтләнеп типтереп яшисең. Ә инде сукыраеп кына калмыйча, сварка миеңне тишеп, өтеп чыкса, тулысынча аласың. Вәт бит ул ничек!

Җыелыш бүлмәсе аһ-уһтан гүләп алды.

Төсе тәмам качкан бер җиңги кутәрелде:

— Юл йөргәндә бер-бер хәл булса, ни рәвешле?

— Ә-э, — дип үтә канәгатьләнү белән сөйләп алып китте Ибраев.— нәкъ өстенә бастыгыз, сеңелем! Сезнең ирегез шофер бит әле? Ерак командировкада. Әнә, тышта нинди коточкыч буран котыра! — Ул йөзенә шомлы төс чыгарды. — Ирегез яланда адашкан. Машинасы баткан. Ул инде баранкасына ябышып туңып утырган. Ә китәр алдыннан гомерен страховать итәргә уена да килмәгән. Балаларыгызны какъ таякка атландырып китте бит, мәлгунь, дуңгыз! Андый ирнең ирлеге — ташка үлчим!.. Сеңелем, ичмасам, үзен җәһәтрәк страховать итеп күр. Балаларыгыз үксез-ятим калгач, нишләрләр?!

Озынга сузмый гына әйткәндә, Ибраев җыелыш барышында һәрберебезнең — я үзен, я бичәсен, я ирен үтереп, бер дә булмаса гарипләндереп чыкты.

Миңа — конторада эшләп утырган җиремнән — инфаркт! Аһ та итә алмый калдым.

Ташбулат краннан егылып төшкән! Ыһ итеп кенә өлгергән.

Гайнисламның кайтуына, бичәсе газ белән агуланып, фани дөньяны куйган!

Сыңар аяклы библиотекаребыз Сафуан, китап киштәсе авып, икенче аягыннан да язган. Хезмәт хакына, кечкенә булса да инвалидлык пенсиясенә өстәмә страховой акчасы алып, төкерми дә, авызын ерып урамда йөри.

Безнең бичәләр, сөенешеп, страховой кассага йөгерешәләр!.. һ. б. һ. б.

— Ә балаларны страховать итәләрме? — дип сорадым мин.

— Әлбәттә, — дип, әсәрләнеп, тирләрен сөртә-сөртә тезеп алып китте Ибраев. — Күптән кирәк иде. Балалар өчен Яңа ел бәйрәме — иң куркыныч чор! Әйтик, менә бүген син эшкә киткәч, балаларың елка утларын яндырганнар да... Гөлт! Сөякләре дә калмагандыр... Әгәр аларны элегрәк страховать иткән булсагыз.

Ибраев минем белән бер йортта тора. Аның гаиләсе нәкъ безнен квартираның өстендә яши.

Минем ачу кабара башлады:

— Я, я, Ибраев, юк шом салма әле күңелгә. Безнең елкада шәмнәр югын үзең күрдең бит...

Мин елканың үз балаларымның гомеренә зыян китерә алмавын әйткәч, Ибраев, аерата төпченеп, шунда ук икенче афәт эзләп тапты.

— Сон дөньяда бүтән хәвеф-хәтәр беткәнмени? Әйтик, син киткәч тә, түшәмең җимерелеп төшкәндер дә... Лып! Һәм ике балаң урынында — ике юеш урын... — Ул, «авызыңны яптыммы» дигән төсле, тантаналы елмаеп, миңа карады.

Тәнем, чынлап та, эсселе-суыклы булып китте.

— Юкны юрамачы әле! Түшәмгә кагыла күрмә. Минем түшәмнең үзегезнең идәнегез булуын да онытма... Ул җимерелсә, үз балаларың соң?..

Шуны әйтеп тә бетерә алмадым, — Ибраевка мәет төсе керде. Ул, трибунада торган көе, елан чаккан шикелле, «һай-й!» итеп акырып җибәрде дә пальтосыз, бүрексез, урамга чыгып йөгерде:

— Балаларым!.. Газизләрем!..

*Вәзих Исхаков*



# БАЗАР ТАВЫГЫ

*Хикәя*

Әйткәндәй, бөтен бәлане бичә тудырды. Шуннан башланды эш. Магазиннарда йөреп кайтты да бу:

— Магазинга тавык китергәннәр, әллә аласы инде, — дигән булды.

— Кит әле, магазин тавыгы да булдымы тавык!

— Алай димә, Вәли. Кеше бик ала. Өреп тутырган кебек, шундый симезләре бар.

— Булмас, булмас. Куй, юкны сөйләмә, — дип, мин каршы төштем. — Магазинга килгән тавыкның ни тәме дә, ни яме дигәндәй. Менә базардан алсаң, ичмасам, другой хәл. Магазин тавыгына исем киткәне юк.

Бичә дә усал шул:

— Тәтесә китәр иде әле, бик тәтеми шул, — ди.

Шулай сүз артыннан сүз чыгып, үзара әрепләшә торгач, ачуым килде. «Кайда, — дим бичәгә, — бир акча. Базарга барам да тавыкның менә дигәнен алып кайтам».

Хәзер инде тавык итен ашыйсы килү, чынлап та, минем уй-фикерне биләп алды. Симез тавыкның өреле шулпасында пешкән тәмле токмач минем күз алдыма килеп басаандай булды.

Әйдә, булышмыйсың дип теңкәне корыта иде, бичәгә бер ярдәм дә булыр, дигән булып, урамда йөгереп уйнап йөргән алты яшьлек кызымны иярттем дә, тавык алып кайтырга дип, базарга киттем.

Юл уңаеннан азык магазинына керсәм, анда ни, әлеге шул минем бичә авыз суын корытып мактаган тавыкларны саталар иде.

— Һ-һи-и... — Эчтән генә көлеп куйдым. — Шушы нәмәгә исе китә диген халыкның, ә?!

Дөрес, ул көн атна уртасы булу сәбәпле базар әллә ни рәтле түгел иде. Тавык эзләп ары сугылдым, бире сугылдым — тик юк кына бит эзләгәнем.

— Вәт син агай, — мин әйтәм, — ризыкка язмадымы икән ни...

Шулай бит ул: бер нәрсә эшләргә теләп, аны эшли алмасаң, яки берәр нәрсә ашарга теләп, аны тапмасаң, ачу килүчән. Андый чакта үчләшеп әнә шул әйберенне булдырырга, ничек кенә булса да табарга тырышасың. Ул көнне, күрәсең, минем белән дә әнә шундыйрак хәл булды. Тик менә, хәерчегә җил каршы дигәндәй, бөтен базарны айкап эзләсәм дә, һичбер тавык әсәре күренмәде. Уңмаган юлга чыкканмын икән, каһәрең, дип авыз эченнән генә мыгырданып, кайтыр якка борылган идем, кыз минем җиннән тотып тарткалый башлады.

— Әти, әнә бер тавык, — дип сул якка төртеп күрсәтте.

Бардык. Карадык. Ботинка сала торган тартмага салган бәләкәй генә тавык иде ул. «Әһә-ә, — дип уйлап алдым мин. — Чебеш тавык икән...» Сездән яшереп торып булмый инде, мона кадәр өйгә бөтен азык-төлекне бичә ташый торган иде. Әле бүген базарга чыгуым да аның белән бәхәсләшүдән генә бит. Күп уйлап тормадым, тәвәккәлләп сорадым:

— Тавыкны ни хакка бирәсен, агай?

— Бүш хак, энекәш, буш хак, — диде тавык сатучы агай. — Нибары 2 сум 50 тиен сорап торам.

— Шушы бәп-бәләкәй нәрсәгәме?

— Бәләкәй булса ни, тавык бит ул...

— Ике сум!

— Юк, ул хакка гына бирә алмыйм.

— Бирмәсәң...

Без инде әзрәк кенә булса да базар гадәтен беләбез. Монда сиңа магазин түгел — сораганны биреп торырга! Юри генә борылдым да китә башладым.

— Кара әле, энекәш, — дип тавык сатучы агай артымнан килә башлады, — мә, ал!

Шунда ике берлекне чыгардым да агайга суздым. Тавыкны кызга тоттырдым.

— Бәй, нигә бик җиңел бу?

— Җиңел, дип ни, тавык сыер түгел — әллә ни тартмый инде ул...

Без кузгала башлагач:

— Энекәш, — диде бу агай миңа каршы төшеп, — тавыкка дога кылып калырмын, янә бер ун тиен өстә инде.

Аны-моны уйлап тормастан, ул сораган ун тиенне дә бирдем. Ни булса да базар тавыгы әле, магазинга китергән, әллә кем муеның борып ыргыткан нәрсә түгел, дип кешеләргә сиздерми генә, эчтән генә кинәнеп тә куйдым.

Кыз юл буе тавык белән уйнап кайтты: әле саргаеп беткән кикригеннән тота, әле борынын кыса.

— Кара аны, очырып җибәрә күрмә, — дим аңа.

— Юк, эти, очмый ул, — ди кыз. — Аның аягы бәйләнгән.

Өйгә кайткач, кыз тавыкны ташлаган да кухняга кереп киткән. Әллә ялгыз калудан файдаланып, әллә инде берәр нәрсәдән куркып, тавыгыбыз кыймылдый башлый. Ләкин үзе утырган тартмадан да чыга алмый, бахыр.

Ванна булмәсенә кереп тавыкны суйдым да бичәгә бирдем.

— Бик юаш тавык, ахрысы, — дим аңа, — суйганда «ыһ» та итмәде.

— Авыру тавык бит бу! — ди хатын. — Шушы вакытта андый арык тавык буламыни?

Ул да булмады, үзебезнең өлкән яшьтәге бер апаебыз килеп керде.

— Әйдүк, апай, — дидем аны каршылап, — авызың бәхетле икән, әле генә менә тавык суеп торам.

Тавыкны пешекләп, тазартуны апай үз өстенә алды.

— Үз гомеремдә мин бик күп тавык асраган кеше, — диде ул. — Алар белән минем башым-күзем тонып беткән инде.

Әмма тавыкны кулга алуы булды, апаем шунда ук күңелемне сүреллерде дә ташлады.

— Кит моннан, дивана, бу тавыкмыни, хәшәрәт бит!..

— Вәли алып кайтты аны, — дип бичә дә тизрәк бәлане минем өскә аударырга ашыкты.

— Кит, кит, тәүбәкәем. Шушы да тавык буламы?

Әмма хәтәре алдарак булган икән. Тавыкны ярып җибәрсәләр... Тәүбә, тәүбә! Аның эченнән чыккан нәрсәләрне күргән кеше гомер буе тавык ите ашамас иде. Чын. Ул да булса мин чебеш дип алган тавык, узган елдан бирле авырып, бавыры шешеп, ите корып беткән бер нәрсә икән.

— Магазиннан гына алган булсаң, — ди апаем. — Анда мондый үләксә китермиләр.

— Син аны әйтәсең әле, апай, — дип сүзгә керешә бичәм. Ике сум түләгәне житмәгән, дога кылып калырмын дигәнгә ышанып, ун тиенне яңадан өстәп биргән әле ул.

— Өлкән яшьтәге кеше булгач, бирдем тагы... — дидем мин, аклanырга тырышып.

— Догасы корсын, үләргә аяк сузган тавыгын базарга алып чыккан кешесен әйтер идем! Оятсыз.

— Безнең Вәлигә шул кирәк ул, — хатын авыз ерып миннән көләргә тотынды. — Гомере буена магазиннан алганны яратмый — гел генә әрләшә иде. Мактаганы базар була торган ие, әйдә пешерик, базар тавыгы бит — ашасын үзе...

Ләкин ул тавыкны ашамадым мин. Чыгарып ыргыттым. Һәм менә шул көннән соң хатын магазиннан ни алып кайтса, шуңа бик ризамын.

— Ярый, — мин әйтәм, — магазинга ни килсә, безгә шул ярый. Тик менә килеп кенә торсын инде...

Совет властеның 50 еллыгына

*Фатих Ибраһимов*

# Без түбәннән күтәрелдек

Күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимовның зур осталык белән әйтелгән шушы тәгъбире Бөек Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгына әзерлек барган бу көннәрдә языла торган бик күп мәкаләләрнең һәм хезмәтләрнең исемнәрен бизәрлек. Әгәр Совет властеның беренче елларында, төгәлрәк итеп әйткәндә 1922 елда, «Кызыл чәчәкләр» повестен бөек әдип әнә шул сүзләр белән башлап киткән икән һәм Россиядә социалистик революция булуны, авылда беренче комсомол ячейкалары, беренче клублар, беренче драмтүгәрәкләр оештырылуны «түбәннән, тормыш төбеннән күтәрелү» дип атаган икән, безгә, алтмышынчы-җитмешенче еллар югарылыгына менеп җиту бәхетенә ирешкән буын кешеләренә, бу тәгъбир бигрәк тә тәңгәл туры килә.

Октябрь көяшы Җир шарының алтыдан бер өлешенә үзенең тәүге алсу нурларын сибә башлаган вакытта без кем идек һәм хәзер кем булдык? Ни өчен безгә шулай түбәннән, тормыш төбеннән күтәрелергә туры килде? Совет властеның 50 еллык юбилеена әзерләнгән бу көннәрдә әлеге сораулар, уй-фикерләр кемнең генә башына килмәс икән?! Әйе, чыннан да, без кем идек? Хәзер кем булдык? Бөек Октябрь безгә нәрсәләр бирде, тагын ниләр эшлисебез бар?

Рус мәмләкәтендә үги баладай яшәгән вак милләтләр арасында безнең хәлебез дә шәптән түгел иде. Экономикабызны, тормыш-көнкүрешебезне әйтеп тә тормастан, башка халыклар кебек үк, рухи яктан да без нык кимсетелгән, кыерсытылган идек. Дөрес, татар халкының бай тарихы да, мең ел белән исәпләнгән матур әдәбияты, үз алфавиты, үз мәктәп-мәдрәсәләре, үз әлифбалары, дәреслекләре дә, ныгып, аякка басып килә торган театры да бар иде. Шуңлыктан безгә культурабызга нигез салуны, башка күп кенә үксезләр шикелле, бары Бөек Октябрьдан соң гына башлап китәргә туры килмәде. Әмма теге яки бу милләтнең культура дәрәҗәсен болар гына тулысынча билгеләп җиткермиләр, культура төшенчәсе, югарыда саналганнардан тыш та, бик күп нәрсәләрне үз эченә ала әле.

Бер генә минутка үткәннәребезгә борылып карыйк. Бөек пролетар революциясенә чаклы безнең профессиональ композиторларыбыз, көй чыгару осталарыбыз, яиса опера һәм балет театрыбыз, профессиональ җырчыларыбыз, махсус хор коллективларыбыз булганмы? Булмаган. Инде килик сынлы сәнгатькә. Революциягә кадәр безнең профессиональ рәссамнарыбыз, аларның кулга алып күрсәтерлек әсәрләре, үз милләтебезнең тормыш-көнкүрешен чагылдырган картиналары бар идеме? Тагын шул ук җавап: юк иде! Бу юнәлештә безде тик беренче һәм бик зәгыйфь адымнар гына ясала иде.

## БУЛГАН ЗАМАННАР, БЕЗГӘ ҖЫРЛАРГА ДА ЯРАМАГАН...

Бер нәрсә дә юктан бар булмый, һәр нәрсәнең билгеле бер алшартлары, үзәлгәрләре була. Әгәр без, урамдагы асфальт астыннан борынлап чыккан үлән яки агач үсентесен күреп, гаҗәпкә калабыз икән, төптәнрәк уйлап карасаң, монда әллә ни могҗиза юк. Шушы урында кайчандыр элеге үсемлекнең орлыгы яки тамыры күмелеп калган. Әнә шул үзәлгәр, яңа көч, яңа дәрт белән асфальтны тишеп, юлындагы киртәләрне ватып-җимереп, үзенә юл сала. Яктылыкка, яшәү мөхитенә омтыла. Татар халкының профессиональ музыка һәм сынлы сәнгате белән дә эш шулайрак тора.

Иң элек музыка сәнгатебезгә тукталыйк. Ерактагы бабаларыбыз, аларның атабабалары да җыр-музыка яратканнар. Аларның табигатенә салынган композиторлык орлыгы, эчке һәм тышкы сәбәпләр аркасында, ул чакларда да күңелләрдән тышка бәреп чыга торган булган, әнә шулай яңа көйләр, яңа җырлар туа торган.

Халык ул көйләрне туйларда, бәйрәмнәрдә, бала тирбәткәндә, авыр тормыштан гаҗиз булып, күңелен бушатканда җырлаган. Нотаның әле нәрсә икәнен дә белмәгән заманнарда бу көйләрне кем саклаган? Шул ук халык. Ул көйләр һәм аларның җырлары авыздан-авызга, бабадан атага, атадан балага ишетелеп (билгеле, иң шәпләре, йөрәкләрне уеп кергән урнашканнары), бер буыннан икенчесенә күчеп килгән.

Тик шунысы кызганыч, халыкның гаять бай иҗат җимеше безнең көннәргә тулысынча килеп җитә алмаган. Аларның күпчелеге, вакытында нотага салынмаганлыктан, юкка чыккан, онытылган.

Татар халык җырларын җыю-туплау һәм өйрәнү эше бездә шактый соңга калып башланган. Бу юнәлештәге беренче адымнар XIX йөз башларына туры килә. Башлангыч тәҗрибәне И. Добровольский ясый. Ул Астрахань татарларының көйләрен туплап, 1816—1818 елларда аларны бастырып чыгара [1].

Шул ук йөзнең кырыгынчы елларында, Петроградтан Идел буена концерт куярга килгәндә, композитор Карл Шуберт та татар көйләрен язып ала. Соңыннан, шул язмалары нигезендә, татар көйләрен ул кыллы музыка кораллары өчен эшкәртә. Бу — безнең көйләребезне эшкәртә башлауның беренче тәҗрибәсе. XIX гасырның ахырында В. А. Мошков һәм С. Г. Рыбаков Идел-Кама бассейны халыкларының музыкаль иҗаты һәм Урал мөселманнарының музыкасы һәм җырлары турында махсус гыйльми хезмәтләр белән чыгыш ясыйлар.

Шул ук XIX гасырда бу эшкә татарлар үзләре дә тартыла башлый. XIX гасырның күренекле галиме Ш. Мәрҗани, татарлардан беренче буларак, музыканың тарихын, аның әһәмиятен язып чыга. Ул болай ди: «Музыкадан төп максат — төрле тавыш һәм көйләрне бер-берсенә яраштырып күркәм һәм матур итеп төзү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына әзәрү. Көйләрнең кайберләре шатландыра, кайберләре кайгыга төшерә, кайберләре көлдерә, җанландыра һәм биетә. Бишектәге бала хуш авазга юанып елаудан туктый һәм игътибарын шул авазны тыңлауга юнәлдерә».

Бөек мәгърифәтче Каюм бабаның фикерләре дә бик кызык. Мәгълүм булганча, ул үзенең «Фәвакиһелҗөләса»ның утызынчы бүлегеи музыканың әһәмиятен аңлатуга багышлый. Каюм Насыйри музыканың әһәмияте турында язып кына калмый, халык җырларын җыя, аларны өйрәнә, беренче буларак, рус теленә тәрҗемә итү эшенә дә керешә.

1869 елда Г. Ваһапов «Җырулар» китабы бастырып чыгара. Бу кечкенә китапка 300 дән артык кыска җыр тупланган. Мөгаллим Гайса Еникеев, 1883 елдан башлап, 50 ел буена диярлек татар-башкорт көйләрен җыеп килә. Ул 150 гә якын көй туплый. Аңа көйләрне нотага салуда профессор А. И. Оводов ярдәм күрсәтә. Фольклорчы Гыйлаҗетдин Сәйфуллин татар көйләрен җыю белән генә чикләнми, аларны «Стелла» дигән музыка коралында һәм граммофонда уйнату өчен пластинкаларга язу белән дә шөгыльләнә. Гариф Минкин татар көйләрен пластинкага 1890 елларда яза башлый.

Мәгълүм ки, XX йөзнең башларында, бигрәк тә 1905—1907 елгы революция уңае белән, Россиядә революцион-демократик хәрәкәтнең көчәюе татар халкының

---

[1] М. Нигъмәтҗанов. Татар халык көйләрен җыю һәм өйрәнү мәсьәләләре. «Совет әдәбияты». 1964 ел. 3 сан.

талантлы улларының бер-бер артлы тарих сәхнәсенә чыгуларына этәргеч ясый. Алар безнең сәнгать нәфисәбезне профессиональ дәрәҗәгә күтәрү буенча зур кайгыртучанлык һәм эшчәнлек күрсәтәләр.

Реакцион карашлы мулла-ишаннар исә үз чиратында җыр җырлауны, гармун уйнауны олы гөнаһ, язык эш дип тыкылдауларын дәвам иттерәләр. Аларча, музыка да, җыр да хәрам иде. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында Зыяның әнисе Зөләйха остабикә музыка турында менә ничек фикер йөртә:

«...Музыка тарту — барыбер, уйнаш итеп тотылу, ат урлап кыйналу, урамда җырлап йөрү кебек үк. Музыканы инде һичбер вакыт адәм рәтле кеше уйнамый. Алар бар да азгыннар, тәүфыйксызлар була. Әнә, егетләр белән тотылып, аты-чабы чыккан Бәдрелхаят, әнә, атасын ач тотып, талкан акчасын эчеп бетерә торган Тимеркәй, тагы шундый эштән чыккан, тәүфыйкларыннан язган егетләр — менә бит музыканың әһелләре кем?»

Муллалар һәм урядниклар хакимлегендәге «кара татар авылы» гына түгел, хәтта мәдрәсә шәкертләре дә музыкадан, күңел ачу, җырлау-биюдән мәхрүм ителгәннәр иде. «Ул чакларда җырлау, гармун, скрипка, мандолина шикелле музыка коралларыннан файдалану, уйнау-көлү, — дип хәтерли элеккеге Мөхәммәдия мәдрәсәсе шәкерте Габдрахман ага Вәлитов, — дин ягыннан бидгать (ярамаган эш) исәпләнгәнлектән, аларны тотуга рөхсәт юк иде. Аңа карамастан, күзәтчеләр юклыктан файдаланып, яшерен-посырын уйнаштыра идек... Мәдрәсәнең түрәләре булмаганда, хор белән дә җырлый идек. Шундый кысынкы шартларда җырлап җибәрү — дөньяда әле шундый күңелле нәрсәләр дә барлыгын искә төшерә иде».

Юк, халык, аеруча яшьләр бирешмәгәннәр. Качып-посып булса да кызлар кубыз тарта, аулак өйләргә, каз өмәләренә җыелып, гармун уйный, егетләр, мунчага качып яки ат белән куна баргач, төннәрен музыка уйнап үткәргәннәр. Сабан туйларында, җыеннарда, солдатка киткән вакытта да яшьләр гармун уйный торган булганнар.

Менә шушы шартларда татарның алдынгы эшлеклеләре халык иҗатын яклап чыгалар, аны пропагандалау юнәлешендә ныклы эш җәелдерәләр. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Фатих Әмирхан, Шәйхзадә Бабич кебек әдипләребез һәм шагыйрьләребез, Фатих Кәрими, Харис Фәйзи (Җәүдәт Фәйзинең әтисе), Заһит Нуркин, Шаһит Әхмәдиев кебек эшлеклеләребез һәм журналистларыбыз бу мәсьәлә турында кабат-кабат язалар. 1906 елда Г. Тукай безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, яңаданяңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайрәләргә мохтаҗ, дип ачынып чыга. 1910 елның 15 апрелендә бөек шагыйрь «Шәрык клубы»нда «Халык әдәбияты» дигән мәшһүр лекциясен укый: «Халык җырлары чын үзебезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм... Нечкәнәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәгемнән минда туган телебезне сөю туды. Әгәр миңа җырлар ярдәм итмәсә, мин соң... туган телебезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик була алыр идеммени?» [1], ди һәм лекциясен мәшһүр «Туган тел» шигыре белән тәмамлый.

Әгәр «Туган тел» шигыренең матбугатта әлеге лекциядән соңрак күренүен һәм аңа бер яңа куплет өсталүен искә алсак, шагыйрь лекциясендәге фикерләрен раслау өчен аны махсус рәвештә язмадымы икән, дигән фикер туа.

Габдулла Тукай халык җырларына зур өмет баглый һәм халык җырлары безнең мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачак, дип әйтә.

Шуннан берникадәр соңрак, бөек корифейларыбызның икенчесе Галимҗан Ибраһимов та шул ук мәсьәләне күтәреп чыга. 1915 елда «Аң» нәшрияты сәнгать нәфисә сөючеләргә «Альбом» чыгара. Сөекле әдип шул «Альбом» мөнәсәбәте белән бер-ике сүз яза. «Бер-ике сүз» генә дип исемләнсә дә, ул шактый зур мәкалә. Күренекле язучы үзенең хезмәтендә татар халкының әле һаман да профессиональ композиторлары, рәссамнары, архитекторлары, һәйкәлчеләре булмауга зур борчылу белдерә.

«Ашказар вә Тәфтиләү иялләре русның Чайковскийлары, полякның Шопеннары була алмаган икән — моның өчен табигатька түгел, тарихка, язмышка үпкәләргә мәҗмүрбез, — ди ул. — Теләгән гөлнең тууы өчен орлык кына җитми, аның яхшы

[1] Г. Тукай. 4 томлыкның 2 томы. 274 бит.

туфракка чәчелүе, вакытында яңгыр вә кояш тиюе, таш белән, фәлән белән басылып калмавы шарт. Безнең халыкның табигатенә чәчелгән музыка истигъдадлары — орлыклары шул шартлар булмаганнан гел булып үсә алмый калганнар, чәчәк ату, җимеш бирүне хәтергә дә китереп булмый инде» [1].

Галимҗан Ибраһимов Россиягә һәм рус мәмләкәтендәге халыкларга XX йөз җиленең шифалы тәэсирен яхшы тоя, ул безнең культурабызның үсеш тенденциясен дөрес бәяли һәм зур ышаныч белән фикерен түбәндәгечә дәвам иттерә: «Каплап яткан таш [2] соңгы елларда ярылды, һәм шуның белән санаигы нәфисәнең иң садәсе булган әдәбият баш күтәрдә — халык эчендә булган иҗат вә сәнгать орлыклары яңа шагыйрьләр, хикәячеләр кыяфәтендә тәҗассем итә, үсә башлады, яфрак атты, инде чәчәкләр дә күренә.

Музыка белән дә, хода насыйп итсә, шул хәл булачак. Музыка хәрамдерме, юктырмы — хәзер аны тикшермиләр. Халык киң бер һөҗүм белән музыкага ташланды, аңар гомуми мәел, гомуми дәрт: яшь кызлар, яшь егетләр эчендә музыка коралларыннан берсен белүне үзенә идеал итмәгәннәр сирәк табылачак. Бу гомуми дәрт, бу гомуми мәел — туачак композитор өчен суларга һава, тамыр җәярга туфрактыр».

Туачак композитор! Бөек әдип татар халкының язучылары гына түгел, бәлки тиздән үзенең көйләрен нотага сала алучы, үз көен үзе уйный белүче профессиональ композиторлары да булачагы турында хыяллана.

Заманалар үзгәрү белән надан, миләре катып беткән фанатик муллалар инде халыкны дин сереме белән куркытып тора алмый башлыйлар, халык музыкага омтыла. 1905 елдан татар театры эшләп килә. 1904 елда Казан музыка училищесы ачыла. Татарлардан бу мәктәпкә кереп укучылар булмаса да, аның беркадәр йогынтысы тими калмый. Скрипкачы Гали Зайкин, пианиначы Заһидулла Яруллин, гармунчы Фәйзулла Туишев, җырчы Фәттах Латыйпов, музыка эшлеклесе Солтан Габәши — профессиональ музыка тудыру өлкәсендә беренче карлыгачлар булалар. 1910 елда ачылган «Шәрык клубы» да халык арасында музыка пропагандасы алып бара. Укытучы Гайса Еникеев, музыка остасы Гыйлаҗетдин Сәйфуллин кебек һәвәскәрләр башлаган эшне башка бик күп инициаторлар дәвам иттерәләр. Шундыйларның берсе Гатаулла Исхакый дигән укытучы була. Ул 1913—1916 елларда, нота һәм мандолинага мөгаллимсез өйрәнүчеләр өчен, ике кисәктән торган «Нота дәфтәре» бастырып чыгара. Бу инде, музыкадан татарча беренче әлифба буларак, моңа хәтле әйтелгән идеяләрне материаллаштырып, халыкка җиткерүдә җитди бер адым иде. Чыннан да җәмәгатьчелекнең мондый «Әлифба»га сусаган булуы авторның икенче «Дәфтәр»гә язган сүз башыннан да күренә. Ул анда «Дәфтәр»нең беренче кисәге яхшы каршы алынуы, музыка сөючеләрнең икенче кисәген дә чыгаруны сораулары турында әйтә.



«Нота дәфтәре»нең тышлыгы.

«Нота дәфтәре»нең беренче китабында, тышлыкта мандолина тоткан хатын-кыз рәсеме. Аның башында калфак, бармагында — йөзек, беләгендә — беләзек. Өстендә яңача тегелгән алсу күлмәк, биленда зәңгәрсу пута. Хатын-кыз — табигать фонында: арткы планда зәңгәрсу

[1] «Альбом», «Аң» наширы. 1915 ел.
[2] Г. Ибраһимов биредә 1905—07 елгы буржуаз-демократик революция тудырган уяну, азатлык хәрәкәтенә ишарә ясый.

күк йөзе, таулар, алдарак — каеннар, ә иң алда — рәшәткәле култыкса. Ханым кулындагы мандолинаның бер башы аның чәченә, икенчесе әлеге култыксага тиеп тора.

Тышлыкның икенче битендә «Дәфтәр»нең эчтәлеге китерелә, укучыларга «Берике сүз» әйтелә. Автор «Дәфтәр»нең максатын болай билгели: «Бу нота дәфтәре, музыкадан һичбер гыйлеме булмаган кешеләргә карап, һәм көйләрне нотага алырга өйрәнү максаты белән язылганлыктан, мөмкин кадәр көйләремезнең садә вә җиңел уйнала торганнарын күрсәттем. Асыл максадым иптәшләремә, мөгаллим ярдәменнән башка, нота гыйлемен һәм мандолина уенын белдерүдер».

«Нота дәфтәре»нең беренче кисәгенә 25 ләп, икенче кисәгенә 30 га якын көй кертелгән. Алар белән танышу авторның көйләр сайлауда шактый талымлы булуы турында сөйли. Анда «Аяныч факыйрь», «Икмәк беткән», «Бала Мишкин», «Вәй деньяй», «Икенче садә», «Колаксыз Зариф», «Таш тугай», «Татардыр бабам» (М. Гафури сүзләре), «Биби Асма», «Оренбург», «Зиләйлүк», «Бәйрәм бүген», «Тотса маскәүләр якаң» (Г. Тукай сүзләре), «Күгәрчен», «Порховой Фатих», «Нарасый бала», «Поляк», «Әйхәйлүк», «Алтын-көмеш», «Салкын чишмә», «Сакмар», «Кара урман», «Тәфкилеф», «Ашказар», «Әллүки», «Зәйнәп» (башкортча), «Һамак» (башкортча бию көе), «Тагын бер һамак», «Русча тормә көе» һәм башкалар бар...

Әнә шулай бер-бер артлы, әмма акрынлык белән, профессиональ музыкага таба адымнар ясала.

Халкыбызның табигатенә салынган сәнагы нәфисәнең орлыклары тишелеп чыксын өчен һәм чәчәк атсын өчен, Галимҗан Ибраһимов әйткәнчә, әле «ярылган ташны» юлдан алып ташларга кирәк иде. Моны Бөек Октябрь революциясе эшләде.

Заһидулла Яруллин белән Солтан Габәшиләр күтәрә башлаган профессиональлек байрагын татар халкының талантлы улы Салих Сәйдәшев тотып алды һәм ышанычлы адымнар белән алга алып китте. Безнең халкыбызның музыка өлкәсендәге бәхете шунда: Салих Сәйдәшев тирәсенә, Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Фәрит Яруллин, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Хөснулла Вәлиуллин һ. б. кебек бер төркем гаҗәп талантлы композиторлар тупланды. Алар хәзер дә профессиональлек байрагын югары тоталар һәм яңадан-яңа әсәрләр белән безне шатландыралар.

Совет власте елларында татар музыкасы жанр һәм форма ягыннан бик нык баеды. Халык җырлары белән беррәттән, опера, балет, музыкаль комедия, симфония, романс кебек бик күп яңа жанрлар һәм формалар барлыкка килде.

«Сания» (1925), «Эшче» (1930) операларының аяклары җиңел булды. Хәзер безнең дистәдән артык опера һәм балетыбыз бар. «Шүрәле», «Алтын чәч», «Муса»ларның даны үз мәмләкәтебез чикләренә генә сыймады, башка илләргә дә таралды. Хәзер безнең филармониябез, җыр һәм бию ансамблебез, халык иҗаты йортыбыз, опера һәм балет театрыбыз, симфоник оркестрыбыз һәм башка бик күп музыкаль коллективларыбыз бар.

Без бу уңышларыбызның бөеклеген ерактагы үткәнебез белән чагыштырып карaганда гына бөтен тулылыгы белән тоябыз, тик шул чакта гына без уңышларыбызны күз алдыбызга китерә һәм без кем идек дигән сорауга, менә кем булдык, дип, горурлык белән җавап бирә алабыз.

*(Ахыры киләсе санда.)*

*(Ахыры киләсе санда.)*

## ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

*Шамил Бикчурин*

# МОГҖИЗА ТУДЫРУЧЫЛАР

*Очерк*

**КИҢӘШМӘ. «ТУЗГА ЯЗМАГАН» ЧЫГЫШ.**
**НЕФТЬЧЕЛӘР ШИКЛӘНӘЛӘР. ГАЛИМНЕҢ БОРЧЫЛУЫ.**

Бар ишекләр берьюлы ачылып киттеләр. Уңнан да, сулдан да, төркем-төркем булып, караңгыга кешеләр чыкты. Берәүләр, баскыч янында ук туктап, тәмәке кабыздылар да сөйләшеп калдылар, икенчеләре, бинадан ерак түгел генә көтеп торган машиналарына утырып, китеп бардылар, өченчеләре, ашыкмыйча гына урам буйлап җәяү атладылар. Халыкның күплеге һәм караңгы урамнарның машиналар, кешеләр тавышыннан җанланып китүе үзе генә дә киңәшмәнең зур, мөһим булганын сиздереп тора иде.

Карангыга күзе ияләшмәгәнгәме, Вахитов, адашкан кешедәй, тирә-ягына карангалап торды. Аңардан ерак та түгел, кемнәрдер әле һаман сөйләшәләр иде. «Пыяла», «труба» дигән сүзләр ишетелгәч: «Киңәшмәнең дәвамы», — дип уйлап алды Вахитов, сигаретын алып кабызды, ирексездән аларның сүзләренә колак салды.

— Ул пыяла труба дигәнең, барып чыкса, кызыклы нәрсә, — ди берсе. Икенчесе шактый кызып, гайрәтләнеп сөйләп китте:

— Безнең нефтьчеләр кулына эләксә, пыяла трубаң түгел, корычың да чыдамый ич! Җыен тузга язмаган сүзләр галимнәрдән чыга!

Көлешteләр дә, бер-берсе белән хушлашып, таралыштылар.

Вахитов та кайту ягына таба борылды. Арган да, кирәгеннән артык борчылган да иде. Юк, әле генә галимнәр адресына әйтелгән сүзләрдән түгел. Андый ачы сүзләрне галимнәргә шактый еш ишетергә туры килә. Соңгы вакытларда уздырылган киңәшмәләрдән, җыелышлардан, утырышлардан арды ул. Бигрәк тә күбәеп китте бит. Ай саен диярлек совнархоз уздыра. Ике атна саен нефть берләшмәсе үткәрә. Атна саен горком ясый. Нигә ерак китәргә, үзләренең нефть фәнни-тикшеренү институтында да җитәрлек ул җыелышлар, фәнни совет утырышлары, бюролар, летучкалар. Ә галимгә гыйльми эш белән кайчан шөгыльләнергә кала? Кайчан ул докторлык диссертациясен тәмамларга, үзенең фәнни хезмәтен кайчан бирергә тиеш? Менә ун ел буена инде һәр киңәшмәдә диярлек парафиннан котылу чаралары турында, нефтьчеләрнең дә, галимнәрнең дә теңкәләрен корыткан парафин турында сүз бара. Нинди генә явызлыклар эшләмәде, нинди генә мәшәкатьләр тудырмады ул. Трубаларга юшкын булып утыра торган парафиннан котылу өчен ниләр генә уйлап тапмадылар да, ниләр генә эшләп карамадылар. Нефть юлларын төрле кул кыргычлары белән дә, оча торган, үрмәли торган кыргычлар белән дә, «керпе»ләр белән дә чистартып карадылар — парафинның сылануы сылану. Скважинага автомат кыргычлар көйләделәр, ләкин трубаларга утыра торган каһәр төшкән парафиннан котыла алмадылар.

Бүгенге киңәшмә дә парафин проблемасына багышланган иде. Аның белән көрәш мәсьәләсе бигрәк тә шушы бер-ике ел эчендә иң мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелде. Скважиналар, еллар үтү белән, әкренләп фонтанлаудан туктадылар, нәтиҗәдә, нефтьтәге парафин трубаларга тагын да әрсезләнебрәк утыра башлады.

Парафинга каршы көрәшнең янарак, уңайлырак ысулларын уйлап табуны Бөгелмә галимнәренә — нефть фәнни-тикшеренү институты сотрудникларына тапшырдылар.

Киңәшмәдә Вахитов залдагыларның күзләре үзенә текәлгәнен яхшы тойды. Чөнки кем-кем, ул — Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары — киңәшмәдәгеләргә күңел юатырлык, куанычлы бер сүз әйтергә тиеш иде. Һәм, сүз алып, ул трибунага күтәрелде. Искеләрне искә төшермәде, озак сөйләмәде.

— Парафиннан котылу юлы бары тик бер генә, — диде ул. — Трубага аның утыруын гомумән булдырмау.

— Ә ничек? — дип төрле яктан шунда ук сорау ташладылар.

— Нефть трубаларының эчен пыяла белән каплатырга кирәк.

Зал җанланып китте. Кайсыларыдыр бер почмакта гөр килеп көлештеләр, аргы башта шау-шу кузгалды. Сизеп торды Вахитов: институт директоры Еронинннан кала, президиумда утыручы олы ук абзыйлар да бу сүзнең җитдилегенә шикләнәләр иде.

Әллә чыннан да Вахитов тузга язмаганрак сүз ычкындырып куйдымы? Татарстанның нефть осталары, авторитетлы агайлар җыелган шундый зур киңәшмәнең биек трибунасына басып, тумаган яңалык турында кычкырырга иртәрәк түгел идеме икән?

## ТРОНОВ ПЫЯЛАГА ГАШЫЙК. ПЫЯЛА — СУКСАҢ УАЛА. ЙОМГАК ОЧЫН ЭЗЛӘП МАКСУТОВ ЮЛГА ЧЫГА.

Иртән Вахитовның иң беренче теләге институтның фәнни сотрудникларын күреп, кичәге киңәшмәдәге хәлләр турында сөйләшү иде. Ул башта институт директоры Еронин янына керде, аның белән туп-туры лабораториягә, Тронов янына китте. Галимнәр хыялый халык. Төн чыкканчы әллә никадәр яңалыклар ачылган, әллә нинди газаплы серләр чишелгәндер кебек. Белеп булмый, пыяла дигәнеңнең, бәлки, көтелмәгән яңа сыйфатлары табылгандыр... Василий Алексеевич белә: пыяла киңәшмәдәгеләр уйлаганча, Вахитовның фантазиясе генә түгел, ул институт галимнәренең бердәнбер өметенә әйләнеп бара иде инде. Институтның өлкән фәнни сотрудникы Валентин Петрович Тронов айлар буе парафинны өнәми торган материаллар эзләде. Сынау өчен скважинага корыч та, бакыр да, алюминий да төшереп карады — парафин аларга да ябышты. Төрле пластмассалар, полиэтилен, фторопласт, капрон, нейлон кебек материаллар да скважина эчендә булып чыктылар — парафин аларны да «үз итте». Хәтта алтынга да сылана икән парафин. Бары тик пыяланы гына сөйми булып чыкты ул.

Алар лабораториягә кергәндә, Тронов, бөдрә чәче яртылаш коелган башын аска иеп, төрле-төрле пыяла пластинкалар арасында казынып утыра иде. Айлар буе бер үк нәрсә белән мавыгу аны инде ялыктырган булса кирәк, ул керүчеләр белән теләртеләмәс кенә исәнләште. Аларның нәрсә сорыйсыларын инде ул алдан ук белә иде.

— Кызганычка каршы, бер нәрсә белән дә шатландыра алмыйм, — диде Тронов һәм пыяла пластинканы алып урыныннан торды. — Бары тик пыяла гына парафинны әтәреп җибәрергә сәләтле. Безгә, минемчә, пыяла тирәсендә генә биергә кирәк...

Вахитов көрсенеп алды:

— Әйе, пыяла... Тик, суксаң уала... — Ул, ачынып, кичәге киңәшмәне, нефтьчеләрнең урамда сөйләшеп торуларын исенә төшерде. Дөрес әйттеләр: алар кулына эләксә, пыялаң түгел, корычың да чыдамый...

Алга килеп баскан проблема бер Вахитов белән Еронинны гына түгел, бөтен институт сотрудникларын аякка бастырды. Һәрберсенең диярлек гыйльми эшләре, яза торган диссертацияләре, нефтькә нинди дә булса мәсьәләне хәл итү буенча алган темалары булуга карамастан, пыяла күбесен гашыйк итте, ләкин әле йомгакның очы күренми иде. Уйланалар, киңәшәләр, бәхәсләшәләр... Бичара пыялага чамасыз күп таләпләр куела: ул бик тиз эресен дә, труба эченә дә бик яхшы сылансын! Тимер кебек чыдам,

корыч кебек нык булсын! Суыкта ярылмасын, кызуда чатнамасын! Әйбәт киселсен дә, яхшы тишелсен дә! Әмма әлегә андый пыяланың дөньяда барлыгын берәүнең дә ишеткәне, күргәне юк иде.

Техник фәннәр кандидаты Максутов та нефть һәм газ кудыру буенча зур фәнни эшләрен бер читкә куеп, могҗизалы пыяланы эзләргә кереште. Туймазы шәһәрендә булды — пыяла заводын карап кайтты. Нефтьчеләргә ярашлы пыяла анда да юк, медицина таләпләренә җавап бирсә, алар өчен шул җитә икән. Төрле техник журналлар, белешмәләр, китаплар актарып утырырга, пыяла эретү, ябыштыру технологияләрен укырга гадәтләнеп китте Максутов. Пыяла сүзе чыккан бер генә газета мәкаләсен дә калдырмый хәтта.

Пыяла турында берәр яңалыкка юлыкмаммы дип, иске журналлар караштырып утыра торгач, бер көнне Максутовның күзе кечкенә генә хәбәргә төште. Мәскәүдәге пыяла фәнни-тикшерену институты сотрудникларының вак кристаллы, утә каты, нык пыяла уйлап табулары турында язылган иде анда.

«Таптым!» — дип кычкырып җибәрүдән аны тыйнаклыгы гына тотып калды. Шулкадәр күтәреп мактаганнар пыяланы, «Каты корычтан да катырак», дип язганнар. Исеме дә бик хикмәтле: «Ситалл» дип атала икән. Исемен теләсә ни дип атасыннар, әмма бу хәбәр Максутовны һавага чөйгәндәй итте. Журналны тотып ул шунда ук нефть бүлеге начальнигы Геннадий Васильевич Кострюков бүлмәсенә йөгерде.

Геннадий Васильевич белән алар тиз генә аскы катка, Вахитов янына төшеп киттеләр.

Вахитов, көндәгечә, докторлык диссертациясе белән мәшгуль иде. Инде төрле сынаулар, экспериментлар артта калган, үзенең берничә еллык хезмәтен кәгазьгә төшерәсе, бастырып Гыйльми советка тапшырасы гына бар. Диссертация яклап, техник фәннәр докторы буласы килүдән генә ашыкмый ул. Ромашкино нефть чыганагында күп төрле «кара алтын» мәйданнары бар, һәр мәйданда нефть берничә катлам булып ята. Нефть катламына суны, сукыр рәвештә, теләсә никадәр җибәрәләр. Вахитовның бу хезмәте нефть ятмаларының чикләрен билгеләүдә, һәр катламга су кудыруны төгәл белергә ярдәм итәр иде. Ә менә диссертацияне тәмамларга һаман вакыт тими, күңелне көн саен туып торган яңа проблемалар борчый. Шуларның иң зурысы хәзер: пыяла мәсьәләсе. Пыяла затыннан булган кремний җир шарының сиксән процентын тәшкил итә бит! Димәк, Тронов дөрес юлга төшкән. Ул әйткәнчә, пыяла тирәсендә биергә кирәк.

Максутов белән Кострюковның яңа сортлы пыяла турында хәбәр алып керүе Вахитовның күңеленә хуш килде. Алар, бергәләп, Еронин бүлмәсенә керделәр.

— Сиңа бүгеннән үк Мәскәүгә китәргә кирәк булыр,— диде Еронин Максутовка, хәбәрне укып чыккач. — Бүгеннән үк!

## СЕМАФОР. ХИКМӘТЛЕ КӨПШӘ.

Вагонның салкын тәрәзәсенә борыныңны терәп, юл буендагы барлык нәрсәләрне күзәтеп, семафорларны санап кайтудан да рәхәт нәрсә бар микән! Гел кинодагы кебек: кадр артыннан кадр алышынып кына тора. Менә, әле генә күз алдында еракгагы тауларга кадәр сузылган яшел болын иде. Ул болын зур бер авыл белән тоташты. Авылны таш юл кисә, анда семафор. Авылның теге башында куаклар. Алар да артта калды, инде поезд урман эченнән чаба. Поезд, гүя агачларны аудара-аудара, урманны ярып бара. Тәмәке кабызган арада инде тагын пейзаж алышынган: аста кечкенә елга, елгада вак кына көймәләр, кечкенә генә кешеләр. Семафор. Поезд ниндидер тау арасында. Өскә ишелердәй булып торган зур-зур ташлар чалынып кала. Менә стрелкачы будкасы, ишек төбендә сары флагын күтәргән бер хатын-кыз. Тагын семафор... Димәк, поезд ниндидер разъездга яки станциягә якынлаша...

Семафорларны күргән саен, Максутов үзенең бала чагын, әти-әнисе белән Урта Азиягә барган чагын искә төшерә. Тугыз яшь иде аңа ул вакытта. Сугыш башланыр алдыннан туган авылы — Мөслимнән киттеләр алар. Иң беренче откан сүзе дә «семафор» булды бит аның. Семафорның нәрсә икәнен соңыннан гына белде ул. Кешенен

тормышы да нәкъ шушы поезд кебек гел алга чаба, аның юлында да бик күп, бик күп семафорлар тора икән...

Яңа урынга килеп, ике ел тору белән сугыш башланды. Әтисе фронтка китте, шуннан кире кайтмады. Әнисе ерак җирләрдә өч бала белән утырып калды. Бик тә кыен, авыр иде яшәве. Рәфкать ач-ялангач укыды, дәрестә башы әйләнде, күзләреннән зәңгәрле-яшелле утлар күренә иде. Ләкин ни өчендер алар Рәфкатькә еракта күренгән семафорлар булып ялтырадылар. Ниһаять, ун класс тәмам. Ул, гомерендә икенче мәртәбә поездга утырып, ерак юлга чыга. Кесәдә — рус теленнән дүртле, калган фәннәрдән бишле булган аттестат, хыялда — Мәскәү, нефть институты, алда — семафорлар, семафорлар...

Студентлар Рәфкатьне тормышта сирәк очрый торган бәхетле кешеләрнең берсе дип саныйлар иде. Имеш, ул экзаменнарны уңышлы гына тапшырып, аңсат кына институтка керде, җил-давылсыз стипендия алып, җиңел генә укыды. Дәүләт имтиханнарында да аңа «бәхетле» билетлар гына чыкты, институтын кызыл диплом белән бетерде. «Кызыл диплом»ның нинди тырышлыклар хакына, йокысыз төннәр бәясенә төшкәнен ул үзе генә белә.

Рәфкать эшкә китәргә җыенып йөри иде инде. Ул нефть инженеры булып эшләү өчен туган Татарстанына кайтачак. Алда — тагын семафорлар... Иөзләгән алар, меңләгән...

Көтмәгәндә аны деканатка чакырдылар, аспирантурада калырга тәкъдим иттеләр.

Аспирантураны тәмамлап, ул Бөгелмәгә, яңа гына ачылган Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институтына кайтты. Куңелендә — яклаячак диссертация, чемоданында — шул эш буенча китап-дәфтәрләре иде. Хәзер дә шул ук чемодан, ә эчендә...

Мәскәүдән Максутов пыяла алып кайтмый. Чемодан эчендә — эче пыялаландырылган кечкенә тимер көпшә. Максутов инде аны зурайтып, нефть трубалары итеп күрә. Бәлки, бу нәрсә дә киләчәк өчен якты семафордыр?

Максутовның Мәскәүгә пыяла өчен китеп, аннан нинди дер хикмәтле көпшә алып кайтуы институт сотрудникларында шактый кызыксындыру тудырды. Үрнәк өчен алып кайткан бармак калынлыгы көпшә кулдан-кулга күчеп йөрде.

## ЯҢА КЕШЕ. БУШКА ТАМГАН ТИР БӨРТЕКЛӘРЕ. ПЫЯЛА КЫЙНАУДАН КУРЫКМЫЙ.

Еронин алдагы көннәр өчен эш планы төзү белән мәшгуль. Иң беренче итеп ул «Донбасска, Константиновка пыяла заводына барырга, трубаларны пыялаландыру технологиясен өйрәнеп кайтырга», дип язып куйды. Максутов алып кайткан кечкенә трубаларның эчен шунда пыялаландыралар икән. «Икенче. Институт каршында яңа лаборатория ачарга, мичләр, приборлар һәм башка җиһазлар табарга. Өченче. Сынауларны башларга!..» Дүртле санын куйды да уйга калды. Кешеләр кирәк. Моны инде план төзеп кенә табып булмый. Галимнәрнең яңа идеаларын тормышка ашыруда ярдәм итәрдәй инженер-техник кадрлар кирәк.

Шулай уйланып утырганда ишек шакыдылар.

— Керегез.

Зур гәүдәле бу кешене Еронинның кайдадыр күргәне бар иде.

— Утырыгыз, — диде исәнләшкәннең соңында, янындагы урындыкларның берсенә күрсәтеп.

Керүче тартынып торучылардан түгел иде, баш түбәсендә генә калган чәчләрен сыпыра-сыпыра, түргә барып утырды.

— Мин Губарев булам, Яков Федорович. Сезгә эшкә килергә исәп.

— Инженермы?

— Инженер.

Башка вакытта булса, Василий Алексеевич инженерларга алай ук шаккатмас иде. Аңа инде инженерлар гына түгел, эш сорап байтак кына галимнәрнең дә мөрәҗәгать иткәннәре бар. Ә менә хәзер ул гади бер инженерның булмага килеп керүенә шатланып бетә алмады.

— Промыселданмы, буровойданмы?

— Бөгелмә аракы заводыннан.

Еронин, нәрсә әйтергә белмәгәндәй, карангалап алды, ашыгып-ашыгып кәгазьләрен актарырга керешт. «Аракы заводыннан... Менә сиңа инженер», дип уйлап алды ул. Тукта, Еронин аның турында ишеткәне бар иде кебек. Тик кайда? Ничек итеп?

— Сезне, әлбәттә, аннан ни өчен китүем кызыксындырадыр, — диде Губарев. Еронинның шикле карашын сизеп алып. — Андый сорауны бер сез генә бирмисез... Чөнки аракы заводында озак еллар эшләдем бит... Сораучыларга мин шаярып: «Башыма аракы исе ярамый», — дип җавап бирәм. Әмма миңа аракы белән эш итәргә туры килмәде. Машиналар, механизмнар төзәтү иде минем һөнәрем...

Яков Федорович көрсенеп тә, зарланып та андагы хәлләрне сөйләп китте. Соңгы елларда, башка аракы заводларындагы кебек үк, Бөгелмә аракы заводы да чимал җитештерүдән аксый башлаган. План үтәлмәгән, машиналар тик торган, искергән, тузган. Барысы да директор белән баш инженер өстенә... Җиһазларны яңарту, запас частьлар табу өчен бик күп чапкан Губарев. Аның саен тиргәгәннәр генә. Тегесен-монысын юнәлтү өчен хәтта аңа спирт та тоттырып җибәргәннәр.

— Заводым өчен тырыштым, — диде Губарев ачынып, — гаепле генә булып калдым...

Әйе, Еронин бу турыда ишеткән иде шул. Инженерның яшермичә, ачыктан-ачык сөйләве Еронинда ышаныч уятты.

Һәм Губаревны институтка эшкә алып ялгышмадылар. Нефть тирәсендә белеме бик сай булса да, тәҗрибәле инженерларда гына була торган практик сәләте белән ул алар дөньясына бик тиз кереп китте. Эшли башлавының беренче көннәрендә үк аны, пыялаландыру ысулын карап, өйрәнеп кайту өчен Донбасска җибәрделәр. Әйдә, сынау срогын шунда уздырсын, үзенең кемлеген күрсәтсен, янәсе. Өйрәнеп, аннан да бик тиз кайтып килде ул. Лаборатория өчен электр миче табуга, аны урнаштыруга, көйләүгә бик күп көч куйды. Ул кыру станогы янына басып болтын, гайкасын да ясый, слесарь да булып ала, электр эшенә дә керешеп китә.

Бу көннәрне Еронин да, Кострюков белән Максутов та лабораториядән чыкмадылар. Хәтта Вахитов та, докторлык диссертациясен ташлап, лабораториягә бикләнде. Кайсының иягеннән, кайсының борын очыннан тир тама. Бөтенесенең дә күзләре мичтә, өч метр гына озынлыгындагы нефть трубасында. Шунысы барып чыкса да шат булырлар иде, ләкин, нигәдер пыялаланмый гына. Икенче трубаны мичкә тыгалар — тагын юк. Аннан: «Таптык бит җибәрер кешене!» — дигән сыман, барысы берьюлы акаеп карыйлар.

Бу трубалар үзенең бирелгән язмышын хәл итәсен аңлаган бичара Губарев нишләргә белми, кызара, бүртенә, ничәнче тапкыр инде галимнәргә аңлатмакчы булып маташа:

— Шушылай инде, нәкъ шушылай: трубаны аласың. Аның эченә кечерәк диаметрлы пыяла көпшә тыгасың. Аның ике башы да ябыштырылган, ягъни томаланган булыр. Трубаны янып торган мичкә саласың. Ул кыза, пыяла эреп киңәя дә, трубаның стенасына берегә. Шулай инде, нәкъ шулай...

Тагын нәкъ Губарев сөйләгәнчә эшләп карыйлар — чыкмый. Труба эчендәге пыяла я куыкланып кала, я сырланып-сырланып ката.

Галимнәр тәмам түземлекләрен җуеп баралар. Вахитов лаборатория буйлап йөренә башлый. Кострюков бер читкә китеп тәмәке тартырга керешә. Еронин тәрәзә янына килеп, тир катыра.

— Бәлки нечкә трубаларда гына мөмкиндер? — дип нәтиҗә ясый ул.

Максутов белән Губарев мич янынннан китмиләр, әледән-әле температура режимын алыштырып, трубаларны әйләндергәләп, сынауны дәвам итәләр. Чия кебек кызарган бу труба да мичтән алына.

Труба өстенә чәчләре коела башлаган, агарган һәм агара төшкән башлар иелә. Коела башлаганы Еронинныкы. Баш түбәсендә чәче утрау кебек калганы Губаревныкы. Агара башлаганы Вахитов белән Максутовныкы. Сирәкләнгән коңгырт чәч Кострюковныкы. Чак суыну белән, куллар берьюлы диярлек идәндә яткан трубага үреләләр. Аны беренче булып түземсез Вахитов ала, күзен труба көпшәсенә куя.

— Булган! — дип кычкырып җибәрә ул.

Әйе, булган. Нәкъ алар хыялланганча — труба эче көзге кебек ялтырап тора.

Инде лабораториядәгеләр бу кадәр назлы трубалар белән эш итү мәсьәләсендә генә борчылалар. Беренчедән, юлда шоферларның дангыр-донгыр килеп йөрүләрен тыярга, икенчедән, нефтьчеләрнең бәрә-суга эшләүләренә чик куярга кирәк булыр, диләр. Белмим, мичтән чыккан трубаларга галимнәр үзләре дә кагылырга курыккач, инструкцияләр генә ярдәм итәр микән?

Бракка чыккан трубаларның пыяласын кубарып яңадан мичкә кертергә кирәк иде. Труба эчендәге пыяланы коеп төшерергә исәплап, Губарев кулына чүкеч алды, сукалый башлады. Ләкин бу ни хәл — пыяла кубарга уйламый да.

— Кара син аны!

Гайрәтен күрсәтергә исәплап, чүкечкә Максутов ябыша. Колакны тындырып металл чыңлый, әмма пыяланың трубадан аерылырга исәбе юк.

— Я әйтегез, бу нәрсә инде?

Кувалда алып, трубаны чиратлап тукмыйлар, янып төшәләр, әмма назлы дигән пыяла урынында нык утыра бирә.

— Егетләр, бу бит көтелмәгән хәл! — дип кычкыра Кострюков.

Ахырда, трубаны мичтә кыздырып, эченә салкын су җибәрделәр. Пыяла чатнады, аны бәрә-бәрә коеп төшерделәр. Пыяланың ныклыгына, озын гомерлегенә шик калмады.

## МАКСУТОВ ҖИЛКЕНӘ. ТОРМЫШ САБАГЫ. ҖИДЕ КАТ ҮЛЧӘГӘННӘН СОҢ.

Пыялаландырган трубаларның беренче даннәре чыгу белән үк, аларны скважиналарда сыныйсы килү дәртеннән Максутов үзе дә мич кебек әчтән яна башлады. Шушы өчәр метрлы трубалардан булса да, җыеп колонна төзисе иде, аны нефть катламына төшерәсе иде. Моның өчен кимендә менгә якын труба ясарга кирәк. Ләкин Еронин да, Кострюков та, Вахитов та ашыкмыйлар төсле. Бәлки алар: «Без трубаның беренче үрнәкләрен күрсәттек, калганын нефтьчеләр үзләре дәвам итсеннәр», — димәкче булалардыр?

Ахырда, эш бетәр алдыннан Максутов Кострюков янына керде. Яшь галимнең болай түземсезләнеп йөрүен нефть бүлеге начальнигы бик яхшы төшенә иде. «Җиде тапкыр үлчә, бер тапкыр кис», — дигән бик матур мәкальне онытa Максутов. Элек Кострюковның үзенә дә галимнәр яңалык кертүдә әкрен кыймылдыйлар төсле күренә иде. Гомер узган саен, тәҗрибәсе арта барган саен уйлап, үлчәп эш итәргә кирәклеген аңлады ул. Вакытлы проблемалар, бүгенге көн өчен генә яраклы эшләр белән мавыгып нефтьчеләр дә, галимнәр үзләре дә вак-төякка күпме көч, акча сарыф иттеләр. Шушы парафин мәсьәләсен генә алып карыйк. Трубага утырган парафинны кыруны башта тимер чыбыкка кыргыч асып кул чыгырларына көйләделәр. Һәр скважинага киткән көч 1800 метр тирәнлектәге коедан чиләк белән су чыгаруга тигез иде. Аннан кыргычны күтәртү электрга җайлаштырылды. Скважина саен электр линияләре үткәрелде, будкалар салынды. Эштән бушатылган операторлар урынына электриклар артты. Берничә елдан скважиналарны читтән торып идарә итүгә күчтеләр. Диспетчер пунктлары төзелде, скважиналарга кабельләр суздылар. Штат, кимү урынына, тагын артты. Хәзер инде промыселларга диспетчерлар, радио һәм телефон белән эш итүчеләр дә кирәк иде. Бу ысул да үзен акламады. Линиядә чыбык өзелүләр, шуның нәтиҗәсендә скважиналарның эше туктап тору, нефть баклары тулып ташу кебек хәлләр күбәйде. Телемеханик системага күчтеләр. Һәр промыселны бу система белән идарә итү өчен гаҗәп кыйммәтле һәм катлаулы аппаратуралар, приборлар белән җиһазлау, һәр скважина саен телевизион мачталар кую, инженер-техниклар тоту мәңнәргә төште. Ә соңыннан үзен акламады — телемеханик система бер типта булганлыктан, алар барлык промыселларда да бер үк дулкында эшли булып чыкты. Шуның нәтиҗәсендә скважиналардан килгән сигналлар да бутала, ялган мәгълүматлар бирә.

Нефтьчеләр дә, аларның заказларын үтәүче галимнәр дә күп еллар буенча ялгыш юлдан бардылар. Бөтен эш парафин утыруны бетерүгә түгел, ә утырган парафинны кырдырып чыгаруга багышланды.

Шушыларны Максутовның исенә төшергәннән соң:

— Әле трубаларның юлы озын, — диде Кострюков. — Аны барлык режимнарда сынарга кирәк! Сынарга да сынарга!

Институтта Геннадий Васильевичның нефть эшендә тәҗрибәсе башкаларга карағанда зуррак. Максутов аның биографиясен дә яхшы белә. Кострюков сугышка кадәр үк Мәскәү нефть институтында укыган. Фашистларның бомбалары башкалага төшә башлаганда, ул дүртенче курста була. Үзе теләп коммунистик батальонга языла һәм Мәскәүне сакларга китә. Аларны хәрәкәттәге армиягә кушып җибәрәләр. Орудие командиры була ул, ике тапкыр яралана. Институтны бары тик 1950 елда гына тәмамлый, шул елны аспирантурага керә. «Галимлек карьерасын миңа Мәскәүдә, нефть институтында ук башлап җибәрергә мөмкинлек бар иде, — дип сөйләгәне бар Геннадий Васильевичның. — Тик мине практик эш тартты». Аспирантураны бетерү белән ул Лениногорск промыселларының берсендә өлкән инженер, аннан промысел мөдире, Татарстан нефть берләшмәсендә бүлек мөдире булып эшли.

Геннадий Васильевичның шуннан соңгы биографиясен инде Максутов үзе дә күреп белә. Максутов бирегә килгәндә, Кострюков фәнни-тикшеренү институтында нефть бүлеге начальнигы иде. Ашыкмый, хәрәкәтләрен чамалап кына эшли, сүзләрен үлчәп кенә сөйли торган бу галим егетнең игътибарын шунда ук үзенә тартты. Галим булудан бигрәк, аңарда җитәкче сыйфатлары күзгә бәрелеп тора иде.

Яңалыкны скважиналарда сынау өчен җилкенеп торса да, Максутов Кострюков белән килеште. Дөрестән дә, трубаларның скважинага төшкәнен күргәнче әле бик күп айлар көтәргә язган икән. Бу яңалыкка чамасыз күп таләпләр куелды: трубаларны кисеп карадылар, тишеп карадылар, юнып карадылар. Берсенә дә бирешми торган булып чыкты пыялаланган труба. Скважинага ялгап төшерү өчен сырлар салдылар — анда да карышмады. Сварка аппаратын алып килделәр. Бу трубаларны эретеп ялгарга да була икән. Монысын инде хыялга бай кеше — Вахитов та көтмәгән иде. Пыяланың газаплары шушының белән тәмам, дип уйлаган иде инде Максутов, ләкин трубаларны тагын Мәскәү лабораторияләренең берсенә җибәрделәр. Аларны анда өзеп тә, изеп тә, яньчеп тә карагannар — бөтенесе нормада булып чыккан. Аннан йөз илле-ике йөз метр трубаны җир өстендәге нефть юлына ялгап, парафинга каршы торышын өч-дүрт ай буена тикшерделәр — нәтиҗә яхшы!

— Менә хәзер инде скважинага төшерергә дә мөмкин, — диде Кострюков.

## ТУГАН КӨН. ФАКЕЛЛАР ҺАМАН ЯНА. ГАЛИМНӘРНЕҢ ФАҖИГАСЕ. МЕҢ ЯМАУЛЫ СКВАЖИНА.

Бөгелмәдән 50—60 километрлар ара булса да, Максутов скважинага нефтьчеләрдән алда килеп җитте. Машинадан төшеп, скважина тирәсен әйләнеп чыкты, әйберләрне барлады. Эш урынында бөтен нәрсә әзер иде инде. Мачта куелган, трубаларны төшерү инструментлары килгән, үзләре ясаган өчәр метрлы трубалар, әрдәнә кебек, штабельләргә өелгән.

Сынау өчен галимнәрнең менә шушы, әллә кайда ерактагы, «Лениногорскнефть» идарәсенең 4 нче промыселы скважинасын сайлап алулары тикмәгә түгел иде. Бу 1711 нче номерлы скважина парафин утыруы белән дан тоткан, операторларны иза чиктергән, каргаулы бер скважина икән. Аңа тәүлек саен ике-өч тапкыр парафин кыргыч төшергәннәр. Бүгеннән, 1962 елның 27 августыннан башлап, бу скважина парафин утырмый торган беренче скважина булып нефть тарихына кереп калачак. Өчәр метрлы трубалардан ялганган мең ямаулы скважина.

Бу көн яңа скважина туган көн генә түгел бит әле. 27 август көнне Рәфкатьнең дә дөньяга килгән көне. Аңа бүген утыз яшь.

Рәфкать, балаларча җиңеллек белән йөгереп китеп, калку урынга килеп басты, авызын зур ачып иртәнге саф һаваны сулап торды. Аңа утыз яшь! Юк, утыз ел гомер узганга һич тә әле ышанасы килми. Ул әле үзен һаман да япь-яшь малай дип хис итә. Менә хәзер ул туфлиләрен, оекларын салып ыргытыр да, шушы чирәм өстеннән ялан аяк йөгереп китәр иде. Күпме йөгерә алыр иде икән? Әнә тегендәге Камы-Исмәгыйль авылы янындагы тауларга кадәр барып җитә алыр идеме икән? Юк, әнә теге басудагы камыл шунда ук аякларын тырный башлар, табаннарына корыган үлән сабаклары кадалыр...

Әйе, аңа утыз яшь. Хәзер инде аның берсе өч, икенчесе биш яшьлек ике кызы бар. Ул эшкә киткәндә, алар икесе дә, ауный-тәгәри, рәхәт йокыда калдылар. Туган көне белән котларга дип кичкә хәтле көтәрләр инде әтиләрен... Әниләре хәзер бәйрәм табынына тегене-моны алу өчен кибеткә чыгарга әзерләнәдер...

Эшне мөмкин кадәр ашыктырырга кирәк булыр... Нигә соң әле нефтьчеләр һаман юк?

Тәмле уйларыннан арынып, Максутов инде хәзер борчылып карана башлады. Юллар буш, вахта машиналары күренми иде әле. Ә кырда, кая гына күз ташлама, скважиналар, факеллар, скважиналар, факеллар... Бу тирәләрдә инде ун-унбиш елдан бирле нефть чыга, шул дәвердән бирле скважиналарда газ яна. Димәк, тәүлек саен меңләгән метрлар ефәк, йөзләгән тонна каучук, пластмасса, тагын әллә нинди кыйммәтле байлыклар җилгә оча. Ни өчен без шулай көч, тир белән табылган табигый хәзинәне әрәм-шәрәм итәбез? Ни өчен шушы кадәр байлыкны файдаланырга кулыбыздан килми? Әнә ерак та түгел, Миңлебай газ-бензин заводы күренә. Скважиналардагы бөтен газны суырып, эшкәртеп торасы урында, аның ишек алдында ук җәһәннәм төсле факел яна. Кабул итеп, эшкәртеп өлгерә алмаган чимал. Татарстанда ул бердәнбер завод, мондагы газның уннан бер өлешен алырга да көче җитми.

Кырларда үкереп янган газ утларын күргән саен, Максутовның эче әрни. Бер аның гынамы! Хәтта тәҗрибә алырга чит илдән килгән дусларыбыз да аны күреп борчылалар, моның өчен сезне балаларыгыз гафу итмәс, диләр.

Нәрсә дип әйтергә белми көрсенәсең генә. Бораулау, нефть чыгару темплары промышленность предприятиеләре салу темпларын узып китте, диләр. Мондый җавап бит бары үз-үзеңне тынычландыру өчен генә. Ә ни өчен промышленностьның бер өлкәсен уздырып җибәрергә дә, икенчесен артта калдырырга?

Монда инде галимнәр түгел, төзүчеләр һәм нефтьчеләр үзләре гаепле. Галимнәр газны саклап калуның күп төрле юлларын күрсәтteләр. Газны теләсә нинди җир асты куышына да, янадан нефть катламына да кудырырга була. Ниһаять, аны, нефть белән бергә, труба аша ерактагы берәр заводка озатырга да мөмкин. Моннан берничә ел элек үк, Максутов газ белән нефтьнең бер трубадан хәрәкәт итә алуын фәнни һәм тәҗрибә юлы белән исбат иткән иде. Ләкин әле һаман бу ысул практикада ныклы урын тапканы юк.

Институтта, үз бүлмәсендә фәнни эшләр белән шөгыльләнеп утырганда, Рәфкать Әхметович болар турында ничектер онытып тора. Алда төрле сызымнар, проектлар, эскизлар, ә күңел мөнә-менә туам диган яңалык белән тулган була. Хыяллар, канатланып, бер урыннан икенчесенә оча. Күз алдында булачак яңалыгыңның күләгәсе уйный башлый. Ул әкренләп укмаша, төсен, формасын ала. Син инде аны я берәр могҗизалы машина, я бер хикмәтле прибор, я әллә нинди агрегат итеп күрә башлыйсың. Куллар үзләреннән-үзләре карандашка үреләә... Карандаш алдындагы кәгазь битен чуарларга тотына... Менә шул көннән инде тынычлыгыңны җуясың. Йокы кача.

Күп айлар үтә. Ниһаять, борчулы, мәшәкатьле көннәрнең җимеше әзер. Ачышларың өчен сиңа югарыдан авторлык таныклыгы җибәрәләр. Баш ватып утырганың өчен әҗерен дә аласың. Дусларың синең кулыңны кыса, коллегаларың уңышлар теләп котлый.

Шунысы аяныч, бу, син уйлаганча, җимеш түгел икән әле, ә һаман чәчкә генә. Сыналган, эшкә яраклы дип табылган, хәтта макталган нәрсәң производствога житкәч, үзенә юл яра алмый. Уйлап табучы, галим кеше үзенең иҗат җимешен татыйсы килеп идарәләрнең, промыселларның, контораларның ишек юлын таптый башлый. Һәркайда ачык йөз белән каршы алалар, авторның яңалыгы тиздән, якын көннәрдә эшкә ашырылачагына ышандырып, кул кысып, озатып калалар. Айлар бер-бер артлы үтә тора. Автор, ниһаять, бу эштән суына, кул селти. Аның күңелен икенче бер нәрсә тырный башлый һәм ул кабат үзенең өстәленә кила, карандашына үреләә...

Вахитовның да, Кострюковның да, Максутовның үзенең дә нефть өлкәсенә керткән байтак хезмәте, әле бүген дә урын таба алмыйча, һавада асылынып тора.

Кырык эшен калдырып, Максутовның бирегә, скважинага килү сәбәбе дә әнә шундый борчулардан иде. Нефтьчеләрнең эшен күзәтергә, кирәк икән чыбыркылап та торырга исәбе. Ә бу галимнәр эшеме?..

Скважинага нефтьчеләр килде. Эшкә зур дәрт белән тотындылар алар. Дөньяда беренче мәртәбә җир тирәнлегенә пыяла эчле трубалар төшә башлагач, Максутов инде бу яналыкның барып чыгасына чын-чынлап ышанды. «Димәк, бүген туган көн итеп, яңа скважина хөрмәтенә дә бокал күтәрергә мөмкин», — диде ул, әченнән генә сөенеп. — Ике туган көн бергә!».

## «БАЛЫК БИРСӘҢ БӘЙЛӘП БИР...» ИНЖЕНЕР ГУБАРЕВ МИЧЕ. ТАГЫН СӘФӘРГӘ.

1711 нче скважинаның даны тирә-якка бик тиз таралды. Скважина утырган Камы-Исмәгыйль авылы кырына икенче көнне үк, төркем-төркем булып, газета хәбәрчеләре ябырылды, промысел, берләшмә, совнархоз башлыклары килде, шәһәр һәм район хуҗалары җыелды. Яңа скважина турында газеталар, радиолар шауладылар, журналларда яздылар. Әле җентекләп сынау үтәргә дә өлгермәгән трубаларның хәле, торышы, ничек ясалуы турында сорап институтка хатлар ява башлады. Кайсылары инде үзләренә яңа трубаларның үрнәген җибәрүне дә үтенделәр.

Моны күреп, нишетеп тору галимнәргә дә күңелле иде. Менә инде ничәнче атна тоташтан скважина кешесез-нисез, парафин кыргыч автоматтан башка эшли. Операторлар аның янына әллә нигә бер генә, мондый җиңел хезмәткә күнеп бетмәгәнгә, галимнәргә ышанмаганнан гына килеп карыйлар.

— Бу әле эшнең башы гына, — диде Еронин, үзе янына бүлмәгә җыелган институт сотрудникларына. — Безгә хәзер трубаларны кимендә алтышар метрлы итеп эшләү ягын карарга кирәк.

— Нинди карау инде тагын? — дип, ризасызланып кашларын җыерды Максутов. — Ясадык, күрсәттек...

— «Балык бирсәң бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир», — дигәннәрме әле? Менә шулай. Нефтьчеләрнең берәр метрлы труба белән мәшәкатьләнәселәре килми.

Алты метрлы труба... Бу инде Максутовка гына түгел, Кострюковка да чамасызрак кебек тоелды. Кыска трубалар сынмый да, бөгелми дә... Ә озынга китсә?.. Белмим, чыдамаслар, пыяласы чатнап, коелып бетәр...

— Ә озын мичләр каян табабыз? — дип, кинәт кенә сорап, барысын да аптырашка калдырды Кострюков. — Андый мичләрнең әле промышленностьта гомумән булганы юк.

Вахитов йөренергә тотынды, шып туктады да башын өскә күтәрде.

— Ә утка чыдам кирпечләрдән ясасак? Газ миче!

— Дөрес! — дип кычкырды Губарев. — Үзем чыгарам мичне!

— Булдыра аласыңмы?

Һәр эшне булдыра алуына масаеп киткән Губарев нык торды:

— Нәрсәсе бар аның? Кирпечне аласың да тезәсең!

— Әйдә алайса!

Промышленность сынаулары өчен бинаны нефтьчеләр Лениногорск шәһәрендәге бер иске мастерскойдан бирделәр. Тар иде ул, тәбәнәк, кысрык иде, шулай да галимнәр өчен лаборатория, нефтьчеләр өчен цех булырга ярап тора иде. Әгәр эшләр уңайга китсә, Лениногорск нефтьчеләре моннан тәүлек саен 120 метр труба алачаклар.

Губарев алъяпкыч киеп алган, терсәгеннән балчыкка батып мич чыгара. Балчык аның колакларына чәчрәгән, борын очына ябышкан. Аның як-ягында Максутов белән Кострюков. Бер читтә Вахитов чүгәләгән, күзлек астыннан гына, песи кебек, Губаревның эшен күзәтә.

— Син чын мичче икән ләбаса! — дип, Губаревның салпы ягына салам кыстырып куя ул.

— Как же! — Яков Федорович бер генә сүз әйтә дә калагы белән балчык измәсен алып кирпечкә чәпи. Максутов белән Кострюков артка чигенәләр.

— Начар кәсеп түгел, — ди Кострюков, өстенә чәчрәгән балчыкны кага-кага.

— Аның урынында булсам, мин институтта трубалар белән интегеп тә йөрмәс идем, — дип төрттерә Максутов.

Ниһаять, мич салынып та бетте. Аңа монтажчылар газ трубасы керттеләр. Губа-

рев мичкэ ут ягып җибәрде. Газ, тәмуг утыдай, дөрләп яна башлады. Мич өстеннән, кирпеч ярыкларыннан төтен катыш газ бәреп чыкты.

— Зинһар, сүндерегез! — дип, бер почмакта төтенгә тончыккан Вахитов кычкыра. Максутов белән Кострюков, яшьләренә тыгылып, ишек янында күзләрен уалар...

Губарев, нишләргә белми мич тирәли әйләнеп йөри, кулындагы калагы белән төтен чыккан бер җиргә измә алып чәпи.

— Ничек болай булды соң әле бу? Нәрсә булды бу мичкә? — дип сөйләнә.

— Итекче пешекче булырга маташкач, шулай инде ул, — ди Кострюков, күзләрен сөртеп. — Ташла, әйткәч, ташла!

Губарев ничек кенә тырышмасын, газ мичендә эшләргә насыйп булмады. Бу явыз мич турында ишетеп, икенче көнне үк газчылар килеп җитте. Мичне яраксызга чыгардылар. Ул да булмады, янгын инспекторлары күренде. Акт төзеделәр, мичкә пломба салып киттеләр. Алар артыннан бинага санитария-гигиена врачлары керде. Кая вентиляция, имеш, кая санитария кагыйдәләре. Чак кына штраф салмадылар. «Гортехнадзор» дигән усал бер оешманың вәкилләре дә булды. Тагын сорау: «Кем рөхсәте белән мич салдыгыз да, кайда проектыгыз, кем раслаган?» Тагын акт. Мең бәла белән котылдылар галимнәр.

«Губарев мичe» үзен акламагач:

— Миңа, ахры, Новосибирскига очарга туры килер, — диде Максутов. — Электр мичләренең зурысын, бәлки, шуннан табып булыр...

Бөгелмә — Казан — Новосибирск маршруты белән Максутов тагын сәфәргә чыгып китте.

## АЛАР ХӘЗЕР КУБӘҮ. БӘХЕТСЕЗЛЕК БӘХЕТ КИТЕРДЕ.

Кысрык һәм караңгы сарайның эче гөр килеп тора. Мотор тавышы, металл чыңы, кешеләрнең кычкырып сөйләшүләре — барысы бергә буталган. Максутов алып кайткан яңа мичләрне сыныйлар.

Бирегә һәр көн диярлек куңып-төнеп ята торган Губарев, Кострюков, Максутов өстенә, эшне карау өчен Бөгелмәдән Ерохин үзе дә, аның урынбасары Вахитов та килгән. Галимнәр семьясына тагын өч студент килеп кушылды: Җәләев, Ахунов, Фунин. Аларны инде студент дип әйтүе дә кыен — өчесе дә бүген-иртәгә читтән торып нефть институтын тәмамлыйлар. Хәзер фәнни-тикшеренү институтында инженерлар, техниклар булып исәпләнәләр. Алар трубаларны пыялаландыруда галимнәргә ярдәм итәчәкләр. «Тар җиргә тана башы», дигәндәй, яңа ысулны өйрәнергә җибәрелгән эшчеләр дә шушы бинада практика үтәләр. Лаборатория эчендә борылыр урын да юк.

Бу сарайны нефтьчеләр цех дип йөртсәләр, галимнәр өчен әлегә ул лаборатория. Чөнки монда куелган мичләрне, механизмнарны камилләштерү, трубаларны сынау дәвам итә.

Лаборатория эче тулы кеше булса да, берәү дә артык түгел. Һәркем үзенә эш тапкан, һәркем нәрсә белән булса да мәшгуль. Кострюков белән Губарев бер почмакта тимер пычкысы белән пыялаланган трубаларны бөҗраларга тураклыйлар — төрле-төрле тәҗрибәләр ясап, бичара трубаларның «җанын алалар».

Максутов, мактау сүзе көткәндәй, вакыт-вакыт директорга борылып карый, ләкин Василий Алексеевич, ни өчендер, дәшми, кызган трубаларга карап утыра бирә. Нәрсәдән риза түгел соң ул? Скважинага төшерелгән трубалар үзләрен аклыйлар: менә өч ай инде берниндн парафин утырмый. Өч метрлы трубалар урынына алты метрлы итеп чыгара башладылар. Начар түгел. Ә бит зур мичләр табу, аларны көйләү бик ансат булмады. Максутов күпме җәфалар чигеп Новосибирскига барды, җиһазлар институтында булды, андагы мичләрне өйрәнде. Аннан Бийскига, электр мичләре ясый торган заводка китте, мең бәлалар белән мичләр табып кайтты. Корыч чыныктыру өчен ясалган махсус мичләрне җайлау, урнаштыру уен эш түгел иде. Аларны үзгәртә-үзгәртә генә дә биш-алты вариантка җиттеләр. Нигә канәгать түгел ул, Василий Алексеевич?

— Беләсеңме, Рәфкать Әхметович, — диде ул, ниһаять, Максутовка карамыйча гына. — Шушы цех үрнәгендә Лениногорскида зур завод салыначак. Нефтьчеләр трубаларны бөтен көенә пыялаландырып бирүне сорыйлар...

— Унике метр озынлыгындамы? — дип гаҗәпләнде Максутов, урыныннан торып. — Мөмкин булмаган нәрсә! Фантазия!

— Минемчә, труба озынлыгындагы мичләр булдырсак, мөмкин.

Максутов андый озынлыктагы мичләрне эзләп карады инде. Юк, андый мичләр ясалмый.

— Мөмкин, — диде Максутов, — тик, кайсы завод безнең өчен генә андый мичләр җитештерүне өстенә алыр икән?

Сөйләшеп торганда очраклы хәл килеп чыкмаса, белмим, трубаларны кисмичә, бөтен көенә пыялаландыру кайчанга кадәр фантазия дип исәпләнгән булыр иде икән? Кинәт трубаның бер башы суына башлады. Карасалар, мичнең түрендә спираль янып чыккан.

Хәл бик җитди иде. Эш тукталу куркынычы туды. Галимнәр барысы да мич янына җыелдылар.

— Кайдан табарга була мондый спиральләрне?

— Бары тик үзенең заводыннан гына, — диде Максутов, кәефе төшеп. Юк кына нәрсә өчен яңадан да аның ерак җирләргә, Бийскига кадәр китәсе килми иде.

Барысының да күзләре — һаман мичтә, исән калган спиральдә. Ниндидер өмет чаткысы чәчеп, яна әле ул, мичкә дә, күңелгә дә җылылык биреп тора. Галимнәр, сүзсез генә, бер трубаны тәгәрәтеп китерәләр, эченә пыяла көпшәне тыгалар, эш юктан, аптыраганнан гына аны мичкә этеп кертәләр. Трубаның бер башы кыза, аны әкренләп алга күчерә баралар. Менә трубаның бар җире дә ут аша узып бетте. Алдылар, суыттылар. Максутов теләмичә генә, труба эченә күз салды.

— Булган, җәмәгать!

Моңа башта берәү дә ышанмый торды. Шулай да Вахитов күзен труба башына куймый түзә алмады.

— Чынлап та булган! — дип гаҗәпләнде ул. — Кара инде, бәхетсезлек бәхет китерде!

Труба эченә берәм-берәм барысы да карап алгач, иркенләп сулап куйдылар.

— Тулысы белән мич эченә тыгуның кирәге юк икән моны! Кискәләмичә, бөтен көенә дә шушы мичтә пыялаландырырга мөмкин икән!

## НЕФТЬЧЕЛӘР ТРУБА ДАУЛЫЙ. БӨГЕЛМӘДӘН ЧЫККАН ЧАТКЫЛАР.

Бүгенге җыелыш нефтьчеләрнең ел йомгакларына багышланса да, үзләренең чакырылуыннан чыгып, Вахитов галимнәргә карата да сүз буласын сизенгән иде. Әнә, чишенергә дә өлгермәгән Максутов белән Кострюковны нефтьчеләр чолгап та алганнар иде. Максутов, аларның әле берсенә, әле икенчесенә таба борылып, кулларын селти-селти нәрсәдер исбат итә.

Галим кеше, әнә шулай, гомер буе исбат итә инде ул. Эше барып чыкса да, барып чыкмаса да, җилкәсеннән йөк төшми.

«Бик үк кыерсытып куймасыннар тагын үзләрен», — дигән сыман, Вахитов алар янына килде.

— Өченче ел инде янына барганыбыз юк! Дөньяның рәхәте! — дип, берәү кычкырып-кычкырып Максутовка скважинасын мактый иде. Үзе шунда ук аны тиргәргә дә кереште:

— Нигә ул трубаларны граммлап кына өләшәсез? Күбрәк итеп чыгарырга кулыгыздан килмимени? Дөньяда пыяла беткәнме әллә?

Вахитов аны таныды — бу кеше иң беренче пыяла төшерелгән 1711 нче скважинаның мастеры Иван Ермолов иде — «мең ямаулы» скважина хуҗасы.

Тагын кемнәрдер ул эшкә бернинди катнашы булмаган Максутовтан ялына-ялына трубалар сорарга керештеләр:

— Миңа бер генә скважиналык булса да... Парафин белән интегәбез... җәфа чигәбез...

Кострюков белән Максутов икәүләп аңлатып карыйлар: цех кечкенә, мөмкинлек шундый... Ул көнгә бер генә скважинаны тәэмин итә алабыз... Әнә, югарыдан сорагыз, завод салуны ашыктырсыннар... Әмма нефтьчеләрнең үз сүзләре сүз.

Вахитов 1960 елның караңгы көзендә булган киңәшмәне исенә төшерде. Әле пыялалы труба түгел, аның пыяласы да табылмаган вакытта институтта туган яңа идеяне сөйләр өчен трибунага менгән иде бит ул. Ничек батырчылыгы житкәндер. Бер уйлаганда, тумаган тайның билен сындыру кебек булды инде. Көлделәр, шаулаштылар, тузга язмаган сүз, хыял дип атадылар...

Бүген фәнни-тикшеренү институтының бу продукциясен бөтен нефтьчеләр хупладылар. Пыялаландырылган трубалар хәзер лаборатория рамкаларыннан чыгып, ил буенча сәяхәт итә. Татарстан промыселларында беренче мәртәбә дөнья күргән трубалар, бүгенге көндә көньякка таба атлап, Оренбург далаларына, Мангышлак ярым атавына, карт Бакуга, илебезнең иң жылы урыны булган Ашхабадка кадәр барып життеләр. Әнә, стенага аның схемасын да элеп куйганнар. Бу трубалар Советлар Союзының барлык почмакларына таралган. Төньякка таба бер чаткы китеп, Пермь шәһәренә, көнчыгышта — Уфага, Түмәнгә барып тоташа. Бер чаткы Волга буенча Куйбышевка, Саратовка, Волгоградка юнәлә. Бөгелмәдән чыккан укларның очлары башкаладагы Халык казанышлары күргәзмәсенә, Украинага, Балтик диңгезе буйларына киткән — алар үзләрендә трубаларны пыялаландыру буенча яңа цехлар, заводлар сала башлаганнар. Безнең трубалар, хәтта илебез чикләрен үтеп чыгып, Чехословакиягә, Польшага барып кергәннәр. Дуслык килешүе буенча, безнең проект белән, аларда да зур-зур заводлар төзелә икән.

Гомумән, галимнәргә карата нефтьчеләрнең хәзер йөзләре ачык, ихтирамнары зур.

Звонок булып, залга кереп утыргач та, Вахитов моны бик яхшы тойды, трибунадан үзләренә әйтелгән жылы сүзләрдән соң, горурланып, әле янындагы Максутовка, әле Кострюков белән Губаревка караштыргалап алды. Әйе, пыялаландырган трубалар Татарстан промыселларында гына да бер ел эчендә 4 миллион сумлык файда биргәннәр, 4 миллион киловатт-сәгать электр энергиясенә экономия ясаганнар. Шуның шаһите булып хәзер «пыялага гашыйк» галимнәрнең барысының да күкрәкләрендә медальләр ялтырый. Бөтенсоюз халык хужалыгы казанышлары күргәзмәсе трубалар пыялаландырудагы уңышлары өчен Бөгелмә нефть фәнни-тикшеренү институтына беренче дәрәжәдәге диплом, Еронин белән Максутовны алтын медаль, Кострюков белән Губаревны көмеш, ә Вахитов белән Ахуновны бронза медальләр белән бүләкләгән иде. Бүген алар беренче тапкыр үзләренең бу кадерле бүләкләрен тагып килгәннәр.

Вахитов, җае чыкса, бу җыелышта нефть галимнәренең эшләре, уңышлары турындарак сөйләргә дип килгән иде, ләкин ул бу уйларыннан бик тиз кайтты. Мактанудан файда юк. Әнә, чыгыш ясаучы нефтьчеләр труба таләп итәләр. Лениногорскида салына башлаган трубалар пыялаландыру заводы — тәүлек саен бер скважинаны тәэмин итә алырлык предприятие әле һаман сафка керми. Нефтьчеләр план буенча 1966 елда ук инде 60.000 метр пыялаландырган труба алырга тиеш булганнар икән, яртысы да үтәлмәгән. Татарстан промыселларында бүгеннән үк меңләгән скважиналарны пыялаландырган трубалар белән алыштырырга кирәк. Кул көче белән парафиннан арындырыла торган скважиналар саны гына да дүрт йөздән узып китә. Мондый вакытта уңышларга бирелеп, тынычланып утырырга мөмкинме?

Сүз алып, әнә шундый фикерләр белән трибунага күтәрелде Вахитов. Ә нефтьчеләр аны алкышлап каршы алдылар...

—●●—

*Газиз Нәбиуллин*

# УРАК ӨСТЕ

## *Сценарий*[1]

Пәрдә ачыла. Анда хор тезелгән була. Сәхнә алдына беренче алып баручы чыга.

I алып баручы.

**Җәйләр буе кырда гизгән,**
**Иген дулкынында йөзгән,**
**Эшләр кызгач ялдан бизгән,**
**Икмәкнең чын тәмен сизгән,**
**Әй, мактаулы игенчеләр —**
**Илгә муллык бирүчеләр,**

Хор.

**Сәлам сезгә, кайнар сәлам!**

II алып баручы *(сәхнә алдына чыга).*

**Җәйләүләрдә таң аттырган,**
**Тырышлыкны гел арттырган,**
**Сөт күлләрен ташыттырган,**
**Эштә үргә ашып торган**
**Терлекчеләр, көтүчеләр —**
**Илгә байлык илтүчеләр,**

Хор.

**Сәлам сезгә, кайнар сәлам!**

Галәви гармун уйнап, үзе кушылып җырлап, сәхнә алдына килә.

**Юллар төште бу якка,**
**Килеп чыктык кунакка,**
**Көндез йөрдек кырларда,**
**Хәзер инде җырларга.**
**Кемнәр хезмәт батыры,**
**Ана җырның матуры!**

Хор.

**Кемнәр хезмәт батыры,**
**Ана җырның матуры!**

Галәви.

**Сезнең колхоз кырларында**
**Шифалы җилләр искән.**

Хор.

**Андый җилләр күп исмәгән,**
**Җиргә ихтирам үскән.**

Сабира.

**Күз төшермә күк йөзенә,**
**Анда бит үсми икмәк.**
**Җиргә кара, җирне ярат,**
**Тик шунда бәтен хикмәт.**

---

[1] Бу сценарий урак өстендә колхозларда, совхозларда чыгыш ясаучы агитбригадаларга файдалану өчен дип язылды. Анда күрсәтелгән исемнәр шартлы рәвештә алынды. Аларны барган урыннарда үзгәртергә кирәк булачак. Сценарийдагы материалларның кайберләре файдаланылмый калырга яки үзгәртелергә дә мөмкин.

В ә к и л.

Жирен сине туендыра,
Жылыта, киендерә.
Бар байлыгы синен өчен —
Бел аның көен генә.

Х ә б и р ә.

Туфрагы гел дымлы аның,
Күп тамган маңгай тирем.
Ак күмәч белән сыйлыйсың,
Кадерле кара җирем.

Г а й н а н.

Кырдан китсәм, туган җирем
Моңаеп кала кебек,
Сөймәсәм аны, йөрермен
Бер үги бала кебек.

I а л ы п б а р у ч ы.

Комбайнчы Фәсхетдин
— Уңган быел ашлык, — ди.
Иртән эшкә ашыгып килә,
Кич кайтырга ашыкмый.

II а л ы п б а р у ч ы.

Очраттык без Фәсхетдинне
Кайткан чакта өенә.
— Өздерегез әле, — диде,
«Җәй айлары» көенә.
Үтибез аның заказын,
Әзерләп торсын тагын.

Җырны хор башкара.

I а л ы п б а р у ч ы.

Агроном иптәш Бари,
Кырда күп йөреп арый.
Ардымы, алтын бөртекне
Учына салып карый.

II а л ы п б а р у ч ы.

Алтын бөртекне иснәсә,
Арганы шунда бетәр.
Безнең җырны тыңлау белән
Яшь егет булып китәр.

Ана багышлап бер яки берничә җыр башкарыла.

I а л ы п б а р у ч ы.

Бригадир дус Зөбәйдә
Йокы күрми бу айда.
Ничек йоклап ятсын, ди,
Йокламый бит бодай да.

Б р и г а д и р *(йөгереп керә)*. Мин бригадир. Миңа да бер-ике җыр багышлагыз әле. Җырны бик яратам мин. Үзем дә җырлыйм. Әллә башта үзем җырлыйммы?

Г а л ә в и. Юк, без сине бистергә исәплибез.

Б р и г а д и р. Шул гына калган иде. Әле правлениедә биетеп чыгарганнары да онытылмый.

Г а л ә в и. Ни өчен биетәләр?

Б р и г а д и р. Әй, юк өчен лә. Бригадаң уракка чыкмаган диләр.

Г а л ә в и. Ни өчен чыкмыйсың соң?

Б р и г а д и р. Иртәгә чыгабыз. Районнан вәкил килеп әйтте инде.

Г а л ә в и. Комбайннарыгыз, ургычларыгыз әзерме соң?

Б р и г а д и р. Районнан килгән вәкил карады инде, әзер булырга охшый, диде.

Г а л ә в и. Тик үзең генә әзергә охшамыйсың.

Б р и г а д и р. Районнан килгән вәкил хәзер канцеляриягә җыелабыз диде, шунда әйтер инде *(ашыгып чыгып китә)*.

Концерт дәвам итә.

Урып-җыю алдынгыларының исемнәре, эш күрсәткечләре әйтелә, аларга багышлап яки алар соравы буенча җыр, бию, нәфис сүз, гармун. Тышта машина туктаган тавыш.

Галәви. Иптәшләр, гафу итегез, безнең «прожектор»ыбыз килеп житте. Хәзер аны сәхнә артына алып кирәк. Хорда катнашучыларны хәзер йөк күтәрүчеләр итеп файдаланырга рөхсәт итегез. Барыгыз, кызлар, рәхим итегез. Бергә-бергә күтәреп кертегез, ә сез, егетләр, «прожектор»га урын әзерләгез, астына йомшак келәм җәегез. Тиз-тиз йөрегез, сак була күрегез, «прожектор»ыбыз ватылмасын, эшкә тотынгач,*(комбайнчы фамилиясе әйтелә)* комбайны кебек, берничә минуттан туктап калмасын. Ә үзем ник монда калдым дисезме, шуны белмисезме? Мин бит начальник, «прожектор» тотып кулны буясам — начар бит, авторитетым очар бит. Минем кул астында 2 алып баручы, ничәмә артист һәм артистка бар. Әһә, «прожектор» керде, иптәшләр! Үзе керде, фермаларда сез ясарга уйлаган асылма юллардан үзе килеп керде. Аның нурлары якты, балкыта ул тирә-якны, гаеп-кыек эшләр юкмы? Яктыртыйк әле утны! Ә хәзер ул сезгә амбар тирәсен күрсәтәчәк.

Сәхнә артыннан якты сузыла, хор ике якка аерылып баса да арттагы зәңгәр пәрдә икенче якка тартыла. Бригадир, шофер, кладовщик бер капчык янында хәйран калып басып торалар. Мөмкин булса, прожектор белән һәрберенең йөзен аерым-аерым яктыртырга кирәк.

Бригадир. Игенче намусы бар диген инде шуларда. Бер капчыкка калгач, ташла да кит, имеш.

Шофер. Монысы үзегезгә, диде бит шалкан Галләме. Ягъни мәсәлән, мин — шофер Әпсәләм, капчык күтәрергә тиеш булам. 6 потлы капчык кына түгел, 90 потлы машина минем җилкәдә.

Кладовщик. Бәлки ул капчыкның бер башыннан мин тотсын дип әйткәндер әле. Кладовщик Рәхмәт Каләмкашовның бүтән эше юк шул. 100 мең потлы амбарга баш булып та баш черен беткән.

Бригадир. Әллә бригадир Җиһангир үзе күтәрсен дию булдымы. Мин күтәрергә түгел, төшерергә яратам.

Шофер. Егетләр, саласы иде бит.

Кладовщик. Саласы иде шул.

Бригадир. Миндә бер сум бар. Салабыз дисәк, күмәкләшик.

Шофер. Капчыкны саласы бар дим мин сиңа. Машинага саласы!

Кладовщик. Мин дә шулай дим бит.

Бригадир. Һәй аны әйтәсез икән. Салыгыз, кулыгызны бәйләп куйган кеше юк ич.

Кладовщик. Сабан туе батыры бригадир Җиһангирга ни булган, ягъни мәсәлән, шофер Әпсәләм белән икегез ике башыннан...

Шофер. Мин ул капчыктан башка да элдертә алам. Әнә икегез күтәреп салсагыз саласыз. Машинамны простой тота алмыйм. Минутым да исәп.

Бригадир. Шундый чакта уч иткән күк бер адәм заты күренми бит. Ну бу шалкан Галләмен!

Кладовщик. Әнә, кемнәр анда?

Бригадир. Әй, әй, Гариф бабай, Гариф бабай!

Кладовщик. Колак аппаратын киеп чыкмаган. Ишетми инде ул. Сәрби әби, Сәрби әби!

Бригадир. Сәрби әби, килегез әле.

Карт белән карчык керәләр.

Карт. Саумы сез оланнар, күрше-коланнар? Үтәләме соң планнар? Бик какшамаганмы бу амбар? Үтми микән җилләр-бураннар?

Бригадир. Амбары ярый әлегә, менә эш тоткарланып тора, Гариф бабай. Бер капчык аркасында.

Карт. Бер карчык аркасында дисеңме?

Бригадир. Капчык дим!

Карт. Ә аны әйтәсең икән. Бик дөрес әйтәсең, энем. Үзем дә уйла-

ган идем аны. Менә карчык белән шуны сөйләшеп килдек әле. Булышырга дип исәпләп килдек.

Кладовщик. Ишетми дип тор син аны.

Бригадир. Болай булса эш пешә. Киреләнерләр дип курыккан идем.

Карт. Ул бакча турында дөрес әйтәсең, энекәш. Бу заманда бакчасыз булмый. Хәзердән хәстәрен күрергә, алмагачын, чиясен дигәндәй, көздән утыртып калдырырга кирәк.

Бригадир. Безне төп башына утыртып калдырырга чамалый бу.

Шофер. Аның белән сөйләшеп эш чыкмас. Карчыгына әйт.

Бригадир. Сәрби әби, сез инде колхозга зур ярдәм иткән кешеләр...

Сәрби. Ярдәм иткән дисеңме? Һи, җан көеге, әйттең сүз! Без аны үзебез төзедек. Әнә бабагыз председатель иде. Болай җыелып бака күле ясаучыларны биетә торган иде ул. Мондый капчыкларны ул йон урынына очыртты. *(Теге капчыкка күрсәтә.)* Хәзер генә...

Карт. Мин аларны хәзер дә йон йомгагы итеп очыртам әле. Бу җәфалар шул төенчекне кузгатырга хәлсезләнеп утыралардыр, мөгаен. Без яшь чакта аны менә шулай гына селтәп ата идек. *(Капчыкны шактый җиңел күтәреп, машинага илтә.)* Хәзер генә буыннар какшабрак китте.

Шофер *(оялып)*. Гариф бабай, үзем, үзем...

Карт. Юлга аркылы торма. Путевкаң кесәңдәме, юлыңда бул. *(Шофер бик уңайсызланып китеп бара, машина кузгалган тавыш.)*

Кладовщик. Күрдеңме, бригадир!

Бригадир. Телеңне теш артына яшер.

Карт. Ә бакча турында уйла син, бригадир, уйла!

Бригадир. Киңәшеңә рәхмәт, Гариф бабай. Фикер алышырбыз.

Карт. Күпер дисеңме, энем! Ватык шул, ватык. Үземнең дә җаным әрни. Әллә каян әйләнеп машина гомере чери бит. Гомер черү генә түгел, ашлык черергә мөмкин. Ашлык, ашлык! Ярар, тагын бер тапкыр чыгып карармын әле. Көчтән килердәй булса, рәтләрмен мин аны. Карчык та булышыр.

Бригадир. Рәхмәт Гариф бабай, рәхмәт.

Карт. Кладовщик Рәхмәтне әйтәсезме? Шулай шул. Ялкауланып киткәнгә охшый.

Бригадир. Үзеңә рәхмәт дим, үзеңә. Сәрби әбигә дә.

Карт. Ярый алай булгач. Мәгънәсен беләсең икән әле. Әйдә, карчык, комбайнчылар эшен карап кайтыйк. Анда да буксовать итүче тере капчыклар юкмы икән? *(Китәләр.)*

Бригадир. Әйдә, кузгал, кладовщик. Әпсәләм әйләнеп кайтканчы теге капчыкларны ташый торыйк! *(Китәләр. Зәңгәр пәрдә дә акрынлап ябыла.)*

Галәви. Ә хәзер шатлыклы җыр, күңелле музыка яңгырасын!

Җыр тәмамлангач.

Галәви. Гайнан энекәш, шушы кара тактаны гына куйыйкчы.

Гайнан. Әллә дәрес үткәрмәкче була инде.

Галәви. Үткәрәм шул. Арифметика дәресе. Мә, шушы акбурны тот әле. Хәзер өч урынлы бер сан яз.

Гайнан. Бүген теге чокырлы елгадан машинаны этеп чыгарганда болай да саннан яздым инде.

Галәви. Өч урынлы сан яз дим мин сиңа!

Гайнан. Алты урынлы диген. Кичә автобуста өч урынга алты кеше утырып килдек бит. Өч урынга билет сатты, алты урынга акча тартты. Бер кибеткә туктап, стакан ярым хәмер капты.

Галәви. Әй тартса сон, бүген бит үзе дә капты. Хәзер үз машинабыз бар. Яздынмы өч урынлы сан?

Гайнан. Яздым. 332.

Галәви. Шофер Галләмнең бер айда әрәм иткән ягулыгын язгансың син.

Гайнан. Булса булгандыр, аны уйлап тормадым.

Галәви. Хәзер шуны киредән әйләндереп яз. 233 булдымы?

Гайнан. 233 булды. Монысы безнең күрше шабашник Гарифның колхоз эшенә катнашмаган көннәре икән.

Галәви. Ә хәзер зур саннан кечкенә санны ал!

Гайнан. 332 дән 233 не алгач, каладыр, каладыр... 99. Йөзгә берәү тулмаган. Комбайнчы Моратханның иң югары норма үтәлеше. Ә иң түбәне күпме булганын беләсеңме? Мин беләм. Кичәге күрсәткече 59 процент.

Галәви. Алайса, зур саннан кечкенә санны ал.

Гайнан. Алдым. 40 кала.

Галәви. Монысы нәрсә?

Гайнан. Һе, 40 ны беләбез инде аны.

**Безнен күрше Моратхан,**
**Яше узган кырыктан.**
**Аерылмаган «кырык»тан.**
**Шушы «кырык» кырык тапкыр**
**Кесәсен дә кырыккан.**

**Милициягә юлыккан,**
**Кемдер чәчен кырыккан.**
**Челләдә дә бүрек салмый**
**Инде шушы хурлыктан.**

Галәви. Зирәк егет икәнсең. Арифметикадан «5» ле. Алга таба китәбез, концертны дәвам итәбез.

Программа нигезендә, җыр, бию, нәфис сүз, музыка коралларында уйнаулар бер-берсен алыштыра тора.

Галәви. Әй, егетләр, кызлар, «прожектор»га әйтегез, агроном кабинетын яктыртыгыз. Үзе килә алмый, эшләре бик тә тыгыз!

Зәңгәр пәрдә тартыла. Агроном өстәл янында. Яза, счет сала, тәмәке кабыза, сүнгәч тагын кабыза, бернечә тапкыр уфылдап куя, графинадан су эчә, сәгатенә карап ала, нигәдер ризасызлык белдереп башын чайкый. Тагын язарга утыра. Шул вакыт шофер керә. Шыпырт кына килеп агрономның күзләрен каплый. Агроном сискәнеп, куллары белән селтәнә.

Агроном. Я, шаярма инде, Нәҗия! Ни хакың бар агрономның күзен томаларга? Абау, кулларыңны тагын юмагансың. Механик кешегә гел бензин белән тынчып йөрергә димәгән. Ягулыкка экономия ясарга кирәк. Синең кулларыңа сыланып кына да елына 100 грамм бензин бетә торгандыр. *(Шофер агрономның күзләрен ныграк кыса.)* Нәҗия дим, ташла әле шул мәгънәсез шаяруларыңны. Бар белгәнең күз томалау.

Шофер *(тавышын үзгәртеп)*. Нишлисең, җан кисәгем? Әллә урак урасыңмы?

Агроном. Чү, ни булды сиңа, тамагың карлыккан? Нәҗия дим, я инде? *(Башын селкә, шофер кулларын җибәрә.)* Монысы нинди әкәмәт тагын? Кайда Нәҗия?

Шофер. Кош булып очты, җил булып исте. Әйдә, иптәш агроном, сезне алырга килдем.

Агроном. Иптәш шофер, обедка кайтырга иртәрәк әле. Борчылмагыз, мин җәяү дә кайтырмын.

Шофер. Юк, мин сезне басуга алып китәм. Таллы бригадасына

Агроном. Бүген беркая бармыйм. Бик зур эшкә кереп чумдым.

Шофер. Сез эшләгез, эшлә, иптәш агроном. Мин канцеляриягезне машинага тагып алып китәм. Шунда яза-яза барырсыз. Кузгалдыкмы?

Агроном. Алай гына ничек китим мин? Командировочное кәгазе дә яздырмаган. Күрше авылга барабыз бит. Командировочныйсыз булмый. Председатель белән бухгалтер килгәнен көтик инде.

Шофер. Алар икесе дә басуда. Председатель мине үзе җибәрде.

Агроном. Соң ул минем урып-җыю планы белән утырганны белми микәнни?

Шофер. Нинди план тагын? Урып-җыю планын күптән кабул иттек ич инде. Җыелышта үзең укыдың.

Агроном. Анысы колхоз буенча бит. Мин чистый агрономический план төзим. Полный расчет белән.

Шофер. Әле тиз бетәме соң?

Агроном. Минимум — унбиш көн.

Шофер. Соң, иптәш агроном, ничә көннән бирле инде урабыз бит.

Агроном. Әкият сатма. Минем план өлгермичә ашлык ничек өлгерсен.

Шофер. Өлгерә икән шул. Сезнең план өлгермәсә дә, үз вакыты житкәч иген өлгерә икән. Председатель әйтмәдемени?

Агроном. Планым өлгерсен дидем ич мин аңа. Ә ул көлде генә. Менә плансыз эшләп агротехниканы бозачаклар, уңышны коячаклар. Аннан мин җавап бирәсе.

Шофер. Сезнең план өлгергәнен көтсәк, ашлык коелмасмы?

Агроном. Ул план белән утыра-утыра үземнең чәчем коела башлады инде.

Шофер. Әйдәгез, бөтенләй пеләшләнеп беткәнче пеләшләнә башлаган басуларга юл тотыйк, иптәш агроном.

Агроном. Барып карыйк (*тора, кәгазьләрен җыя*). Ә командировочное кәгазен кайдан алабыз?

Зәңгәр пәрдә ябыла.

Галәви.

Алда — бушый барган кырлар,
Чагылып китә ак чыклар.
Иртәнге кояш нурында
Иркәләнә капчыклар.

Машиналар, машиналар,
Бер тоташ колонналар.
Елның шушы вакытында
Туктаусыз агылалар.

Шофер дус, син бу чорларда
Көнне төнгә ялгыйсың.
Эшең гөрләп бара икән,
Шушы гөрләү — ял! — дисең.

Чәчәк бәйләме сузсак та
Үрелеп алалмассың.
Җыр букеты бүләк итсәк,
Кабул итми калмассың.

Алдынгы берничә шоферның исеме әйтелә, алар соравы буенча күмәк яки ялгыз җыр.

Галәви. Җәмәгать, хәзер ут ягабыз.

Гайнан. Кайда?

Галәви. Шушында, сәхнә уртасында!

Гайнан. Янгын чыкса?

Галәви. Чыксын. Шуның өчен ягабыз да!

Гайнан. Пожарниклар минут эчендә килеп сүндереп китәчәкләр.

Галәви. Сүндерә алмаслар. Үзләренә ут капканын да сизми калырлар. Хәзер үк ут ягабыз, зарарлы күренешләрне салабыз да яндырабыз, көлләре күккә очсын. Кабыз, әйдә, чәнечкеле, үткен уклы җыр уты! *(Таягын күтәрә, сәхнәгә бер-бер артлы ал-кызылдан киенгән егетләр, кызлар керә.)*

Ут ягабыз, ут ягабыз,
Кирәкми коры утын.
Кимчелекләргә каршы без
Кабызабыз җыр утын.

Килеп житә пожарник,
— Каян чыккан пожар, — ди.
Пожарник та тәнкыйть утын
Сүндерәлмәс, пожалуй.

Тракторчы Иргалидә
Бетмәгән ди иркәлек.
Черем итеп бара икән
Кабинада тирбәлеп.

Гали уңган комбайнчы,
Урган чакта урыр нык.
Тик кистергән башаклары
Бер чүмәлә булырлык.

Комбайнчы булганнан соң,
Вәлинең эше башка.
Комбайнга утырып кына
Кайта көндезге ашка.

Рәхимҗан шәп кибетче,
Сәүдә итә кич-иртә.
— Ярты алсаң күп була, — ди,
«Йөз»не салып эчертә.

Урындагы фактлар буенча кимчелекләрне тәнкыйтьләп чыгарылган җырлар дәвам итә.

1 алып баручы. Яратам кырда кухняга
Бер тукталып китәргә.
Итле аштан, каймагыннан,
Пәрәмәчтән, коймагыннан,
Сарык, куян, кош итеннән,
Сумсасыннан, паштетыннан —
Аз-маз авыз итәргә!

Повар апа, тагын өстә,
Бигрәк тәмле пилмәнең.
Нигә инде шушы кырга
Әллә кайчан килмәдем?

Ашыңны бер кабу белән
Көч арта беләкләрдә.
Повар апа, килдек сине,
Җыр белән бүләкләргә.

Хор яки ялгыз җырчы берничә көй башкара. Сәхнә бушый. Бер яктан бригадир, икенче яктан ярдәмче килеп керә.

Ярдәмче. Иптәш бригадир, борчак уңышын хәбәр итәргә ашыктым. Хәзергә телдән генә әйтәм, язмача соңрак булыр. Кичә суктырган унбишенче участокта һәр гектардан уртача уңыш 20 центнер! Күп бит, иеме!

Бригадир. Тагын борчак сиптерәсеңме? Бик беләсең килсә, ун центнер андагы уңыш! Кичәге үлчәү шуны күрсәтә иде.

Ярдәмче. Ә бүгенге үлчәү, бик беләсең килсә, 20 центнерны күрсәтә. Ышанмасаң, комиссия җибәр, я үзең үлчәп кара!

Бригадир. Төнлә яңгыр яуганда өстенә япкан идегезме?

Ярдәмче. Гаеплемен, иптәш бригадир. Мин барып җиткәндә яңгыр туктаган иде инде.

Бригадир. Яңгырда борчак бүрткәнме соң?

Ярдәмче. Бүртмәгән кая, борчак чумары хәтле булганнар.

Бригадир. Әнә шул бүрткән борчакны бүрттереп йөргәнеңне төшендеңме инде?!

Алар китәләр. Алып баручылар аерым программада концертны дәвам итәләр. Тагын бригадир белән ярдәмче керәләр.

Ярдәмче. Иптәш бригадир, рапорт бирергә рөхсәт итегез.

Бригадир. Рөхсәт.

Ярдәмче. Сезнең карамакта бригада бүген бөртекле культуралар уруны тәмам итте. Бригадир ярдәмчесе Әхмәди Шәхмәдиев.

Бригадир. Күз буямагыз! Урылып бетмәгән биш гектар арпаны беркайда да куя алмассыз.

Ярдәмче. Бөртекле түгел ул, иптәш бригадир.

Бригадир. Арпа әле кичә генә бөртекле культура булып исәпләнә иде.

Ярдәмче. Кичә исәпләнгәндер дә, бүген... юк шул. Бөртекләре... окончательно... коелып беткән.

Бригадир. Чәч бөртекләрем дә коелып бетәр әле синең белән. Ындыр табагында охрана бармы?

Ярдәмче. Булмыйча. Хәлиулла бабайны икәү бергә илтеп куйдык бит.

Бригадир. Бар тикшереп кайт, йоклап ятмыймы?

Ярдәмче китә, зәңгәр пәрдә ачыла.

Каравылчы. Кем килә, әйтмәсәң — атам.

Ярдәмче. Мин, мин, бригадир ярдәмчесе. Ата күрмә, Хәлиулла абзый.

Каравылчы. Атмыйм ла. Нәрсә белән атыйм. Бодай тутырып кына атмасам шул.

Ярдәмче. Өстеңдә дә юка икән. Салкын түгелме?

Каравылчы. Өстә юка булса — ындыр калын. Төне салкын булса — көшеле җылы. Менеп яткач арканы пешерә.

Ярдәмче. Пешерә дисеңме? Каяле, кая? Кызганмыни соң бу?

Каравылчы. Кызган шул. Бик кызган. Кызганучы гына күренми.

Ярдәмче. Кызгану сиңа да хәрам түгел ич.

Каравылчы. Кызгану әхрән вазифасына керми.

Ярдәмче. Таратырга, болгатырга ярый инде сиңа да.

Каравылчы. Тарата торган гадәтем юк. Әхрән өчен гүпчи яраган эш түгел. Болгатырга дисең? Көшелләрне түгел, кешеләрне дә болгатканым юк. Мин — әхрән. Мин саклауны беләм.

Ярдәмче. Һич кичекмәстән бригадир иптәшкә язма хәбәр итәм.

Каравылчы. Минеме? Таратмый, болгатмый дипме?

Ярдәмче. Сине түгел лә! Бодай хакында. Таратучылар, болгатучылар табып җибәрсен. Аңарчы мин дә көшел ләүкәсенә менеп парланыйм әле.

Зәңгәр пәрдә ябыла.

Галәви.

**Мондыйларны узындыру**
**Ярамый конфет белән.**
**Парлап алу бик мәслихәт**
**Чын, кайнар тәнкыйть белән.**

Гайнан *(керә)*. Концертны берничә минутка туктатып торуыгызны үтенәм. *(Прожектор утлары больницаның кабул итү бүлмәсен яктырта.)* Кемдер авырып килгән. Бәлки аңа безнең дә ярдәм кирәктер. *(Зәңгәр пәрдә ачыла. Кабул итү бүлмәсе. Анда врач һәм тап-таза, яшь-яшь егет.)*

Егет. Доктор апа сез буласызмы?

Врач. Мин булам. Нәрсәдән зарланасыз?

Егет. Председательдән.

Врач. Больницага килергә машина бирмәдеме?

Егет. Кем машина сорасын аннан. Авыр эш кушып җәфалавы белән узәкка үтә. Әле менә кыр станындагы ашханәгә продукция ташырга куша.

Врач. Нинди чир белән интегәсез соң?

Егет. Менә хикмәт. Врач икәнсез, анысын сез әйтегез инде, хи-хи... Чиремне табыгыз да, больницага салыгыз.

Врач *(егеткә текәлеп карый, тегесе чигенеп куя).* Йөрәгегездә куркыныч бар.

Егет. Сез ни сөйлисез? Кайдан беләсез?

Врач. Күзләрегез әйтеп тора.

Егет. Менә хикмәт. Әле мин йөрәгем авырый дип уйламый идем.

Врач. Авырый икән шул. Хәер, аракы эчмәсәгез, тиз төзәлер.

Егет. Менә хикмәт. Эчкәнем булса икән.

Врач. Эчкәлисез шул.

Егет *(залга карап).* Менә хикмәт. Күз буучыдыр бу. Сәйфидә самогон төшергәнне әйтмәсен тагы.

Врач. Хәзер үк кайтыгыз да председатель янына керегез. Нинди эш кушса да баш тартмагыз. Физкультураны да онытмагыз. Бик кирәк ул сезгә.

Егет. Менә хикмәт. Спорт мастеры булып куярмынмы? Юк инде, доктор апа. Мин 25 яшьтә хәзер. Малайлар уены уйнарга буыннар каткан.

Врач. Бөек галим Павлов сиңнән 50—60 яшькә олырак вакытында да велосипедта йөргән, городки уйнаган.

Егет. Картайгач, кешегә балалар акылы керә шул. Ул яшькә житкәч, әллә мин дә уйнармын.

Врач. Житә алырсызмы? Ялкау кеше озак яшәми.

Егет. Менә кил син больницага. Ярдәм өмет итеп кил. Ярдәм урынына сиңа — авыр эш, очсыз-кырыйсыз физкультура, кып-кыска гомер.

Врач. Юк, мин сезгә баштагы икесен генә тәкъдим итәм.

Егет. Болай булсагыз, авыруларны больницадан биздерер бетерерсез әле. Берегезне дә тыңламыйм. Сезне дә, председательне дә. Үз башыма да мәкинә тутырмаган. Өйгә дә кереп тормыйм, комбайннан салам ташлатырга барам. Авырсам, үзегез ялынып килерсез, ну мин комбайннан төшмәм.

I алып баручы.
**Әй шәп врач Лидия,**
**Ап-ак халатын кия.**
**Ап-ак бүлмәгә керә.**
**Чирләп килсән,**
**«бик тәмле» дип,**
**Бик әче дару бирә.**

II алып баручы.
**Кыр батыры авырмасын,**
**Чирләр аңа кагылмасын,**
**Шундый изге теләк белән,**
**Таңнан торып кырга килгән.**
**Сәламлиләр алтын кырлар,**
**Бездән сәлам — ялкын җырлар!**

Медицина работникларының яраткан берничә җыры башкарыла.

I алып баручы.
**Янгыра, җыр, ераkларга,**
**Уралма тирәкләргә,**
**Арган чакта көч булып син**
**Кабатлан йөрәкләрдә.**

Хор. Саубуллашу җыры җырлана.

II алып баручы.
**Хушыгыз, апалар, абыйлар,**
**Энеләр, сеңелләр.**
**Дәртле эш утында**
**Җилкенсен күңелләр.**

I алып баручы.
**Күп сездә эшчәннәр,**
**Уңганнар, тырышлар.**
**Гел үнсын игеннәр,**
**Мул булсын уңышлар.**

Галәви.
**Эшләгез берләшеп,**
**Яшәгез гөрләшеп.**
**Өстәлеп торсын гел**
**Сөенеч һәм бәхет!**

*Мирсәй Әмир*

# УКЫЧЫ ӨЧЕН ЯЗАБЫЗ[1]

Докладлардан да, чыгышлардан да күрәбез: 1966 елда да безнең язучыларда иҗат активлыгы җитәрлек булган. Драматургияне искә алмаганда, барлык жанрлар буенча да шактый күп һәм җитди әһәмияткә ия булырлык яңа әсәрләр иҗат ителгән. Шулай да, узган елларга караганда бераз үзгә буларак, бу елда поэзиябез нәтиҗәлерәк күренгән әйтәсе килә. 1966 елда С. Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасы, С. Батталның «Чирмешән якларында» романы кебек күләм ягыннан да, идея эчтәлеге ягыннан да җитди әһәмияткә ия булган әсәрләр игълан ителде, гражданлык пафосы белән сугарылган лирик шигырьләр язылды. Яшь көчләребез алып килгән шигырьләр дә поэзиябезне әһәмиятле яңалыклар белән тулыландырдылар.

Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме буенча да узган елда сизелерлек, күзгә күренерлек әһәмиятле хезмәтләр дөнья күрде. 1966 елның зур юбилейлар елы булуы да тәнкыйтьчеләребезне активлаштыра төшәргә ярдәм итте. Муса Җәлил, Г. Тукай, Ф. Әмирхан иҗатлары турында күп кенә әһәмиятле хезмәтләр барлыкка килде.

Прозабыз турында мин Гариф Ахунов (докладчы буларак) әйткән фикерләр белән кигездә кушылам. Тик кайбер әсәрләргә карата биргән бәяне бәхәсле дип карыйм.

Сүз башлыча Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясенә кагыла. Бу әсәр турында сөйләгәндә, аның әдәби эшләнеше, сайланган эчтәлеге һәм проблемаларның әдип тарафыннан сәнгатьчә хәл кылынуы хакында әйтелгән фикерләр белән мин тулысынча кушылам. Ләкин бу хикәя узган елда язылган барлык проза әсәрләре арасында иң югары урында тора дигән фикер белән бәхәскә керәм. Чөнки әдәби әсәргә бәя биргәндә аның сәнгатьчә эшләнеше ни дәрәҗәдә булуга карап кына фикер йөртү белән чикләнә алмыйбыз. Бер үк дәрәҗәдә, хәтта күбрәк дәрәҗәдә дисәк тә артык булмас, аның идея эчтәлегенә дә игътибар итәргә тиешбез һәм итәбез.

«Әйтелмәгән васыять» хикәясендә авторның укучыны өлкән буын кешеләренә карата игътибарны көчәйтергә чакыруы бик дөрес. Бүгенге тормыш көймәсенең койрыгын күптән үз кулларына алган яшь һәм урта буын кешеләрен ата-аналарыбыз, әбибабаларыбыз өчен изге булган хисләр, йолалар белән җитәрлек хисаплашмауда гаеплаве дә урынлы. Бу кадәресе белән, әлбәттә, килешергә була. Ләкин Әмирхан иптәш, минемчә, бу мәсьәләдә тормыш үзе чыгарган кануннар белән исәпләшми.

Реаль тормыш халыкта борыннан килгән гадәт-йолаларның, традицияләрнең яхшыларын дәвам иттерү, аларны яңа шартларга буйсындырып, тәрәккый иттерү, тулыландыру һәм баету юлы белән бара. Моны без борыннан да элек төрле буын кешеләре арасындагы мөнәсәбәттә күрәбез. «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә автор бүгенге тормышыбызда әйдәүче урын тоткан буынны инде картлыкка чыккан буынга каршы куя. Ягъни ике якның берсен кире кагу позициясендә тора. Автор, бәлки, мин алай куярга теләмим, дияр. Бары яшьләрнең картларны аңламаганлыгын гына күрсәтергә теләдем, дияр. Әйе, әсәрне шулай аңлатырга да урын бар. Чөнки андагы яшьләр чыннан да картларны үзләренчә хөрмәт итәләр. Ләкин үзләренчә генә шул. Аларча караганда, өстенә кияр киеме, ашарына ризыгы, торыр өчен җылы урыны, хәтта аерым бүлмәсе булгач, карчык кешегә тагы ни кирәк! Ә ул карчык — борыннан да элек кеше бит әле! Зур үткәненә, бүгенгесенә, балалары аша киләсе көннәренә дә баглы кичерешләре, уй-тойгылары, бай, катлаулы эчке доньясы булган кеше! Яшь буын моны аңламый. Бу, әлбәттә, әдәби әсәр өчен катлаулы психологик момент. Ләкин мәсьәләнең аянычлы ягы шунда: автор бер-берсенә каршы куелган бу ике буын кешеләренә мөнәсәбәттә объектив позициядә тора алмый — үзе дә ике якның берсенә кушылып китә. Тагын да аянычлырагы: картлар ягына, әсәрдә сурәтләнгәнчә,

[1] Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышны ябу алдыннан булган чыгыш.

инде бетүгә хөкем ителгән, төзәлмәс чиргә мөбтәля булган, хәтта инде үлеп үк киткән Акъәбиләр яки, өрәге бу дөньяда булса да, үзе кеше буларак инде күптән сафтан чыккан Миңлебай картлар ягына кушыла.

Мин моны әсәрнең стилендә күрәм. Чөнки авторның бөтен мәхәббәте, барлык җылы хисләре Акъәбиләр ягында. Ул аларның тойгыларын, хәрәкәтләрен якын күреп, үз күреп сурәтли, аларны кызгана, кызгандыра... Дөрес, ул Акъәбигә каршы куелган яшь буын кешеләрен дә кара төсләргә буямыйча, тормышта ничек булсалар, шулай күрсәтергә тырыша. Ләкин язучының боларга теләктәшлек күрсәтмәве һәр җөмләсеннән диярлек сизелеп тора. Аларның тышкы хәрәкәтләре дә, эчке дөньялары да ирония аша, ничектер примитивлаштырып бирелә. Нәтиҗәдә укучыны алга әйдәү урнына, аны артка, иске авылга, тизәк яккан учаклар, салам түбәләр, читәннәр авылына йөз юнәлдертергә тырышу килеп чыга. Туган ил төшенчәсен тарайтып аңлата.

Хикәянең ахырында үзенең ничә ел яшәгәнен дә онытkан Миңлебай картның Акъәби турында: — Ул үлмәде, ул кайтыр! — дип раславы, аның тизәк көле астында пыскыган учагын сүндермәскә өндәве, йомшак итеп әйткәндә, миңа аңлашылмый. Кайбер иптәшләр бу образга карата, ул бит инде күптән аңын җуйган, алҗыган карт, аның сүзләреннән нинди дә булса мәгънә эзләү урынсыз чокчыну булыр иде, дияргә телиләр. Шулай да булсын, ди. Ләкин аны хикәясенең финалына китереп куйган автор үз акылында бит! Әдәби әсәрдә һәр детальнең автор теләсә дә, теләмәсә дә гомумиләштерелгән икенче мәгънәсе дә буласын аңламый торган кеше түгел.

Һәрхәлдә, минемчә, әсәр бәхәсле, ул укучыны кирәкмәгән юнәлештә уйландырырга да юл калдыра.

Һәм шушы уңай белән узган еллардагы йомгаклау җыелышларында да әйтелгән фикерне кабатларга туры килә. Ягъни бездә бәхәсле әсәрләр языла тора, басылып чыга тора, алар турында кулуарларда сүз көрәштерүләр дә бара, ләкин матбугат битләрендә ачык бәхәс булмый кала. Бу безнең хәрәкәттәге әдәбиятыбызга бәйләнешле кыю тәнкыйтьнең һаман да йомшак икәнлеген күрсәтә торган хәл. Шушы ук җитешсезлегебез бәласе буларак, бездә әле һаман да әдәби кыйммәте бик аз булган яки бөтенләй булмаган әсәрләр, «басылса гаҗәп түгел, басылмаса хаҗәт түгел» җөмләсенә керә торган тезмәләр һәм чәчмәләр, диалоглар һәм монологлар газета-журнал битләрендә генә түгел, нәшрият чыгарган китаплар арасында да, сәхнәләрдә дә, эфирда да, телевизор экраннарында да үзләренә урын табалар.

Зәет Мәҗитов иптәш үзенең докладында укучы өчен язылган тәнкыйть җитмәве турында, минемчә, бик дөрес әйтте. Бездә чыннан да әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр һаман да күбесенчә автор өчен, нәшрият яки театр өчен язылалар. Киң катлам укучы өчен язылган тәнкыйть мәкаләләре күбрәк булсын! Барыбыз да укучы өчен язабыз.

Без хәзер бөек юбилей елында. Алда Бөек Ленинның тууына 100 ел тулу көне якынлаша. Узган әдәби елыбыз да шушы тарихи көннәргә әзерлек билгесе астында узды. Бу уңай белән безнең әдәбиятыбызда Ленин образын гәүдәләндерүгә багышланган һәм җир шарында беренче булып яңа дөнья төзү шартларында узган ярты гасырның тарихи яктан аеруча әһәмиятле чорларын җанландырган әсәрләр язылды һәм язылу өстендәләр. Һәр язучы, бик табигый буларак, бу зур бәйрәмне аның әһәмиятенә лаеклы булган яңа әсәр белән каршы алырга әзерләнә. Бу, әлбәттә, бик мактаулы эш. Ләкин Совет властеның илле еллыгы — ул гади бәйрәм генә түгел. Дөнья күләм зур тарихи вакыйга. Шуңа күрә бу тантананы турыдан-туры аның үзенә багышлап язылган яңа әсәрләр белән каршы алу гына җитми. Узган 50 ел революциянең җиңүе өчен, аның бүгенге тантанасына килү өчен өзлексез көрәш еллары булдылар. Соңгы ике ел эчендә генә түгел, 50 ел эчендә ирешкән уңышларыбыз белән каршы алабыз без бу бәйрәмне.

Хәзер безнең алдыбызда шушы ярты гасыр эчендә иҗат ителгән әсәрләребез арасыннан заман сынавын яхшы үткән иң күренекле әсәрләребезне дә искә төшерү, мөмкин булган дәрәҗәдә аларның үзләрен күрсәтү, шушы елларда туып җитлеккән һәм илебезнең хөрмәтле кешеләре рәтенә кергән язучыларыбызның әдәби портретларын бирү, элдынгы замандашларыбыз, үзебез кичергән көрәш еллары турында чын әдип каләме белән язылган җанлы истәлекләр бастыру бурычлары тора.

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫННАН МАТЕРИАЛЛАР**

*Нәкый Исәнбәт*

# ШӘЙХЗАДӘ БАБИЧ

*Күренекле язучыбыз Нәкый ага Исәнбәт зур фәнни хезмәт төгәлләп килә. Хезмәттә татар һәм башкорт әдәбиятларының классик шагыйре Шәйхзадә Бабич поэзиясе тикшерелә, Октябрь революциясе елларында Башкортстан җирендәге иҗтимагый тормыш, әдәби хәрәкәт яктыртыла.*

*Редакция Нәкый ага хезмәтенең кайбер бүлекләре белән укучыларны да таныштырып барырга булды. Журналыбызның бу санында әлеге хезмәттән алынган беренче мәкалә бирелә.*

## Шәйхзадә Бабичны беренче һәм икенче мәртәбә күргәндә

Мин Шәйхзадә Бабичны гомеремдә өч мәртәбә күрдем. Бу күрүләремнең барын бергә җыйсаң, ихтимал, өчесе бер сәгатькә дә тулмас, шулай да бу очрашулар минем өчен бик зур мәгънәле һәм тирән эз калдырган булып чыктылар.

Беренчесе, моннан 54 ел элек, бик бала чагымда, минем өчен һич көтелмәгән бервакытта булды. 1913 елның март башлары иде бу. Ул чагында Өфедә Кузнецк дигән урамда, бер катлы агач өйләр арасында, «Хәсәния» дигән таш мәдрәсә бар иде. Күз алдыгызга китерегез: тар гына агач баскычтан йортның икенче катына менелә. Ишекне ачып керүгә бер якта мич, каршы стена буенда өсте-өстенә өеп куелган кыска аяклы, озын буйлы парталар. Шунда камзул-түбәтәйле малай шәкертләр. Аннан үтеп каршы ишектән шундый ук икенче бүлмәгә, ансыннан да үтеп өченчесенә керәсең. Бу түр бүлмә дәресханә дип атала. Анда пишкадәмрәк шәкертләр торалар.

Монысына килеп керүгә бераз караңгы. Бары тик түгәрәк, биек калай мич белән шкаф арасыннан төшкән яктылык сызыгы гына сине бүлмә уртасына китереп кертә. Бер көнне шул яктылык сызыгы буйлап бүлмәгә буй җиткән ике егет килеп керә. Алар уртадагы әлеге калай мич янына басып, бүлмәгә бер күз салып алгач, һич тә исләре китмәгән кыяфәттә генә шул мич янына ук как идәнгә утыралар. (Мәдрәсәдә утыргыч юк.)

Ис китәргә монда бит алар өчен әллә ни ят нәрсә юк, бар да ул заман өчен табигый күренеш: күз алларында биек кенә бер бүлмә. Идәндә стена буйлап җәелгән киез-келәмнәр, алар өстендә кыска аяклы тәбәнәк өстәлләр. Ул өстәлләрнең түр башларында өелгән китаплар. Бүлмәнең иң түр почмагы, билгеле инде, казый һәм пишкадәмнәр урыны. Ләкин бүген анда беркем дә юк. Башка өстәлләр тирәсендә дә бер-ике шәкерт кенә күренә. Бүген ял көне — җомга көн итеп, күрәсең, аларның күбесе калага-нигә чыгып киткәннәр. Әнә икенче түр почмакта, тәбәнәк өстәл янында аяк бөкләп ябык кына бер малай шәкерт утыра. Түбәтәйчән, камзулчан... Кулында каләм. Өстәл астыннан дәфтәрен чыгарып алдына сала да бик тәмләп шул дәфтәр битләренә текәлә.

Бу малай — мин идем.

Баштарак мин мич янында утырган ул егетләргә карап-карап алсам да, тынычлап утыруларын күргәч, аларга артык күзем төшмәде. Азмыни монда андый кереп чыгучылар! Берәүнең ата-анасы яки агай-энесе килер, берәүләр болай эш юктан үтешли генә кызык өчен күреп чыгыйм әле дип керер... Мәдрәсә ич ул. Ишеге һәркемгә ачык. Рәхим ит, кара да утыра бир.

Билгеле, ул яңа кергән абыйлар мине дә күрәләрдер. Алар мине бу шәкерт дәрес әзерли дип беләләр булыр. Бик яхшы, тик шулай дип белсеннәр. Ләкин минем өчен җомга көннең бар рәхәте иң элек шушылай кешесез генә калып, аулаклап утыру. Менә бүген дә мин яңагыма таянып, алдымдагы шигырьләремне эчемнән генә укыйм. Яратам шуларны... Дөньяда шуларны яңадан бер кат күздән-күңелдән кичерүдән, кайбер юлларын тагын да матуррак итеп «чыгару»дан да ләззәтле эш юк. Чөнки болар бит минем үз шигырьләрем...

Күпме шулай утырганмындыр, ләкин, никтер, кинәт кенә шунда ялт итеп мич ягына бер күз салдым. Карасам, анда әлеге ике кешем дә миңа карап утыралар. Берсе аның чандыр, җитмәсә, шадрамы шунда. Башында очлы бүрек. Әмма шул бүрек астыннан чыгып торган зур-зур колаклары күзгә ташлана. Югарак кына пальтодан иде, ахрысы. Үзе ул, бүгенге кебек хәтеремдә, тезләнеп утырган, озын гәүдәсе алгарак яткан, иреннәрен кыскан, үткен һәм җитди күзләрен батырып һаман миңа карый. Икенчесе аякларын бөкләп, җәелә төшеп утырган. Аның йөзе киң, яңаклары чыгынкы, карасу чырайлы. Аксыл сары бишмәттән. Ул казакъ я[...]и башкорт булырга кирәк. Тирмәдә утырган кебек, бик җайлап утыра, хәтта бер[...]елмайган да кебек. Ул да миңа караган.

Минем шулай үз-үзем белән кәефләнеп утыруым аларга д[...]елеп киттеме, белмим нидәндер, кинәт мин уңайсызландым. Кеше әйбере белән [...]тылган кебек тиз генә алдымдагы дәфтәремне җыйнап, өстәл астына тыкмакчы б[...]дым. Ләкин шунда көтелмәгән бер хәл булды. Минем нишләмәкче булуымны кү[...] белән, теге тезләнеп утырган озын буйлысы, аягына да басмады, идәннән үрмәләг[...]ул-аякларын алга бер-ике генә атты да шундук минем каршыма ук килеп утырды. Өстәл аша сузылып кулымдагы дәфтәремнең бер башыннан тотты:

— Тукта, нәрсә язасың? Шигырьме? — ди. — Безгә дә күрсәт әле...

Казакъ кыяфәтлесе дә килеп җиткән. Елмаеп аның янында утыра.

Менә кирәк булса! Бу кешеләр, ахры, миңа төбәп килгәннәр. Шигы[...]е дип тә сорый, әллә болар мине шигырь чыгаручы малай дип ишетеп, үземнә күр[...] килгән кешеләрме?..

Мин дәфтәремне аңа суздым:

— Әйе, шигырь, — дидем бугай.

Ул дәфтәрне алды, тиз-тиз битләрен ачкалап күз ташлап чыкты.

— Тагы бармы?

— Бар...

Булмыймы соң миндә...

Өстәл астында, чынаяклар артында, иң кадерле почмакта гына яшереп са[...]ан шигырь дәфтәрләремне берәм-берәм чыгарып алдына куя барам. Исемнәре ты[...]нда: «Башкортлар өчен чиккән аһ-вә хәсрәтләрем», «Күңел кояшы», «Яшьлек [...]ә-ремдә»...

Тегем ашыгып-ашыгып карый.

— Шигырь генә чыгарасыңмы?

— Юк, менә көлке журналлар да чыгарам. Менә «Балта», менә монысы «Балд[...] Минем бер романым да бар.

Какча егет бер дә көлми, киресенчә, тагын да җитдирәк кызыксынган кыяфәт б[...]лән миңа карады:

— Роман да дисең? Кайда ул? Я әле, я? Күрик.

Шулай диде, ахры. Мин уңайсызланам:

---

[1] Балда дип бездә авыр чүкечне атыйлар. Мин аны шул исемдә җәйләрен үзебезнең авылда чыгара идем. Н. И.

— Роман дип, ул ни... язылып бетмәгән әле. Йөз бит чамасы гына. Башкортлар тормышыннан, — дип нәрсәдер мыгырдандым.

— Каяле, кая, диләр. Ахырында аны да чыгарам. Ачып-ачып карыйлар. Шулай «бар малымны» алларына чыгарып куйгач, мин дә хәзер иркенләп карасыннар диген кебек, тордым да читкәрәк киттем. Күңел түзәме соң! Күрше бүлмәгә чыктым. Авыз җырылган инде, җыеп та алып булмый. Ничек инде... Шундый дәү кешеләр сине шагыйрь дип ишетеп эзләп килсеннәр әле... Шатлыгым эчемә сыймый. Малай чак бит. Аягымны кая басканымны да белмим. Чабам, ахры... Мин шулай бүлмәләрдә җилтерәп бер әйләнеп чыгарга да өлгермәдем, дәресханә ишегендә бер шәкертнең башы-кулы күренде: «Әйдә, тиз бул, тегеләр чакыра», — дип изәде.

Мин тагын анда кердем, алар янына килдем. Әлеге чандыр йөзле, зур колаклысы бу юлы коңгырт күзләрен мөлаем елмайтып кызык кына итеп миңа карады:

— Син, ди, бу дәфтәрләреңне миңа биреп җибәр, мин анда яхшылап укырмын. Курыкма, без «Галия» шәкертләре...

Мин үз шигырьләремә бу кадәр илтифат күргәч, күңелләрем тәмам эреп киткәнгәме, бер нәрсә дә уйлап тормыйча:

— Ярый, ярый, — гына дим. — «Галия»некеләр булгач...

Ул бар дәфтәрләремне йомарлап куенына тыкты да урыныннан торды:

— Сау булып торыгыз, — диде, ахры. Кулын бирде. Тегесе дә. Менә чыгып та киттеләр.

Минем тирәгә шәкертләр җыелды. Зәки абзый[1] да кайтып җитте. Тиз-тиз вакыйганы аңа сөйлә бирдем.

— «Галия»некел ｐ? Кемнәр ди соң алар?

— Белмим.

— Кайсы ыйныфта укучылар? Сорадыңмы?

— Юк...

— Шәп ансең! Бәләкәй чагыңнан бирле чыгарып килгән шигырьләрең... Ярый ла яхшы ке әр булып китереп бирсәләр. Ә китермәсәләр?..

Алай икән. Мин, ачык авыз, үземнең оригинал әсәрләремнең берданбер данәләрен биреп җибәргәнмен. Кемнәр икәнлекләрен дә сорашмыйча! Куанычымнан ансы хәтеремә дә килмәгән. Хәер, хәтеремә килгән булса да исемнәрен сорарга кыймаган булыр идем. Мин нәрсә? Үндүрт яшьлек малай, алар дәү шәкертләр. «Галия»не әр... Шулай да күңел киресенә ышанмый. Китерерләр, китерерләр...

Китүл әнә бер атна үтте, ике дә үтте. Шигырьләр һаман кайтмый. Март бетте, апрель керде. Менә инде бер айдан артык була. Зәки абзый мине шелтәли:

— Ә темме? — ди. — Икенче акыллырак булырсың.

Икен ә бер олы шәкерт тә аңа кушыла:

— Ул «Галия» җуликларына ышану... Ай-һай, белмим шул. Без өйдә булсак, алай гына еп җибәртмәгән булыр идек. Моның малайлыгыннан файдаланып... Чынлап та б Апаң бармы, бар, миңа бирәсеңме?» дигән кебек, җүләр саттырып, кешенең үзе арган бар шигырен ал да кит, имеш! Әле җитмәсә, үз исемнәрен куеп бастыр та чыгарырлар...

шләргә? Барып сорап эзләп карарга мы? «Галия» бит... Мин аның тирәсенә якын ба та караганым юк. Көләрләр... Минем эч сыза. Дәшмирәк пышын-пышын йөри ба дым. Ул да булмады, бер матур яз көнне дәресханәгә бер шәкерт ахылдап ча п керде:

— Чык, сине тышта бер абый чакыра...

— Кем? Кем?

Минем йөрәк жу итеп китте. «Тегеләр»ме әллә? Тиз-тиз күтәрмәдән төшәм. Тышта к яш. Карасам, кара юка пальтодан теге какча, озын егет. Башын югары күтәргән. ік һәм тез генә баскан да тора. Юлдан бер читтәрәк... Дәшми. Бу икенче очрашуы ызда ул миңа бераз горур һәм һавалы сыман күренде.

Мин якынлагач, ул да шунда миңа табан бер атлап куйды. Йөзендә дә җитди гътибар күренде. Куеныннан төргәге белән теге дәфтәрләрне чыгарды:

[1] Зәки абзый — минем бертуган агам, югарырак сыйныфта укучы.

— Менә дәфтәрләрең. Барысы да шушында, — дип миңа сузды. — Яхшы, яз шулай. Сау бул!

Елмая төшеп кулымны кысты, бер генә кат селкеп куйды. Тиз һәм житез атлап, алдына караган хәлдә ян капкага борылды. Китте...

Дәфтәрләрне алып, баскычтан очып менгәндәй мендем, өстемнән тау төште. Кер-керешкә дәфтәрләрне күтәрә бирәп, Зәки абзыйга кычкырдым:

— Менә, китермәсләр диган идең!

— Барысы дамы?

— Барысы да.

— Нәрсә әйтте?

— Ә ул... ул артык сөйләшеп тормады.

— Шигырьләрең турында... Бер сүз дә әйтмәдемени соң?

— Юк...

— Ай буе тоткан, укыган... Хет күңел өчен бер сүз әйтсен иде малайга...

Чынлап та, бу абый кешем бераз сәеррәк булып чыкты әллә? Алганда бик яхшы иде, икәүләшеп читтән күзәтеп тордылар, яныма да килеп утырдылар. Ә тапшырганда... Чык тышка, мә сиңа дәфтәрләреңне. Исән бул!.. Әллә шигырьләремне яратмаган булдымы? И, ул кешә үзе соң шигырь дигәннең тәмен, мәгънәсен беләме икән әле? Ярый әле шунсы бәхет: югалттым дип курыккан шигырьләрем үземә кайтты...

Мин дәфтәрләремне өстәлгә салып, бит-битләп ачып карый башладым. Бар да урыннарындамы? Тукта, чү! Монда бер язулы пучтавай кәгазь[1] битә килеп чыкты. Карасам, анда шигырь белән шундый юллар язылган:

**«Яшә, Нәкый!**
**Мин сине тәбрик итәм шигырең белән, Әхмәт Нәкый.**
**Бик шат улдым, мәмнүн улдым мин сиңа, рәхмәт, Нәкый!**
**Мин өметлемен сиңа, истикъбалың парлакъ[2] синең:**
**һәм булачак (инша алла) мәртәбәң «чарлакъ» синең!**
**Ихтирам илә кардәшеңез Ш. Бабичев»**

Э-м-м, әйтәм шул... Күрәсең, бу «Галия» шәкерте үзе дә шагыйрь булып чыкты. Әллә ул берәр яшерен шагыйрь микән? Мин бер дә мондый фамилияне матбугатта очратканым юк. Ә шигыре нинди шома, зур шагыйрьләр кебек оста итеп, килештереп язылган. Миңа нинди зур теләкләр белдергән!.. Миңа, ялан аяк тузанда ат булып чапкан бер малайга!.. Ул минем шигырьләремне яраткан! Минем өчен моннан да зур бер мөкафәт булырмы?

Әйе бит әле, ул тышта басып торганда да ниндидер һавалы, өстен бер кыяфәттә башын күтәреп тора иде. Шагыйрь һәм шулай булырга тиеш тә. Ул бит күңеле, хыялы белән югарылыкларда йөзүче зат. Ул үзе шагыйрь булган өчен дә шулай дөньяга сер бирмәс, кимсенмәс кыяфәттә басып торган. Тик дәфтәрләремне биргәндә генә миңа мөлаем карап, үзенең тиң күрүен сиздереп куйды. Күрдеңме... Аз сөйләште, әмма күп мәгънә аңлатты...

Шул ук кәгазьдә Бабичның бу шигыре астына икенче кул белән болай дип язылган иде:

**«Мөхтәрәм Нәкый әфәнде!**
**Без, казакъ кардәшеңез Әхмәд Мамитов, дәхи сезнең сәламәтлекеңезне теләнәктә вә киләчәктә бик зур өмиддәмез.**
**Ә. Мамитов».**

Кардәш, туган казакъ халкының бер вәкиленнән минем кебек өйрәнчек татар шәкертенә өметле караш, жылы сүз.

Һәм шуннан ике ел да үтмәде, Бабичның исеме һәр жирдә ишетелә, әсәрләре басыла башлады. (Мин дә шул елларда бастыра башладым.) Казанда мин язышкан «Аң» журналы идарәсе Бабичның «Газазил» поэмасын соратып алып һәм алдан игъ-

[1] Элек хат язу өчен тотылган кечерәк битле махсус матур кәгазь шулай дип атала иде.
[2] Истикъбалың парлакъ — перспективаң якты балкып тора.

лан итеп бастырып чыгарды (15 нче ел). Бабич? Әдәбият мәйданында бу исемне күргәч, шунда гына кинәт минем хәтергә теге чакны «Хәсәния» мәдрәсәсенә килеп, мине эзләп табып, шигырьләремне укыган әлеге озын, ябык «Галия» шәкерте искә төште. Аның миңа багышлап язган кәгазен, шигырен яңадан табып алып укып карадым: Ш. Бабичев! Менә ул кем! Миңа киң иҗат мәйданына башлап юллама биргән кеше зур талантлы шагыйрь Шәйхзадә Бабич үзе булган икән!..[1]

Шәйхзадә Бабич белән бу очрашуыбызга тәгәлрәк тукталуым һәм ул чагындагы үз кәеф хәлемә дә урын бирүем бу вакыйганың минем өчен әһәмиятле булып кына калмыйча, аннан да бигрәк Бабичның үзен һәм аның иҗтиһатын тасвирләү ягыннан характерлы булуы өчен икәнлеге укучыга шаять аңлашыла торгандыр дип уйлыйм. Чөнки бу вакыйга, минемчә, Бабични яңа бер яктан ачарга ярдәм итә. Тәптәнрәк уйлаганда, бу булган хәлнең тарихи яктан да, шулай ук безнең бүгенге заман өчен дә гыйбрәтле ягы һәм мәгънәсе бар. Чөнки Бабичның мине эзләп килүе ул чагында аның Өфедә үзенә шагыйрьләр даирәсе табалмаганы өчен түгел, алар анда җитәрлек табыла иде. Иң элек ул укыган «Галия» мәдрәсәсе үзе яшь шагыйрьләр учагы иде. (Ярмәкиләр, Ибраһим Башмаковлар, Гыйзетдин Исәнбирдиннәр, Ходаяровлар һәм башкалар.) Шунда ук мәдрәсә күршесендә генә классик шагыйрьләрдән Гафури, Сәгыйт Рәмиев яши, арырак Сүнчәләй һәм башкалар бар иде. Өфенең үзендә татар матбугаты һәм мәтбагалар бар иде. Билгеле, Бабич шулар арасында кайнап үсә һәм «Галия»не үзе дә кайната иде. Шулай булса да, ул кайдадыр Сабир хәзрәт мәдрәсәсе «Хәсәния»дә шигырь язып ятучы тагын бер малай шәкерт бар икәнен ишетә. Андый шәкертләр һәркайда беткәнмени? Ләкин, юк, Шәйхзадә андый түгел. Ул үзенең казакъ шәриген иәртеп, гомердә аяк басмаган «Хәсәния»гә килә, мич янында как идәнгә тезләнеп утырып, зур чыдамлык белән, шул малайны читтән күзәтеп утыра, әсәрләре белән дә өстән-нидән генә танышып китми, бәлки җентекләп уку өчен үзенә ала, укый, тапшырырга тагын үзе күтәреп алып килә. Ул гына да түгел, шул малайның балаларча хыял җимеше булган шигырьләрендә өмет һәм шигърият чаткысы күргәч, ага булып, аны якты иҗади киләчәккә, уңышларга чакырып, рухландыручы шигырь язып кулына тоттыра...

Хуш, шуннан нәрсә чыга, диярсез.

Гадәттә Шәйхзадәне талантлы, ләкин шаталак, юләр сымак, уен-көлкеле, җиңел кеше итеп күрергә яраталар. Кемгә ничек булгандыр һәм кемдә нинди тәэсир калдыргандыр, ләкин мин күргән Шәйхзадә андый кеше түгел иде. Мин аны татар һәм башкортлар өчен әдәбият тудыру юлында чынлап янып көрәшүче, аңа бу эшне беркем дә тапшырмаган булса да, үзенчә, әдәбият кадрларын үстерү артыннан йөрүче кеше итеп күрәм. Әнә шул юлга үзе җәяүләп төшкән, мәдрәсәдән мәдрәсәгә йөри, үсмер балалар арасыннан өметле яшь каләмнәр эзли, шундый шәкерт табылса, аның күңеленә рух өрә һәм язучылыгына юлламалар бирә. Болай үзе карап торышка сатир кыяфәтле булса да, ул, халык мифологиясендәге легендар Хезерильяс кебек, нииндидер изге җанлы, бик җитди кеше булып күңелемдә калган. Мин моны иң элек үземә карата булган шушы мөнәсәбәтеннән алып әйтә алам.

Әйе. Ул чагында Язучылар союзы да булмаган, әгъзалык билетлары бирү дә юк, язучылар алдында да, хәзерге кебек, әсәрләрен бастыру өчен планга кертү яки кәгазь табу кайгысы гына тормый һәм начальник каршына гына түгел, бай абзый каршына барырга кирәк. Алай да нәкъ шундый сыйнфый һәм милли изелүләр заманында да әдәбиятыбыз һәм аның кадрлары өчен чынлап янучы Шәйхзадә кебек дәртле агалар булган. Алар үзләре фәкыйрь шәкерттән булсалар да, кече энеләрен үстерү кайгысын чиккәннәр. Шуның аркасында бездә һәркайда диярлек үзешчән юл белән әдәби хәрәкәт туып үсеп, алга барып торган. Язучылар туып, әдәбиятыбыз, каты реакцияләргә бирешмичә, үзенә юл ярып үсеп барган. Яки, икенче төрле әйтсәк, милли изелү булса, аңа каршы милли уяну, азатлык хәрәкәте дә булган.

Әйе. Шәйхзадә Бабич ул, билгеле, үткен һәм зур талантлы шагыйрь, көчле сатирик, декламатор. Шуның өстенә ул әдәби үзешчән түгәрәкләр, хәрәкәтләр оешты-

[1] Шәйхзадә Бабич һәм казакъ Әхмәд Мамитовларның бу кулъязмалары әле дә үземдә саклана.

ручы, яшьләрне үстерүче, изге йөрәкле, ярдәмчел ага иде. Ул әдәбият бакчасында үзен чәчәк дип кенә түгел, бакчачы дип тә белгән кеше. Шундый кешелекле, халыкчан сыйфатлары белән гуманист шагыйрь Шәйхзадә тагын да зуррак ихтирамга лаеклы, җитди әдәби педагог булып та минем күз алдымда тора.

## Бабичны өченче кат күргәндә

18 нче ел... Тын гына матур бер җәйге кич. Алдыгызда ике катлы гүзәл таш бина тора. Тәрәзәдә утлар. Эчтән уен да җыр, музыка тавышлары яңгырый. Бу сезгә Өфенең «Госмания» мәдрәсәсе булыр. Бүген монда курста укучы мөгаллим-мөгаллимәләрнең ял кичәсе бара.

Ул вакытлар Өфегә һәр җәйне диярлек Урал-Себердән, Идел-Камалардан укытучылар җыела. Революция булгач, элекке хокуксыз мөгаллим-мөгаллимәләрне, шәкертләрне тиз-тиз курстан үткәреп, аттестацияләр бирергә кирәк булып чыккан. Шунлыктан Өфе җәй көннәрендә бик җанлы була, үзен азат, ирекле, бәйсез тоючы яшьләр белән шау килеп кайнап тора иде.

Без «Госмания»гә керергә торганда, кемдер шунда: «Беләсезме, бүген Дарелмөгаллиматта да вечер икән», — дип әйтә салды.

Дарелмөгаллиматмы? Һуу... ул Дарелмөгаллимат дигәнең[1]. Әллә шунда барабызмы?

— Монда, үзебездә, атна саен булабыз. Әйдәгез анда киттек.

Берничә курсант чынлап та шунда китәргә булды. Аларга ияреп мин дә Дарелмөгаллиматны күрергә киттем. Ул шактый ерак, толчокка таба бер урамда булып чыкты. Башта безгә әллә кайдан ерак бер шау-гөр ишетелеп торды. Барган саен гөрелте көчәя, җанлырак була бара. Менә уен, җыр тавышлары ачык аерыла башлады. Без казарма кебек зур-зур тәрәзәле, ике катлы якты бер агач бина турысына килеп чыктык. Бөтен тәрәзә-ишекләр шар ачык, бөтен шәһәргә гарасат! Бер кемнең бер кемдә эше юк!.. Ә кемнән сорап торырга? Заманы шундый! Эчкә керәбез. Баскычыннан менәр хәл юк, кая карама кызлар. Бар да бәйрәмчә киенгән. Бар да тыгызлыктан, бөркүдән янган-пешкән, өскә дә, аска да кеше агыла. Мин дә бер янга сыгылам. Бер агым мине үргә таба агызып алып менеп бара. Мин инде өске катта. Урта бүлмәдә шау-гөр, кискен тавышлар, уеннар бара. Аяк тертеп тукталыр урын юк. Мин тынычрак почмак эзләп каядыр ян ишеккә сыгылам. Боларда да егетләр аз икән, бүлмә тулган кызлар... Җайсызрак булса да, биредә бер яктарак басып торып халыкны карарга була.

Аякка ныгытып басып алырга да өлгермәдем, тагын этәреш башланды. Арттан бер егет терсәкләре белән юл ера: «Бабич килгән, Бабич!» — ди, залга ашыга. Шул уңайга мине дә бер якка кагып янымнан теге егет, аның артыннан кызлар төште. Ишек юлы буылды. «Бабич» та «Бабич!». Бар да бер-берсен узарга тырышып шунда агыла. Барысын да кузгаткан бу сүз мине дә электереп ала. Бу сүз миңа үзенә бертөрле тәэсир итә. Бер сүзне дә критикасыз кабул итәргә өйрәнмәгән минем акыл тәүдә моңа да ышанасы килми: — Бабич дисең? Шәйхзадәме? Аны хәзер Оренбурдамы, кайда диләр бит... Башкорт хәрәкәтенә кушылган. Ай-һай, ялгышмыйсызмы? Монда «Госмания»дәге курста тагын икенче бер яшь Бабич бар. Ул да бик яхшы декламатор. Шуны әйтәләр булыр, дим. Үзем шулай сөйләнәм, үзем халыктан калышмыйм, кушылып шул якка агам. Чыннан да Бабич булса, миңа аны күрмичә калырга ярамый. Тирәмдә куанычлы, кызу тавышлар көчәя бара:

— Шәйхзадә, Шәйхзадә! Әнә үзен кызлар түгәрәккә электереп алдылар. Әнә әйләнә...

Залда Рим папасы уены бара. Уртада партадан ясалган биек тәхеттә балкып бик мәһабәт бер кыз белән папа утыра. Түгәрәк җырлый, әйләнә. Аяк очына басып үрелеп тә карыйм, Бабичны табалмыйм.

---

[1] Дарелмөгаллимат — мөгаллимәләр педучилищесы. Анда да бу вакыт җәйге курслар булып, Өфенең үзеннән һәм үз өязеннән җыелучылар өчен иде, ахрысы.

Тәхеттәге кыз кул чапты, түгәрәк туктады. Кыз:

— Шәйхзадә Бабич әфәнде! — дип боерды. Уртага бер гаскәри кеше чыкты. Бабич?.. Шунда гына мин аны яхшылап күрә һәм таный алдым. Хәтерем ялгышмаса, аның бу вакыттагы сурәте күңелемдә шушы рәвештәрәк калган:

Өстендә таушалганрак күгелҗем-көрән гимнастерка. Ялан баш. Чәче кыска итеп алынган. Билендә киң сары каеш. Наган. Ярым галифе чалбар, итекләре дә сары төстә иде бугай.

Ләкин ул хәзер мин моннан биш ел элек мәдрәсәдә күргән егет Шәйхзадә түгел: ул башын элеккечә бәйсез, югары тотмый, нәрсәгәдер гаепле сыман, нәрсә беләндер килешкән кебек, бераз аска игән; маңгае, белмим, аны ут шәүләсе шулай күрсәтәдерме, никтер, саргылт булып күренә. Буе да мин элек күргәнчә озын түгел, бераз кечерәйгән. Ихтимал, теге вакыт мин аны тәү күргәндә, үзем кечкенә булганга, ул миңа артык озын күренгәндер?.. Иңсә-җилкәләр дә элеккечә бик үк төз түгел, бераз чыгынкы сыман. Шул ук вакыт чырае бүген миңа, никтер, уйчан, хәтта бераз боек күренде.

Ул да түгел, аның бу бөкрәя төшеп торышында ниндидер, нәрсәгәдер күнгәнлек, тәкъдиренәмә баш салганлык, фатализм бар кебек иде. Бабичның үзе белән дә, шигырьләре һәм аның ашкынулы шагыйрьлек рухы белән дә бу, ничектер, бергә сыешмый торган ят хәл иде.

Кыз аңа декламация сөйләргә кушты. Мин хәзер бөтен игътибарым белән Бабичка текәлдем. Чөнки Бабич гаҗәп оста декламатор булып дан тота, миңа, үзем дә шагыйрь булган кешегә, аның декламация сөйләвен менә хәзер үз күзләрем белән күреп, үз колакларым белән ишетү көтелмәгән бәхет!

Куштылар — күнде. Менә ул башлады. Котбетдин бабайның үлгәч каберда Мөнкир-Нәкиргә ничек җавап бирүен сөйли. Ләкин ничек сөйли! Иң элек ул үзенең какча, ләкин бик тере хәрәкәтчән йөзенә кырыс һәм төксе бер кыяфәт чыгарды. Бер ягындарак басып торучы күмгәдер кашларын җыерып чытык кына карады да күкрәктән чыккан калын, ләкин эчке бер рухи тавыш белән аның үзенә генә бер хәбәр сөйләгән кебек болай дип сөйләп китте:

«Безнең авылда Котбетдин дигән бер бабай бар иде, син аны үзең дә күргәнең бар бугай? Шул үлеп китте бит. Бик яхшы кеше иде, мәрхүм. Җиназасын илтеп күмдек, җирләдек. Мине кабер башында аның теге дөньяда гүр фәрештәләренә ничек җавап бирүен тыңларга калдырдылар...» Шулай диде дә кисәк кенә аяк кагып, башын алга селкеп куйды, калын иреннәрен алга очлайтып кысып япты. Шуның белән йөзе бик җитди тартылып китте. Кырыйдагы баягы кешегә тагын бик җитди карап алды. Бабич булып түгел, кайдадыр шул вакыйганы сөйләүче авыл агае булып карап алды. Менә һич тә көтелмәгән бер метаморфоза! Ничек соң бу? Әле генә Шәйхзадә иде, хәзер синең алдыңда чынлап та кыямәт хәлләрен үз күзе белән күргән бер агай тора. Түгәрәктәгеләр бу кыяфәткә карап түзә алмыйча эче катып көлә башлады. Ләкин Бабичның көлү-елмаю ихтималы юк, әле ул кисәк кенә башын аска кага, әле ул үтергеч җитди бер кыяфәт белән туп-туры синең күзләреңә батырып карый, тагын алгы сүзенә күчә. Уен эш түгел, кеше сиңа теге дөнья хәлләрен сөйли...

«...Юк, Мөнкир фәрештә туктамый, тагын тегеңәр үзенең кабер соравын яудыра:

— Хак боерыгын тоттыңмы? — ди.

— Ат койрыгын? Тоттым, — диде Котбетдин бабай. — Менә кайчагында ат койрыгын тигәнәк сырып ала. Тотмыйча хәлең юк. Бүтәнчә ничек тазартасың аны?»

Тагын гөрр... иткән көлеш. Шуның белән бергә, Бабич тамашачыны кулдан да ычкындырмый, аңа паузаларда гына көләргә ирек биреп, үз тезгенендә тота.

Күрәсең, бу Шәйхзадә декламатор буларак, үзен башка бер сурәттә (образда) итеп күреп кенә калмыйча, бәлки каршындагы тамашачыларны да шул хикәяне кайдадыр хәзер башка бер җирдә тыңлаучы агай сурәтендә күрә, ягъни, аларны да үз хыял көче белән икенчегә әверелдерә... Монда ике катлы метаморфоза килеп чыга: сөйләүче Бабич та, аны тыңлаучы син дә башка бер ят кешегә әверелдегез... Шартлы рәвештә үзегезне шулай дип хис итәргә тиешсез.

Шәйхзадәнең сөйләгәндә кыяфәтенә бик тиз кырыс яки көлке төсләр бирә белүенә карап, кайбер җитдирәк кешеләр аны «балаганчы», «клоун» дип тә язып чыккан-

нар иде. Әлбәттә, шик тә юк, Шәйхзадә гаять тә көчле мимик, артист. Шулай булса да ул үз иҗатында нигездә шагыйрь-сатирик булганлыктан, аның бу йөз байлыгы рухи иҗат байлыгына һич тә каршы килми, киресенчә, бик туры килә. Ләкин Шәйхзадәнең шигырь уку остасы булып китүе кемнән дә булса күреп яки өйрәнеп эшләнгән бер эш түгел. Ул берниндп дә театр мәктәпләре күрмәгән. Бу тик аның үзенең нечкә мимикаларга гаять бай булган сизгер йөзен, тембрга бай яңгыравыклы тавышын үзлегеннән файдалана белүгә корылган осталык. Шуның белән бергә аның карап торуга шыксыз йөзе гаять зур рухи байлыгын, эчке матурлыгын ачып, тамашачыда зур мәхәббәт казана[1]. Аның бар осталыгы үзендә булган табигый сәләтләрен, үз талантын үзе ачу һәм шуны үзе үстерү юлы белән табылган. Шунлыктан да аның декламаторлыгы беркайда да күренмәгәнчә үзенчәлекле. Бу аның үз табышы, үз табигый байлыгы, бу үзешчән һәм ирекле, иҗади казаныш. Инде аның, мин күреп үткәнчә, үзен генә түгел, тыңлаучыларны да сурәткә әйләндереп, ике кат әверелеш тудыра алуына килсәк, бу аның хыял-фараз[2] көче гаять актив булганын, аның пластик һәм эластик табигате шуңа бик тиз җайланучан булганын күрсәтә торган бер факт диярга кирәк. Берәүләр моны көлү-көлдерү, балаганчылык диләр икән — дия бирсеннәр. Халык күңелен күтәрә торган сау көлдереш иҗат итү үзе генә дә зур мактауга лаеклы. Әмма инде халкыбызның әдәби сөйләм һәм шигырь телен үзлегеннән бу рәвештә сәнгатьчә үстерә һәм тамашачыда эстетик яңа тойгылар, яңа фикерләр тәрбия итә белүе өчен, халыкның Бабичны аеруча тәкъдир итүе бигрәк тә бушка түгел булып чыкты. Халык дигәннән монда тамашачы-публика һәм аның зәвыгы хакында гына түгел, Бабичны шагыйрь итеп тә яраткан киң халык турында бергә алып әйтелә бу сүз.

Менә ул сөйләп бетте, гөр итеп кул чабу китте. Кемдер аңа хәрби фуражкасын сузды. Ул аны кигәндә, йөзендә, күзендә елмаю сыман бер үткен нәрсә чагылып үтте. Ләкин үз-үзеннән бик үк канәгать калмаган булса кирәк, йөзе тагын җитдиләнде. Ул сыгылып, теге папа янындагы кызга нидер аңлата, ләкин халык аңа яңадан кул чаба, тегене сөйлә, моны сөйлә, мандолин! — дип заказ биреп кычкыра башладылар. Минем янымдагы баягы кызу егет кулларын югары күтәреп бик каты чаба, «бисс!» дип кычкыра, үзе шул араны миңа аның хакында тиз-тиз хәбәрләр әйтергә ашыга:

— Бүген әле ул бераз ни... ниерәк сөйләде. Ул монда Өфедән үтеп барышлый поезддан гына менгән, ди, китә, ди, каядыр Мияс ягына, ди. Күрәсе кешеләрем бар иде, шуңа сагынып кереп чыгуым дип әйтә, ди. Ашыга. Сагынмыйча соң... Дарелмөгаллимат аның үз йорты кебек бит.

Эш бу егет әйткәнчәме-түгелме, ләкин бу вакыт Бабич чыннан да янындагыларга карап, нәрсәдер әйтеп, ике кулын учлап күтәреп саубуллашу аңлатты. Йөзе тагын уйчанланды, иңсәсе чыга төште. Юк, тагын бер мәртәбә күрәм, Шәйхзадә мин моннан биш ел элек «Хәсәния» мәдрәсәсендә күргәнчә түгел. Анда теге яшьлек һавалыгы, бәйсезлеге юк; ничектер, ул нәрсәгәдер җигелгән кебек күренә иде.

Хәер, ул миңа бу кыяфәте белән бераз ят булып тоелса, мин дә хәзер аңа моннан биш ел элекке малай Нәкый булып күренә алмас идем, шәт.

—✦—

[1] Өфедә бер кичәдә уздырылган матурлык ярышында Шәйхзадәнең беренче приз алуы аның бу йөзе чыннан да зур рухи матурлыкка бай булуын, шуның белән халыкта да зур мәхәббәт казануын күрсәтә торган бер факт булып тора. Приз бирү өчен халык кул чабып сәхнәгә чыгарганда, аның халыкка йөзен күрсәтмичә, аркасы белән чыгып, гаять зур алкышлар астында шулай ук кереп китүләре дә үзенчәлекле бер хәл.

[2] Хыял-фараз — бу сүзне русчадагы **воображение** мәгънәсендә алдым. Югыйсә хыялның **фантазия** һәм **мечта** мәгънәләре дә бар, чуалтылмасын. Н. И.

# *Габделҗаббар Кандалыйның туууына 170 ел*

## КАНДАЛЫЙНЫҢ БИЛГЕСЕЗ ПОЭМАЛАРЫ

Габделҗаббар Кандалый әсәрләрен матбугатта беренче мәртәбә Каюм Насыйри чыгарган иде. Аның әсәрләрен беркадәре җыеп тәртипкә салу, шулардан чыгып шагыйрьнең катлаулы иҗатына гыйльми дөрес бәя бирү исә бары совет чорында гына мөмкин булды.

Шулай да Г. Кандалый иҗаты канәгатьләнерлек дәрәҗәдә өйрәнелгән дип әйтеп булмый әле. Шагыйрьнең 1960 елда чыккан җыентыгына язган кереш мәкаләсендә профессор Х. Госман Кандалый турында без аз беләбез, «эзләнү дәвам итәргә тиеш, шагыйрьнең әле без белмәгән әсәрләре табылыр», — дип язган иде. Галимнең сүзләре дөреска чыкты: күптән түгел Кандалыйның моңарчы билгесез ике зур поэмасы табылды. Шулай, Азия халыклары институтының Ленинград бүлегендә каталоглар карап утырганда, игътибарны бер карточкадагы: «Рисаләт-әл-иршад, Габделҗаббар Болгари», дигән сүзләр җәлеп итте. Кызыксынып китеп, китапны соратып алдым.

Болай карап торуга кечерәк кенә кульязма ул, һәр ике ягы да язылган 46 кәгазь — 92 бит. Узган гасырдан бирле В-318 номеры белән институтта сакланып яткан бу китапта Габделҗаббар Кандалыйның моңарчы билгесез ике поэмасы бирелгән. Берсе «Рисаләт-әл-иршад», ягъни нәсихәтләр китабы (1 а — 33 б битләр). Икенчесе исеме билгесез поэма — кыйсса (34 а — 46 б битләр).

Поэманың Кандалый әсәрләре булуы хакында текстта ук әйтелгән. «Бөтебдер Габделҗаббар, Нәсихәт һәрбере — на-җар» [1], диелә бер урында. Моннан тыш әсәрләрдә авторның «Я Габделҗаббар», «Әй фәкыйрь Габделҗаббар, аңла сән аны...», «Бу фәкыйре Габделҗаббари, зәгыйфь, бине Габделмәҗид Болгари, нәхиф» [2] (1 б, 32 б, 45 б, 34 а битләр) кебек үз-үзенә мөрәҗәгать итүләре дә еш очрый.

Габделҗаббарның әтисе чыннан да Габделмәҗит исемле булган (кара: Г. Кандалый. Шигырьләр. Казан. 1960 ел. 4, 7 битләр). Соңгы цитатадан исә әтисе Габделмәҗитнең «Болгари» дигән псевдоним-нисәбәсе булуы да ачыклана. Каталог төзүчеләр, күрәсең, «Болгари» псевдонимын шагыйрьнең үзенә карый дип уйлаганнар һәм шуннан чыгып карточкага «Габделҗаббар Болгари» дип язганнар.

Текстта автор исеме куелмаган хәлдә дә (бәхеткә ул бар), бу әсәрләрнең Г. Кандалыйныкы икәнлеген исбатлау артык кыен булмас иде. Кандалыйны башка шагыйрьләр белән бутавы читен бит! Шагыйрь иҗаты белән якыннан таныш укучылар моны алда китерелгән шигырь үрнәкләреннән дә күрерләр, шуңа да атрибуция мәсьәләләренә артык тукталмыйча, поэмаларның үзләренә күчәбез.

«Рисаләт-әл-иршад» поэмасының эчтәлеген, характерын әсәрнең йомгак өлешендә автор үзе болай аңлата:

> Нәсаих [3] әйләдем, әй яр,
> Синең өчен язып эшгар,
> Кабул итеп дотып юл кар [4]
> Ерак(к)а китмәгел, ная.
> Нәсихәтләр сиңа хуб бад [5],
> Боның исемене идарсең яд
> Атап «Рисаләт-әл-иршад»,
> Язылган ошбу дүрт пая. (33 б бит.)

Әйе, безнең алда дидактик әсәр. Ләкин моны борынгы татар әдәбиятында шактый киң таралган суфичылык дидактизмы белән бер үк нәрсә дип уйлау дөрес булмас иде. Дини мотивлардан файдаланып, укучысын «теге дөнья» белән кисәткәләсә дә, бирегә беренче планга дөньяви таләпләр куелган: укырга, укып белемле булырга; наданлык-җәһаләттән котылырга; аң-белем бу дөньяда да, «тегесендә»дә кирәк. Фикер бик ачык әйтелә:

---

[1] Н а-җ а р — боерык түгел.
[2] Н ә х и ф — көчсез, хәлсез («мескен» мәгънәсендә).
[3] Н ә с а и х — нәсихәтләр.
[4] Ю л к а р — юл кара (рифма өчен кыскарткан).
[5] Хуб бад — яхшы (файдалы) булсын.

Гыйлемлек хəслидə[1] улгыл,
Җəһалəтдин үзең йолгыл;
Ничек улса җəһəд кылгыл,
Ки, зинһар, калмагыл надан!

. . . . . . . . . .

Җəһалəтлек яманлыкдыр,
Бере аның наданлыкдыр,
Болардин һич яман юкдыр,
Гизəрсең гəр зəмине-асман[2].
(2 а.)

Менə шундый гомуми талəплəр куйгач, укучысын үз фикерлəренə тагын да ныграк ышандыру өчен, автор шактый кызык алымнар белəн эш итə. Ул кеше гомерен сабыйлык, егетлек, ирлек, картлык, үлем килү кебек дəверлəргə бүлə һəм һəр дəвердə кеше ничек яшəргə тиеш иде, лəкин чынлыкта ничегрəк яши икəнлеген образлар ярдəмендə сурəтлəп бирə. Фикерлəрен тагын бер фокуска җыеп, замандашларын аң-белемле булырга, күңел-иманны пакьларга өнди. Сабый чак əрəм узмасын һəм киләчəктə үкенмəс өчен яшьлектə укырга кирəк (2 б). Ə укымасаң, ди автор, хəлең «җаһиллəр локмасын капмак», ягъни «урак урмак, печəн чапмак» булыр, башың михнəттə гизəр (таныш мотивлар — элекке мəгълүм əсəрлəрендə дə шагыйрь хезмəткə шулай түбəнсетеп карый!)

Егетлек чагыңа да ышанып гафил булып ятма, ди шагыйрь, чөнки ул да бик тиз узачак:

Егетлек йил кеби үткəй,
Карылык физ-заман йиткəй,
Бакып күр, халеңне ниткəй,
Фасадатда үтеп рузгяр[3].
(4 а.)

Ə картлыгың — гомерең йомгагы; бармы шул турыда уйлап, тəүбə иткəнең, яки берəр изге эш эшлəгəнең! (21 а).

Поэмада «Егетлек вакытындагы нəсихəтлəр вə вəгазьлəр», «Кызларга улган нəсихəтлəр вə вəгазьлəр», «Яман хатыннар бəяны вə ирен рəнҗетүчелəр», «Явызлар берлə сөхбəт итмəслек», «Җан алынган вакытлар вə əҗəл килгəне» исемле, шулай ук бозык уйлылык, кеше хакын ашау, кеше белəн кешечə була белү шикелле темаларга багышланган егермедəн артык бүлек бар. Алар арасына кертелгəн автор чигенешлəре дə байтак кына. Һəрхəлдə, кешенең, дөньяга килеп, нинди дəверлəр узуы, «теге дөньяда» нəрсəлəр күрү ихтималлары һəммəсе эзлекле рəвештə, җентеклəп бəян ителгəн.

Дөнья һəм ахирəт мотивларын болай үреп, кеше алдына «гыйбрəт көзгесе» кую, аны белем-мəгърифəткə, саф əхлакка, туры иманга һəм гаделлеккə өндəү — дөнья əдəбиятында шактый очрый торган алым. Дантеның «Илаһи комедия»сен алыгыз. Безгə Иран əдəбиятыннан кергəн «Җөмҗөмə солтан» поэмасына игътибар итегез. Кыскасы, дини сюжетлар, илаһи мотивлар белəн файдаланып, бу «фани дөньяны» төзəтергə омтылу — феодализм идеологиясе хакимлек сөргəн чорлардагы шагыйрьлəргə, əдиплəргə бик хас бер күренеш. Бередə мəсьəлə алымда түгел, ə максатта. Максатны кем нəрсəдə күргəн — бу инде икенче проблема...

Югарыда китерелгəн өзеклəрдəн дə Кандалыйга хас сыйфатлар ачык күренə. Аның поэтик алымнарын, татар шигырендə ул тудырган яңа элементларны күрсəтерлек мисаллар «Рисалə»дə күп кенə:

Иген икмəк вирер икмəк, —
(2 б)

Сабыйлык төш кеби улыр,
Егетлек кош кеби улыр,
Карылык буш-тəһи улыр...
(2 б)

Хəмакать[4] арканын чолгап,
Йөгердең дөньяны болгап.
(22 а.)

Болар өстенə Кандалыйның халык иҗатыннан файдаланган образлары да шактый. Шул ук вакытта поэманың теле шактый чуар, архаик сүзлəр белəн тулы булуын да билгелəп узарга кирəк. Бу беркадəре аңлашыла да: «Рисалəт-əл-иршад» — китап теле белəн таныш мəдрəсə шəкертлəренə махсус адресланып язылган дидактик əсəр.

---

[1] Гыйлемлек хəслидə — гыйлем эзлəү юлында.
[2] Җирне, күкне гизсəң дə (бередə: үрле-кырлы сикерсəң дə мəгънəсендə).
[3] Бозыклыкта көннəр үтеп.
[4] Хəмакать — ахмаклык, интəклек.



Кулъязманың 33 б — 34 а битләре.

Беренче урында уку-мәгърифәт мәсьәләләрен куеп, башка сюжетларны апарга буйсындыру шуны күрсәтә. «Рисалә»дәге дини мотивларны да шуннан чыгып аңларга кирәк. Шагыйрьнең интим лирикасына, полемик рухтагы социаль шигырьләренә дөньявилык, бунтарьлык, дини тотнаксызлык хас булып, бу хәл иҗтимагый фикер үсеше белән тәшендерелсә, махсус дидактик әсәрләрдәге чикләнгәнлекләр дә Кандалыймулла, Кандалый-мөдәррискең үз җәмгыятендә тоткан урыны, бурычы белән аңлатылырга тиешле.

«Рисалә» турында сүзне бетерүдән элек, бер шөбһәне дә әйтәсе килә. Фикеребезчә, бу әсәрнең башыннан берничә строфасы югалган булырга тиеш. Гадәттә, шарык китапларында, шул исәптән татар кулъязмаларында да текст, кагыйдә буларак, беренче кәгазьнең икенче — эчке битеннән башлана. Безнең кулъязмада исә беренче кәгазьнең тышкы «а» битеннән үк:

Хода рәсуле Мөхәммәд
Һидаять шәмсе ул әхмәд...—

дип, текст башланып китә. Фасыл башы да, традицион «бисмилла»да юк. Менә шуңа күрә, беренче кәгазь өзелеп төшеп, аның белән бергә кереш өлештәге алланы мактауга багышланган юллары да югалган дип уйларга мөмкин.

Кулъязмадагы икенче әсәр исә тагы да күбрәк зыян күргән. Текст нибары 13 кәгазьдә (26 биттә) сакланып калган. Әсәрнең яртысыннан зуррак икенче өлеше югалган булырга тиеш. Бик кызганыч, чөнки бу «Рисалә» кебек дидактик поэма гына түгел, бәлки күп дәрәҗәдә катлаулы фәлсәфи дастан. Сюжеттан яңа сюжетлар үстерү шикелле күп тармаклы композиция, реаль вакыйгаларга риваятьләрне үреп бирү, аралап автор чигенешләрен кертү һәм гомумән эпик әсәрләргә хас салмак тон бу әсәрнең эчтәлеге, күләме турында нык уйларга мәҗбүр итә.

Керештән бер өзек китерик:

Хәмедлә тәслиядин фарыйг улдым[1],
Максадым сөйләмәгә шарыйг[2] улдым;
Бәгъзе яран фәкыйрө, бәгъзе нас[3]
Әйләделәр бу гарибдин илтимас[4]:

[1] Мәгънәсе: мактау белән тыныч торудан азат булдым.
[2] Шарыйг булу — юл башлаучы булу.
[3] Нас — кешеләр.
[4] Илтимас — үтенеч.

«Бер китабәт кыйссалардин әйләгел,
һәр нә гаҗаибдин улса сөйләгел;
Төрки улсын ул китабәте шәриф,
Самигың деле улыр ирде ләтиф» [1].
Бу фәкыйре Габделҗаббари зәгыйфь,
Бине Габделмәҗид Болгари, нәхиф,
Күрде кыйссадин бу фәкыйрь күп көтөб [2]
Деләюр язмага аны җәмгъ итеп,
Нә ишетдем һәм күрдем бән фәкыйрь
Язаем яхшы-ямандин кәсир [3]...

(34а.)

Шушы беренче юлларны укып та Кандалыйның нинди зур әсәргә тотынганлыгын беркадәре шәйләргә мөмкин. Борынгы дәвер татар поэзиясе һәм шәрык әдәбияты традицияләренең үстерелеше турында да фикер йөртеп була.

Әсәрдә борынгы Бәлх солтаны Ибраһимның, хакыйкать эзләү максаты белән, байлыгын, милкен ташлап, ил гизеп китүе, күп маҗаралардан соң хакимлеге белән танылган гарәп хәлифе һарун әр-Рәшид белән очрашуы, фәлсәфи мәсьәләләр буенча бәхәсләшүе, аннары тагын әллә нихәтле маҗаралар кичерә-кичерә Йәмән мәмләкәтенә барып чыгуы, үзе кебек үк «хакыйкать эзләүче» дәрвишләр белән очрашып йөрүләре сурәтләнә. Шунысы игътибарга лаек, биредә «тәгълим касды илән» Болгар җиреннән чыккан б е р ә ү дә очрый.

Вакыйгалар, югарыда искәртелгәнчә, авторның фәлсәфи чигенешләре — «мөнәҗәтләр» белән дә бизәкләнә. Кызганычка каршы, әсәрнең азагы югалган. Шулай да, шагыйрьнең төп фәлсәфәләреннән берсе, уебызча:

Әй, берадәр, тәрке гыйзз вә җаһ ит,
һәм сакынгыл — тәрке карбе шаһ ит;
Карбе солтан уладыр җанга бәла,
Улмагыл боның белән сән мөбтәля [4], —

дигән, фикер тирәсендә оеша сыман [43 а]. Чөнки Ибраһимның власть һәм байлыктан баш тартуы, һарун әр-Рәшид, тәкәббер казый һәм башкалар белән әңгәмә-бәхәсләре шул фикер тирәсендә йөри. Пәйгамбәрләр тормышына мерәҗәгать итүе белән дә автор шундый ук социаль һәм фәлсәфи карашларын үткәрергә чара эзли сыман. Мәсәлән, Ибраһим тәкәббер казый белән бәхәсләшеп: әгәр мал-мөлкәтле кеше генә ихтирамга лаек икән, борынгы пәйгамбәрләргә «яр улыр ирде ки Фиргавен вә Карун», — ди [40 а]. Дөрес, мондый мотивлар шәрык халыклары әдәбиятларында очраштыргалый. Ләкин безнең өчен аларның К а н д а л ы й а ң ы а ш а нинди төскә төрелеп, нинди тенденция белән чыгуын билгеләү әһәмиятле булыр иде. Биредә дә тарихи конкретлыкны исәпкә алып, тарихи эволюцияне, аның сәбәпләрен эзләргә кирәк. Әсәр өзек килеш кенә булса да, анда фикер йөртерлек материал бар, һәм ул Кандалый узган катлаулы иҗат юлын дәверләргә бүлеп киң планда өйрәнер өчен әдәбиятчыларыбызга шактый зур мөмкинлекләр бирә. Без биредә кулъязма турында хәбәр итү белән генә чикләндек.

Ниһаять, соңгы мәсьәләгә тукталыйк. Яңа табылган кулъязманың кәгазендә «1816» — ел дигән су билгесе (филигрань) бар. Димәк, кәгазь фабрикадан чыгып, кулъязма булып өлгергәнче 3—4 ел узып китсә дә, бу нөсхә 1820 елдан да соң күчерелмәгән дип исәпләргә кирәк. Ә Г. Кандалый 1787 елны туган, ягъни күчермә язылган чорда аңар 20—23 яшь тирәсе була. Шулай итеп, безнең алда яшь, мәгәр, чын шигъри осталык биеклегенә ирешмәсә дә, танылып өлгергән («и л т и м а с ә й л ә ү»!) Кандалыйның зур күләмле әсәрләре икән. Бу хәл яңа кулъязманың әһәмиятен бермә-бер арттыра.

Кулъязма күчермәме, әллә автографмы дигән сорауның куелуы да бик ихтимал. Кандалыйның яшь чагындагы почеркын (ә почерк үзгәрүчән була) белмәвем сәбәпле, хәзергә бер тәгаен фикер әйтеп булмас. Автограф табылган булса — бик кызыклы; ләкин мин аның гади шәкертләрнең берсе эшләгән күчермә булуын теләр идем (орфографиядәге кайбер характерлы хаталар шулай уйларга мөмкинлек бирә). Автограф булган хәлдә, хикмәтле очраклык кына ярдәм итмәсә, әсәрнең башка нөсхәләрен табуга ышаныч аз; күчермә булса, киләчәк эзләнүләргә өмет бағларга урын кала. Ә бабаларыбыз шәкерт чакларында, гәрчә зур белемгә куллары җитмәсә дә, китап күчереп язарга бик яратканнар. Шаять бу әсәр дә бер генә нөсхәдә калмагандыр. Яшь Кандалый үзе дә шушы ике поэманы язуы белән генә чикләнмәгәндер дип ышанасы килә.

**М, ГОСМАНОВ.**

---

[1] Мәгънәсе: Тыңлаучыларның күңеле хуш булыр иде.
[2] К ө т ө б — китаплар.
[3] К ә с и р — күп.
[4] Мәгънәсе: «Әй туган, шан-шәрәфне, югары дәрәҗәне ташла, һәм үзең теләп шаһларга якынлыктан кач, (чөнки) солтаннарга якынлык — җанга бәла, андый бәладән котыл».

## сәнгать кешеләре

*Коткарды Ленин*
*Диярләр алар,*
*Әгәр берәрсе*
*Юлда сораса...*

***Сибгат Хәким.***

*Владимир Воронов*

# МӘҢГЕЛЕК ЯШЬЛЕК

*(З. Бәйрәшеваның иҗат портреты)*

Казан консерваториясенә кергәләп йөргәнегез булса, түгәрәк йөзле, күе кара чәчле бу сөйкемле ханымга игътибар итми калмагансыздыр. Җыйнак гәүдәле ул ханым житез-җиңел адымнар белән ашкынып-дәртләнеп янгызыздан үтеп киткәндә, ихтимал, аның кызларча җиңел хәрәкәтләренә карап, сокланып торган чакларыгыз да булгандыр. Ул алтмышның өске ягына чыккандыр инде, диган уй башыгызга да килмәгәндер.

Татар җырчылары арасыннан беренчеләрдән булып махсус югары белем алган, беренче татар операларында төп рольләрне башкарган танылган җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы, Казан дәүләт консерваториясенең профессоры Зәһрә ханым Бәйрәшева әнә шул инде. Узган елның октябрь аенда республикабыз җәмәгатьчелеге аның 60 еллыгын билгеләп үтте.



Татар хатыны — профессор, сәнгать профессоры! Бик гыйбрәтле хәл бу. Кем кешә иткән? Тормышның нинди шифалы җилләре аны олы юлга чыгарышкан, гади татар кызын профессор дәрәҗәсенә күтәргән? Мин еш кына әнә шул турыда уйланам. Зәһрә Бәйрәшеваның бай тормыш юлын күз алдына китерергә, аны зур сәнгать дөньясына алып килгән сукмакларны ачыкларга тырышам.

Сукмаклар исә ерактан, Касыйм өязендәге бәләкәй генә Җаубиш авылыннан башлана.

* * *

Табанак, ярлы өйнең тонык тәрәзәләре аша урамга утлы күмердәй очкынланып ялтырап торган коңгырт кара күзләр төбәлгән. Аларда гаҗәпләнү һәм чиксез соклану. Һәр бала кебек, аның да тынчу һавалы, ярым караңгы бу өйдән тизрәк урамга чыгып йөгерәсе, тәрәзә аша серле һәм кызык булып күренгән әйберләрнең һәм-

мәсен тотып-кабып карыйсы килә. Тик чыгармыйлар. Син әле кечкенә, Зөһрә кызым, егылырсың, диләр. Бераз үсә төш, диләр...

Элекке заманда гаиләдә кыз баланы өнәп бетермиләр иде, дип сөйлиләр. Елтыр күзле шушы кызы тугач, нинди хисләр кичерде икән Гәрәй абзый? «Малай көткән идем, булмады, бирмәде ходай!» дип, эчтән генә уфтанып-көрсенеп йөрдеме икән?.. Кем белә, бәлки, киресенчә, шатлангандыр, куанычы эченә сыймыйча: «Тере бала булырга охшаган, бәхете белән үсә генә күрсен инде», дип сөенеп бетә алмагандыр әле.

Ә Зөһрә, чыннан да, бик тере, әти-әнисенә мәшәкать артыннан мәшәкать ясап торучы, тиктормас бала булып үсә. Әнисе бәләкәй кызының бөтен кыланышларына түзә, тик бер яман гадәтен һич кенә гафу итә алмый. Башка бөтен шуклыклары өстенә, ул тагын, кече яшьтән үк, җыр-биюгә һәвәс була. «Йортның бәрәкәтен качырасың, шайтаннар иялəштерәсең», дип әнисе аны орышып та карый: әллә ни файдасы гына тими. Кем белә, уңай шартлар булганда, бала күңеленә сабый чакта ук салынган шушы орлык — җырга, музыкага хирeслек — үсеп, көчәеп тә киткән булыр иде. Әмма тиздән гаилә өстенә зур кайгы килә: Зөһрәгә 6 яшь тулганда Гәрәй абзый үлә. Нәни кыз әтисез, семья туйдыручысыз кала. Гамьсез бала чак артык кыска гомерле булып чыга.

Алты баланы туйдырып, киендереп барыр өчен, әнисе байларга ялланырга, таңнан төнгә кадәр ал-ялны белми эшләргә мәҗбүр була. Әнисе җилкәсенә төшкән авыр йөкнең күпмесендер хәзер инде кечкенә Зөһрә дә сөйрәшә. Бер-бер артлы еллар уза, торган саен тормыш кыенлаша. Аптырагач, әнисе Вологда шәһәрендәге туганнары янына күчеп китәргә уйлый: «Бергә-бергә җиңелрәк булмасмы, аз гына булса да тормышлар рәтләнмәсме?..» Ләкин, күченеп килүгә, үзе тиф белән авырый башлый, озакламый үлеп тә китә. Унбер яшьлек Зөһрә әнисез дә кала.

Зөһрә Бәйрәшеваның Октябрьдан соңгы тормышы шактый кызыклы һәм гыйбрәтле. Очраклы хәлләр, һич тә уйламаганда юлыккан мәрхәмәтле кешеләр юллар чатында аптырап калган ятимә кызны упкыннарга егылып төшеп имгәнүдән саклап калалар, аңа якты сукмаклар аша олы юлга чыгарга булышалар.

1920 ел. Кояшлы, матур, җәйге җылы көн. Шәһәрнең кеше сирәк йөри торган, тыныч-тын урамнарының берсендә, тәрәзәләре түбәнә кадәр каерып ачып куелган агач йортта, 14—15 яшьлек үсмер кыз, җырлый-җырлый, рамнар юа. Ул эш белән шулкадәр мавыккан, тәрәз турыларында басып, байтактан бирле үзенә карап торучы пөхтә киемле чибәр ханымны да күрми. Ниһаять, озак кына кызыксынып-күзәтеп торганнан соң әлеге ханым түзми, дәшергә була:

— Чибәр кыз, исемең ничек?

Кыз шунда гына күтәрелеп карый, каршында елмаеп басып торган ят апаны күреп, чиядәй кызарып чыга:

— Зөһрә...

— Зөһрә?.. Исемең дә, тавышың кебек үк, матур икән, сеңелем. Мәктәпкә йөрисеңме соң?

— Беренче хезмәт мәктәбендә укыйм...

Ят апа бераз уйланып тора, аннан тагын оялчан кызның күзләренә карый:

— Ә җырларга өйрәнәсең киләме?

Тартыныбрак, сөйләшергә уңайсызланыбрак торган Зөһрә, бу сүзләрне ишеткәч, ачылып китә.

— Әйе, — ди ул балаларча куанып, — минем б-и-к артис буласым килә.

— Алайса, иртәгә музыка мәктәбенә кил, яме.

Мариинск театрының танылган җырчысы, тәҗрибәле педагог Л. Ф. Нордштрем белән Зөһрә Бәйрәшева әнә шулай таныша. Бер ел буена ул музыка мәктәбенә йөри, рус композиторларының һәм Көнбатыш Европа классикларының күп кенә музыкаль әсәрләрен башкарырга өйрәнә. Ләкин озакламый Нордштрем Вологдадан Петроградка кайтып китә, башланган эш ярты юлда тукталып кала. Тормыш яшь кызны, сәнгать дөньясыннан аерып алып, бүтән сукмаклар белән атларга мәҗбүр итә.

Тагын берничә ел вакыт уза. Зөһрә беренче баскыч мәктәпне бетерә, икенче баскыч мәктәпкә күчә. Анысын да уңышлы тәмамлый һәм, укуын дәвам итү теләге белән, 1924 елда Казанга килә, педагогия институтының тел бүлегенә укырга керә.

Шулай студентлык еллары башлана. Ул бик тырышып, күңел биреп фән нигезләрен үзләштерә, әйбәт тәрбияче, югары белемле педагог булырга әзерләнә. Ләкин күңеленең кайсыдыр почмагында сүнми дә, сүрелми дә торган тагын бер хис яши. Бала чакта ук кузгалган шул хис һаман тынгылык бирми, аны гел иләсләндереп, җилкендереп тора. Ахыр килеп, шул хис аны үзешчән сәнгатьнең актив бер вәкиле итә. Белмим, институтта ул вакытларда Зөһрә катнашмаган, ул чыгыш ясамаган кичә яки концерт булдымы икән? Мөгаен, юктыр.

Концертларның берсендә Зөһрә Казан Консерватория музыка техникумының директоры А. А. Литвинов белән очраша. Шушы очрашу аның язмышын хәл итә.

Сопрано тавышлы татар кызы башкарган җырлар, күрәсең, Литвиновка бик охшаганнардыр. Концерттан соң ук ул Зөһрәне эзләп таба һәм икеләнергә урын калдырмыйча:

— Мондый тавышны әрәм итәргә ярамый! Безгә күч, — ди.

Шулай, көтелмәгәндә очраган әйбәт кешеләр ярдәмендә Зөһрә Бәйрәшева яңадан үзе яраткан сәнгать дөньясына кайта.

Техникумга күчкәч тә, бәхет дигәнең Бәйрәшева тирәсендәрәк йөри: аны Татарстанның атказанган артисткасы Екатерина Георгиевна Ковелькова [1] классына билгелиләр. Техникумдагы беренче дәрес мондыйрак бер кисәтү белән башлана:

— Җырчы-артист хезмәте турында, ни өчендер, гаҗәеп беркатлы һәм җиңел караш яшәп килә, — ди Екатерина Георгиевна үзенең яңа укучысына. — Янәсе, җырчы булыр өчен укып азапланасы юк, тавышың булса, шул җиткән... Аң бул, — дип өсти тәҗрибәле педагог, — табигый тавышы, музыкаль сәләте булмаган кешедән, аны гомер буе укытсаң да, юньле җырчы да, музыкант та чыкмаячак. Әмма булган сәләтне дә үстерә һәм камилләштерә барырга, табигать тарафыннан бирелгән тавышың белән идарә итә, иркен файдалана белергә өйрәнергә кирәк. Моның өчен ифрат зур ихтыяр көче, тырышлык сорала. Яхшы җырчы булыр өчен еллар, дистә еллар буенча өзлексез күнегүләр алып барырга, гомер буе э ш л ә р г ә кирәк.

Шуннан китә күнегүләр... Глинка һәм Варламов язган күнегүләр, Зейдлер һәм Конконе вокализлары. Берсен башкарганда музыкаль нәфислек чаралары игътибар үзәгендә торса, икенчесендә тын алуга басым ясарга кирәк, өченчесендә — дикциягә. Бераз соңрак халык җырларын, татар, рус, итальян композиторлары әсәрләрен өйрәнү... Тырышлык бушка китми: җырчының тавышы көрәя, тагын да матуррак яңгыраш ала. Һәм, Консерватория музыка техникумына күчеп бер ел укуга, Зөһрә Бәйрәшеваны беренче татар операсында төп партияне башкарырга чакыралар.

* * *

Татар совет музыка сәнгатенең бүгенге дәрәҗәсеннән торып хөкем йөрткәндә, «Сания» операсы, ихтимал, алай үлеп искитәрлек әсәр дә булып тоелмас. Әмма ул вакытта, моннан 40 ел элек — бөтенләй башка хәл иде. Безнең хәзер дистәләрчә опера-балет әсәрләребез, махсус белем алган бик күп талантлы артистларыбыз, бөтен союзга данлыклы театрыбыз бар. Ул вакытта боларның берсе дә булмаган. Алай гына да түгел, күпләр бу эшкә бөтенләй ышанмаган яки шикләнеп караган. С. Габәши, В. Виноградов һәм Г. Әлмөхәммәтовларның шундый шартларда опера язарга керешүләре кыю омтылыш, иҗтимагый-политик әһәмияткә ия булган зур вакыйга итеп каршы алына. Операны сәхнәгә чыгарышуда бөтен җәмәгатьчелек катнаша. Һәм Татарстан республикасының 5 еллык бәйрәме якынлашып килгән көннәрдә Казан урамнары тиздән беренче милли опера куелачагын хәбәр иткән зур-зур игъланнар белән бизәлә.

Бераз алгарак китеп, шулкадәресен дә әйтик, беренче милли опера куелган көннәрдә шәһәр бәйрәм төсен ала. «Сания»нең даны еракларга тарала. Минем алда шул елларда рус, татар, башкорт телләрендә, СССР территориясендә яшәүче башка тугандаш халыклар телләрендә чыккан газета-журналлар, музыка сәнгате мәсьәләлә-

---

[1] Е. Г. Ковелькова (1876—1964) — 30 елдан артык иҗебезнең иң зур театр сәхнәләрендә төп партияләрне башкарып килгән, Шаляпин, Собинов кебек җырчылар белән уйнау бәхетенә ирешкән талантлы артистка һәм зур педагог иде; М. Рахманкулова, Г. Кайбицкая, Ю. Гыйззәтуллин, башка бик күпләр — аның укучылары. Ул Казанда туып, Казанда үлде.



Немец журналында «Сания» операсына багышланган бит.

рен өйрәнүгә багышланган төрле җыентыклар. Аларның һәрберсендә диярлек «Сания» операсы, татар совет музыка сәнгате ирешкән уңышлар турында сөйләүче мәкаләләр басылган. Арада чит илләрдә чыкканнары да очрый. Менә «Zede woche musik» исемле немец телендәге журнал. Аның 1925 ел 19 декабрьда чыккан санында «Сания» операсыннан арияләр, аерым өзекләр басылган, төп рольләрне башкаручыларның рәсемнәре урнаштырылган. Яки икенче бер басманы, ерак Италиядә чыга торган «Leuropa Orientale» исемле журналны алыйк. Бу журналда да татар музыкасына һәм «Сания» операсына багышланган зур гына мәкалә бар. Ихтимал, шундыйрак материаллар башка илләрнең газета-журналларында да басылгандыр...

Заманында беренче татар операсы шундый зур уңыш казанган икән, билгеле, бу данны яулашуда, әсәрнең авторлары белән бергә, спектакльдә төп партияләрне башкарган җырчыларның да, шуп исәптән Бәйрәшеваның да, мәгълүм өлеше бар.

Ул көннәрне искә төшереп, Зәһрә ханым үзе болай сөйли: «Композиторлар тарафыннан Сания партиясе лирик-колоратур сопрано тавышлы җырчыга исәпләнеп язылган иде. Минем кебек лирик-драматик сопрано тавышлы кеше өчен, билгеле, бу тональность югарырак. Нишлисең, аптырагач, дирижер А. А. Литвинов миңа партияне бераз түбәнрәк тональностьта, ягъни үз тавышым белән җырларга рөхсәт иткән иде.

Бик нык каушаганга күрәдер инде, премьера көнне сәхнәгә чыгуга дирижерның алдан — репетицияләр вакытында әйткән бөтен киңәшләре хәтердән чыккан. Һәм мин Саниянең беренче ариясен авторлар ничек язган булса, шул ук тональностьта башлап та киткәнмен. Җитмәсә, соңгы куплетның ахыргы сүзләре үк онытылган.

Беренче күренеш бетеп, ял итәргә утырган гына идем, арттан, йөгереп диярлек, дирижер килеп керде. Аның шул вакыттагы кыяфәтен күрсәгез иде. Кызарынган-бүртенгән, күзләре шундый усал ялтырый. Үзе өзлексез йөренә, үзе кулындагы бәләкәй таягы белән юлында очраган әле бер нәрсәгә, әле икенче әйбергә бәреп ала. Китте тезеп минем ялгышларны... Түзеп кенә тор. Орышты, орышты да, дирижерлык итә торган әлеге бәләкәй таягы шартлап сынгач, бераз тынычланып калгандай булды. Әллә шушы әрләү килеште инде? Белмим, ни булгандыр: калган күренешләрдә каушау да кимеде, тавыш та әйбәтрәк чыкты шикелле.

Бүгенгедәй хәтеремдә. Икенче күренеш тәмамланып, соңгы аккордлар тынарга да өлгермәде, тамаша залыннан чәчәк бәйләмнәре яварга тотынды. Бөтен сәхнә чәчәкләр белән күмелде. Букетларның күбесе гади кыр чәчәкләреннән иде бугай. Спектакль тәмамлангач, бөтенебезне зурлап, кабат-кабат чакырып котладылар, кыйммәтле бүләкләр бирделәр. Мине бриллиант кашлы йөзек һәм көмеш самовар белән бүләкләгәннәр иде...»

Зәһрә Бәйрәшеваның II—III курсларда укыган чордагы тормышы телгә алып сөйләрлек вакыйгаларга бай түгел. «Сания» операсында уңышлы чыгыш ясаганнан соң, техникумда аңа махсус стипендия билгелиләр; яшь җырчының тормыш шарт-

лары бераз рәтләнеп китә. Бер җаена төшенеп алгач, һәркөн кабатлана торган исәпсез-хисапсыз күнегүләр дә артык куркытмый башлый. Ике ел вакыт эчендә Зөһрә күп кенә кызыклы музыкаль әсәрләр өйрәнә, Вердиның «Аида», Чайковскийның «Евгений Онегин», Даргомыжскийның «Су кызы» операларыннан аерым өзекләр әзерли, җырлау техникасын камилләштерү һәм тавыш диапазонын киңәйтү юнәлешендә җитди уңышларга ирешә.

Өченче курс бетеп, җәйге каникуллар башлангач, Зөһрә, апны апасы янында уздыру теләге белән, Мәскәүгә китә. Биредә ул башкала театрларының күп кенә спектакльләрен карый, танылган җырчыларны тыңлый. Шулай йөри торгач, үз бәхетен сынап карарга була. Байрәшеваны зур театр хорында, Мәскәү оперетта театрында, К. С. Станиславский һәм В. И. Немирович-Данченко исемендәге музыка театрында тыңлыйлар. Оперетта театры җырчысы Г. М. Ярон аңа Мәскәү консерваториясенә күчәргә тәкъдим ясый, Зөһрә риза була. Һәм Казан музыка техникумыннан килгән җырчы кыз, авыр имтихан тотып, зур конкурс үтеп, башкала консерваториясенә кабул ителә.

* * *

Артистлар белән без, күбрәк, спектакльләр, концертлар вакытында очрашабыз. Гадәттә, ул спектакль-концертлар күңелле бәйрам төсен ала: артистларга кул чабалар, аларны алкышлыйлар, иң яхшыларына букетлар бирәләр. Моңа карап, артист тормышы бик җиңел, күңелле икән, дип уйлау — хата булыр иде. Әйе, тамашачы өчен алар көн дә бәйрам ясыйлар, ләкин үз тормышлары бәйрәмнәрдән генә тормый. Яхшы җырчы, яхшы артист булып җитешү өчен күп тир түгәргә кирәк. Мәскәү консерваториясенә кереп укый башлау белән Зөһрә Байрәшева тагын бер кабат нә шуңа ышана.

Казанда ук башланган күнегүләр, практик дәресләр, лекцияләр аның күп вакытын ала. Укытучылар да башка, таләп тә зуррак. Турыдан-туры үз өлкәңә караган әйберләр генә укытылса, тагын бер хәер иде. Юк бит, алай гына түгел. Тарих һәм әдәбият та, чит тел дә, тагын әллә никадәр башка фәннәр дә кирә. Һәммәсен укырга, һәрберсен үзләштереп барырга кирәк. Юкса, стипендия бирерләр дип өметләнмә.

Аның каравы, Байрәшевага данлары бөтен илгә таралган җырчылар, атаклы педагоглар кулында белем алу бәхете тия. Алар арасында В. Н. Петрова-Званцева, Л. Я. Шор-Плотникова, П. А. Ламм, З. П. Лодий кебек профессорлар, СССРның халык артистлары Н. С. Голованов, Л. В. Баратов кебек мәшһүр дирижерлар һәм режиссерлар бар. Шул кешеләр ярдәме белән гади татар кызы сәнгать серләренә төшенә, һәрьяклап әзерлекле белгеч булып җитешә, консерватория тәмамлый.



Байрәшева Рәйхан ролендә.

1931 елда Зөһрә Байрәшева Казанга кайта. Шул елдан башлап аның тормышы, иҗат эшчәнлеге аерылгысыз рәвештә татар совет музыка сәнгатенең үсү, камилләшү тарихы белән бәйләнгән.

Ул радиокомитетта җырлый, концерт бригадаларында катнаша. Мо-

царт, Бетховен, Шуберт, Чайковский, Рахманинов, Белый әсәрләрен татар телендә башкара. Ул елларда Татарстан радиосы, даими рәвештә, дингә каршы махсус тапшырулар бирен бара. Радиокомитет солисткасы буларак, билгеле, Зөһрә Бәйрәшева да бу эштән читтә кала алмый.

Мәгълүм булганча, 1934 елда, төзеләчәк опера театрына кадрлар һәм репертуар хәзерләү нияте белән, Мәскәү консерваториясе каршында татар студиясе оештырыла. Башка талантлы яшьләр: җырчылар, композиторлар һәм шагыйрьләр белән бергә З. Бәйрәшева да әлеге студиягә җибәрелә. Студия укучыларын тәрбияләү эшенә башкаланың зур сәнгать белгечләре җәлеп ителә. Бәйрәшева, мәсәлән, Н. Райский, М. Мирзоева, А. Доливо кебек җырчы-профессорлардан дәрес ала. А. Доливо аны романслар, халык көйләрен җырларга, М. Мирзоева рус композиторларының ике җырчы өчен язылган әсәрләрен башкарырга өйрәтә. Профессор Н. Райский ярдәмә белән Бәйрәшева зур концерт программасы төзи. Рус һәм татар композиторлары операларыннан аерым партияләр әзерли. Студияне тәмамлап чыкканда, аңа түбәндәге сүзләр язылган диплом бирелә: «Махсус комиссия Зөһрә Гарәй кызы Бәйрәшеваны опера сәхнәсендә беренче пландагы партияләрне башкарырга сәләтле җырчы дип таба».

* * *

*«Кичә Татарстан республикасы культура фронтында ирешкән зур җиңү бәйрәмен билгеләп үтте. Яшь композитор Җиһановның «Качкын» операсы белән беренче татар опера театры ачылды».*
*«Правда» газетасы. 1939 ел. 18 июнь.*

Еракта дәртле, көчле җыр ишетелә. Бу — Булат, Бикә алпавытның Пугачев явына качып киткән колы туган якларына кайтып килә.

Ул да түгел, дәртле музыка хәвефле, драматик авазлар белән алмашына. Киемнәре ертылып, чәчләре тузгып беткән бер кыз йөгереп чыга. Аның күзләрендә өметсезлек, дөньядан туйганлык. Көтеп-көтеп тә кайтмагач, сөйгәне Булатның исәнсау булуына өмет өзгән, алпавыт утарында күргән җәбер-золымнарга, мыскыл-хурлауларга түзәр хәле калмаган Рәйхан, елгага ташланып, үз-үзен һәлак итмәкче. Шунда ул Булат белән очраша:

*Сине көттем мин таңда су өсте*
*Кояш чыгуын көткән чагында.*
*Сине көттем мин күк читенә эңгер*
*Соңгы нурын, соңгы нурын сипкән чагында.*



«Качкын» премьерасыннан соң. Икенче рәттә сулдан беренче З. Бәйрәшева.

Кызның җырында Булаты кайтуга чиксез сөенү дә, авыр, газаплы тормыштан зарлану да, алпавыт Бикәгә, аның канэчкеч кешеләренә нәфрәт хисләре дә. Рәйхан-Бәйрәшеваның күңелләрне тетрәтерлек җырын хуплап, залда озакка сузылган көчле алкышлар яңгырый.

Менә тагын бер күренеш. Алпавыт Бикәнең кешеләре Булатны эзли. Халыкны бунт күтәрергә, Пугачев явына кушылырга котыртучы егетне каты җәза көтә. Шуны яхшы аңлап-белеп торган халык аның кайда яшеренүен әйтми. Куркытып та, ялап та эш чыгара алмагач, Бикәнең солдатлары Рәйханны тотып бәйлиләр. Безнең алда инде сөйгәне өчен теләсә нинди җәзага да түзәргә әзер, тәвәккәл һәм батыр йөрәкле Рәйхан-Бәйрәшева. Изге көрәш юлында ул һәлак була, әмма дошманнары алдында тез чүкми...

Татар опера һәм балет театрында эшләү дәверендә З. Бәйрәшева төрлесе төрле характердагы, төрле пландагы дистәләрчә образлар иҗат итте: Бибисара (Н. Җиһанов. Ирек), Саҗидә (Н. Җиһанов. Илдар), Аембикә (Н. Җиһанов. Түләк), Маргарита (Гуно. Фауст), Татьяна (Чайковский. Евгений Онегин), Чио-Чио-Сан (Пуччини. Чио-Чио-Сан). Бу һәм башка күп партияләрне татар сәхнәсендә беренче мәртәбә Бәйрәшева башкарды. Тагын әнә шул ягы белән дә аның исеме татар музыка сәнгате тарихына кереп калган. Ул вакытларда чыккан газета-журналларда басылган мәкаләләргә һәм рецензияләргә караганда, Бәйрәшева зур эмоциональ тәэсир көченә ия, тамашачыны ышандырырлык һәм истә калырлык образлар тудыра алган. Шулкадәресен дә истән чыгарырга ярамый: җырчы иҗатына уңай бәя биргән ул рецензияләрнең күбесе Муса Җәлил, Гадел Кутуй кебек музыка сәнгатен тирән аңлаучы, югары зәвыклы кешеләр тарафыннан язылган.

Тамашачы күңелендә озак вакытлар сакланырлык образлар тудыру өчен исә җырлый белү, тавыш кына җитми. Моның өчен теге яки бу әсәрдә сурәтләнгән тормышны яхшы белергә, үзең башкарачак образның рухына төшенергә, композиторның бу образ аша тамашачыга әйтергә теләгән уйларын дөрес сиземләргә, музыкаль әсәрне бер бөтен итеп аңлый белергә кирәк. Болар гына да аз. Кешенең күңелен тетрәтерлек һәм истә калырлык, табигый һәм тормышчан образ иту өчен, музыкаль сәләт өстенә, зур актерлык сәләте дә сорала. Артистлык темпераменты,



З. Бәйрәшева бер төркем артистлар, язучылар арасында.

югары эчке культурага ия булу, табигый сәләт һәм зур тырышлык Зөһрә Бәйрәшеваны татар сәхнәсенең күренекле опера җырчылары рәтенә чыгара.

1944 елның 15 июнендә, татар сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен, Зөһрә Гәрәй кызы Бәйрәшевага «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелә.

* * *

1947 елда Бәйрәшеваны камера җыр классы алып барырга Казан консерваториясенә укытучы итеп чакыралар. Тагын бер елдан ул бәтенләй укытучылык эшенә күчә. Менә егерме ел инде Бәйрәшева шушы тынгысыз һәм җаваплы хезмәтне башкарып килә.

Укытучылар башкарган авыр хезмәтнең күләмен һәм әһәмиятен нинди критерийлар, нинди үлчәүләр белән билгеләп була икән? Укытып чыгарган балаларының соңыннан тормышыбызда алган урыннары, даннары беләнме? Бәйрәшевада укып чыккан 100 дән артык җырчы арасында андыйлар бик күп. Мәскәүдә һәм Ленинградта, Казанда һәм Бакуда, Уфада һәм Чабаксарда, Чиләбедә һәм Ульяновскида, Ижевскида һәм Йошкар-Олада, илебезнең башка күп шәһәрләрендә заманында Бәйрәшевада белем алган җырчылар эшли. Аларның байтагы хәзер даннары бөтен илгә мәгълүм булган мактаулы җырчылар санала.

РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы З. Хисмәтуллина, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган артисты Б. Апполонов, ТАССРның халык артисткалары Г. Сәйфуллина һәм Р. Билялова, ТАССРның атказанган артистлары И. Ишбүлэков, Иосыф Гыйззәтуллин, М. Пантюшин, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең танылган җырчылары И. Шакиров, Э. Җәләлетдинов, К. Басыйров һәм башкалар Зөһрә Бәйрәшевада укыдылар.

Бәлки, җыр укытучысының хезмәтен укучыларының культура, зәвык дәрәҗәсе белән билгеләргәдер?.. Бу яктан да Зөһрә Бәйрәшеваның йөзе ак. Булачак артистларны ул түбән сортлы әсәрләр белән мавыкмаска, репертуар сайлауда таләпчән һәм талымлы булырга өйрәтергә тырышты.

Һәр яктан килгән, бүгенге тормышыбызга лаек булырдай чын кешеләр үстерү, сәнгатькә гашыйк артистлар тәрбияләү — сүз дә юк — ифрат кыен вазифа. Шуны тирән аңлаган һәм үз эшенең җитдилеген яхшы төшенгән укытучы гына тәрбияче алдында торган күп санлы бурычларны уңышлы башкарып чыгарга сәләтле. Зөһрә Бәйрәшева — әнә шундый укытучыларның берсе.

Партиябез һәм хөкүмәтебез аның укытучылык юлындагы хезмәтенә югары бәя бирде. 1957 елда милли кадрлар тәрбияләү эшендәге зур уңышлары өчен Зөһрә Бәйрәшева «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. 1958 елда уңышлы педагогик эшчәнлеге өчен аңа доцентлык дәрәҗәсе бирелде. 1963 елда, татар хатын-кызлары арасыннан беренче булып, Зөһрә Гәрәй кызы Бәйрәшева сәнгать фәннәре буенча профессорлык дәрәҗәсенә лаек булды.

——□——

# АРХЕОЛОГИЯ ДОКТОРЫ АЛЬФРЕД ХАЛИКОВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



Барлык фәннәр арасында тарих фәне иң борынгыларыннан исәпләнелә. Элек-электән кешеләр үзләренең ата-бабалары, аларның тормышлары белән, зур вакыйгалар, зур шәхесләр белән кызыксына килгәннәр һәм халык тормышындагы иң әһәмиятле фактлар турында киләчәк буынга язып калдырырга тырышканнар. Шулай итеп, гасырлар буена тарихи язмалар туплана килгән. XIX йөзгә кадәр тарих, нигездә, менә шундый язма документларга һәм халык истәлекләренә таянып язылган.

Әгәр язма документлар булмаса, ул чагында нишләргә соң? Элекке заманнарда, әйтик, моннан мең, мең ярым еллар элек барлык халыкларның да язу системасы, тарихчы галимнәре булмаган лабаса! Культура ягыннан алга киткән илләрнең тарихчылары да үзләрендә яисә күршеләрендә булган барлык нәрсәләрне күреп, белеп житкермәгәннәр. Шулай булгач, язма документларга гына нигезләнгән тарихны тулы дип әйтеп буламы?!

Менә шунда инде тарихчыларга археологлар ярдәмгә килә. Археологлар борынгы кешеләр торган җирләрне казып карыйлар һәм җир астыннан табылган материаль культура калдыклары буенча бик ерак тарихларны «укый» алалар. Язма документларга әйбер документлар өстәлә. Бары тик археология барлыкка килгәч кенә тарих фәне чын-чынлап алга китә алды. Соңгы йөз, йөз илле ел эчендә археологлар кешелек дөньясын искиткеч ачышлар белән баеттылар. Бөтен дөнья культурасы алдында археологларның хезмәте чиксез зур.

Без еш кына: татар язма әдәбиятының ерак тарихы бар, дияргә яратабыз. Ә менә бездә тарих фәненең дә ерак тарихы булганлыгын безнең барыбыз да белә микән? Бездә, мәсәлән, Болгар чорында ук атаклы тарихчылар булганлыгы мәгълүм. Болгардан соңгы чорларда да татарлар арасында тарихчылар бетеп тормаган. Мисалга XIX гасырда яшәгән олы галимнәр Шиһаб Мәрҗани белән Каюм Насыйриларны күрсәтү дә житә. Татарлар арасында тарих фәненең торышы, үсеше мәсьәләсе, минемчә, киләчәктә аерым тикшеренүне таләп итә.

Революциягә кадәр бездә археология белән кызыксынучылар да күренә башлый. Шуларның иң беренчесе укытучы Гайнетдин Әхмәров була. Шулай да бу археологлар «кызыксынучылар»дан ары уза алмыйлар. Бүгенге көннәргәчә бездә фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешкән бер генә археологның да булмавы шул турыда сөйли булса кирәк.

Ләкин бу кимчелек инде артта калды. Күптән түгел Мәскәүдәге Югары аттестация комиссиясе Альфред Халиков язган докторлык диссертациясенең якланганлыгын раслады. СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият, тарих институтының Археология һәм этнография секторы мөдире, республикабызның күренекле археологы, тарихчысы Альфред Халиковны, шулай итеп, татарлардан беренче доктор-археолог дип әйтергә безнең тулы хакыбыз бар.

Альфред Халиков 1929 елда Татарстанның Октябрь (Норлат) районы Кизләү авылында туа. Археология белән ул Казан университетының тарих бүлегендә укыган чагында ук кызыксына башлый. 1947 елны Казан археологы Н. Ф. Калинин белән ул беренче мәртәбә фәнни экспедициягә чыга. Шуннан бирле Альфред Халиков һәр елның язгы, җәйге, көзге айларын кырларда-басуларда үткәрә. Хәзер ул экспедицияләргә үзе җитәкчелек итә. Татарстан археологлары гына түгел, күршебез Мари АССР археологлары да берничә ел инде аның кул астында эшлиләр.

Студент чагында ук өйрәнә килгән материаллары нигезендә А. Халиков 1956 елда «Идел буенда, Казан тирәсендә бакыр чорында яшәгән кабиләләр тарихы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Соңга таба яшь галимнең фәнни чикләре киңәйгәннән-киңәя бара. Беренче адымнарын шулай Казан тирәсендә генә башлаган Альфред озакламый бөтен Урта Иделне өйрәнә, Татарстанда гына чикләнеп калмыйча, күрше өлкәләргә дә үтеп керә. Аның 1965 елны якланган докторлык диссертациясе «Урта Идел буе халыкларының борынгы тарихы» дип атала.

Альфред Халиковның докторлык диссертациясендә туган җиребезнең фәндә моңарчы тиешенчә өйрәнелмәгән ерак чорлары яктыртыла. Үзенең бу хезмәтендә галим күп кенә бәхәсле яисә ачыкланып җитмәгән мәсьәләләрне үзенчә, яңача чишә һәм Урта Идел буе халыкларының үткән тормышын, фәнни дәлилләргә таянып, тулы итеп күз алдына бастыра. Идел буе халыкларының борынгы тормышын өйрәнүчеләр өчен аның бу хезмәте әйтеп бетергесез дәрәҗәдә кыйммәтле кулланма булачак.

Альфред Халиков әле яшь, көчле. Киләчәктә аның совет фәнен үстерүдә, туган халкыбызның тарихын өйрәнүдә яңаданяңа уңышларга ирешәчәгенә без аз гына да шикләнмибез.

«Казан утлары» журналының тапшыруы буенча, мин Альфред Халиков янында булдым, редакция исеменнән, журналның күп санлы укучылары исеменнән аны докторлык дипломы алуы белән котладым һәм аның кайбер сорауларга җавап бирүен үтендем. Түбәндә укучыларны шул сорау-җавапларның кыскача эчтәлеге белән таныштырмакчы булам.

НУРИХАН ФӘТТАХ

Сорау. Татар халкының борынгы тарихын өйрәнүдә соңгы елларда нинди уңышларга ирешелде?

Җавап. Бу сорауга җавап биргәнче, иң әлек Урта Иделнең борынгы чорын күз алдына китерергә тырышып карыйк. Урал таулары борын-борыннан Азия белән Европаны бүлеп торган булса, Идел, Чулман (Кама) сулары, киресенчә, ике континент халыкларын тоташтыручы, аралаштыручы төп сәүдә юлы булган. Иделдә, Чулманда төрле халыклар, төрле культура, дин вәкилләре очрашкан. Монда яшәүче җирле халыклар да, гасырлар үтү белән, төрле сәбәпләр аркасында әледән-әле үзгәреп, алышынып торганнар. Аларның кайберләре утракланган җирләреннән куып китәргә мәҗбүр булганнар, кайберләре олы яуларда кырылып беткәннәр, кайберләре читтән килгән яңа, көчле кабиләләргә кушылып, этник яктан юкка чыкканнар.

Тик шулай да аларны эзсез югалганнар дип әйтеп булмый. Безнең борынгы җиребездә әзме-күпме тормыш кичергән халыкларның җир астында каберлекләре, торак урыннары (кала-таулар) торып калган. Без менә шул каберлекләрне, кала-тауларны казыйбыз, аларда табылган кеше, мал-туар сөякләре, таштан, металлдан, балчыктан, пыяладан, сөяктән ясалган бик күп төрле әйберләр буенча элекке халыкларның тормыш-көнкүрешен, яшәү шартларын, динен-идеологиясен өйрәнәбез. Казып табылган әйберләр — чүлмәк ватыклары, төймәләр, алкалар һәм бүтән төзәнү-бизәнү әйберләре, ук, сөңге башлары, акчалар, таш бина калдыклары һ. б. бик күп нәрсәләр — безгә борынгы кешеләрнең кайчан, ничек яшәүләрен генә түгел, бәлки аларның нинди телдә сөйләшкән булуларын да, йөз-бит, тән төзелешләрен дә ачыкларга ярдәм итә. Конкрет алганда, Болгар дәүләтенең тарихын без, башлыча, менә шундый материаль культура калдыкларына таянып тикшерәбез.

Болгар дәүләтенең төп төрки халкы, билгеле булганча, Урта Идел һәм Урал арасындагы киң территориядә яшәүче татарларның борынгы бабалары булып саналалар. Татарларның борынгы бабалары алар гына түгел, әлбәттә. Безнең «баба»ларыбыз бик күп. Шул күп «баба»лар арасында иң күренеклеләреннән берсе — Болгар дәүләте төркиләре.

X гасыр башларында Болгар дәүләте түбән Иделдәге хазарларга буйсынган була. Борынгы язмалардан күренгәнчә, хазарлар белән болгарларның теле бер булган. Алар төрки телдә сөйләшкәннәр. Гарәпләрне Көнчыгыш Европага үткәрмичә тоткарлап торган, Византияне гарәп агрессиясеннән саклап калган Хазар империясе X гасыр азакларында көчсезләнә, таркала башлый. Менә шул шартларда Болгар дәүләте мөстәкыйльлеккә ирешә. Көнчыгыш Европадагы төрки культураның үзәге, шулай итеп, хазарлардан болгарларга күчә.

Кыска гына вакыт эчендә Болгар көчле, культуралы дәүләтләрнең берсенә әверелә. Һөнәрчелек, сәүдә, төзелеш, металл, күн эшкәртү, иген игү буенча һәм тормыш-көнкүрешнең, хуҗалыкның башка күп кенә тармакларында Болгар төркиләре үз заманындагы күршеләреннән бик нык алга китәләр. Мисал өчен чуен кою һөнәрен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Болгарлар XIV гасырда ук инде чуен коюның серен үзләштерәләр. Көнбатыш Европада исә (Англиядә) чуенны беренче мәртәбә XVI гасырда гына коя башлыйлар. Болгар төркиләренең күрше халыкларга культура тәэсире бәхәссез нәрсә. Марилар, удмуртлар, башкорт, мордва, чувашлар гасырлар буена болгарларның уңай тәэсирен тоеп яшиләр. Болгарларның тәэсире шулай ук русларда да сизелә. Рус елъязмаларында әйтелгәнчә, болгар осталары русларга, мәсәлән, таш биналар салып бирәләр.

Соңгы елларда Болгар дәүләте тарихын тикшерүдә шактый уңышларга ирешелде. Шулардан берничәсен күрсәтеп китәргә була.

Беренчедән, Идел-Чулман буйларына төрки халыкларның кайчан, кайсы гасырда килүләре мәсьәләсен алыйк. Тарихта моңарчы: Идел буена болгарлар VII — VIII гасырларда күчеп килгәннәр һәм, шулай

булгач, VII — VIII гасырларга кадәр монда төрки халыклар булмаган, дигән караш яшәп килә иде. Бу карашны раслаган ышанычлы дәлилләр юк иде, шуңа күрә, бик озак еллар буена бу мәсьәлә бәхәсле көе кала килде.

1950 елда казыла башлаган һәм елданел казыла килгән Олы Тархан, Танкеевка каберлекләре безнең өчен көтелмәгән яңалыклар ачты. Ул яңалыкларның иң әһәмиятлесе шул: Урта Идел һәм Чулман буйларында, болгарлар килгәнче берничә гасыр элек үк инде, ниндидер төрки кабиләләр яшәгән. Алар бу җирләргә III—IV гасырларда ук күченеп килгәннәр. Бүгенге татарларның Иделдәге, Чулмандагы шул бик борынгы бабаларын без кайчандыр Европа тарихында яңа эра ачкан хуннарның бер төркеме булырга тиеш дип исәплибез. Шулай итеп, болгарлар үзләре җирле төрки кабиләләр иленә басып кергәннәр, аларны үзләренә буйсындырганнар һәм үз исемнәрендә дәүләт төзегәннәр. Ләкин культура үсеше ягыннан алар утрак төркиләрдән түбәнрәк торганнар һәм соңга таба, җирле кабиләләрнең культурасын үзләштереп, алар белән тулысынча аралашып беткәннәр. Болгарларның бары данлы исемнәре генә сакланып калган. Тарихта мондый «ялгышулар»ны шактый очратырга мөмкин.

Икенчедән, Болгар дәүләтенең халкы мәсьәләсе. Болгарларның төрки булуы турында ышандыргыч язма мәгълүматлар булса да (мәсәлән, XI гасырда яшәгән Мәхмүд Кашгари сүзлеге), кайбер тарихчылар монгол яулап алуларына кадәр Болгар дәүләтенең халкы төрки булмаган, бәлки угро-фин, славян яисә бүгенге чуваш теле кебек телдә сөйләшүче кабиләләр булган дип килделәр. Аларның фикеренчә, Урта Идел, Чулман буйларында төрки халыклар бары тик Алтын Урда чорында гына утракланып калганнар.

Казан археологларының Олы Тархан, Танкеевка каберлекләрендә тапкан күп санлы материаллары шулай ук бу карашның да нигезсез икәнлеген исбат итте. Болгар дәүләтенең төп халкы, алда күренгәнчә, монголлар килгәнче дә, монголлар килгәч тә, һичшиксез, төрки булган. Шулай да аларның теле ниндирәк «төрки» булды икән соң? Бу мәсьәләдә әлегә нык урнашкан бер генә фикер юк. Ләкин кайбер мәгълүматлар болгарларның кыпчакларга якын булуы турында сөйли. Мәсәлән, кенязь Всеволод Юрьевич 1184 елны Киев кенязе Святославка язган хатында: кыпчаклар белән болгарларның теле дә, нәселе дә бер ди. Аннары, Мәхмүд Кашгари сүзлегендә кыпчак сүзе яисә болгар сүзе дип күрсәтелгән сүзләрне без бүгенге татар телендә очрата алабыз. Мәсәлән, «бал» сүзен М. Кашгари кыпчаклар, суарлар сүзе дип бирә. Моңа шулай ук «авыс» (балавыз) сүзен дә өстәргә мөмкин.

Димәк, болгар теле, кайберәүләр ышандырырга тырышканча, һич тә хәзерге чуваш теле кебек булмаган. Болгар төркиләренең теле кыпчак, угыз телләренең якын туганы булган һәм, ихтимал, бүгенге татар теленең нигезе нәкъ менә шул борынгы заманнарда ук формалаша башлагандыр дип әйтәсе килә.

Ләкин шуны да онытмаска кирәк. Болгар дәүләтенең халкы этник яктан бер генә төрле булмаган. Монда, төркиләр белән бергә, әлбәттә, башка этник группалар да яшәгән.

Сорау. 1966 елгы археологик эшләрнең нәтиҗәләре турында бер-ике сүз әйтә алмассызмы?

Җавап. 1966 елда Казан археологлары күп кенә эшләр башкардылар. Фәнни хезмәткәр Тамара Хлебникова җитәкчелегендәге бер отряд борынгы Болгар шәһәре калдыкларын тикшерде. Аерым алганда, фәндә «Кара пулат» («Черная палата») дип йөртелгән таш бина тирәсе казылды. Элек бу бинаның кайчан салынуы да, ни өчен салынуы да билгеле түгел иде. Былтыр бу мәсьәләгә берникадәр ачыклык кертелде. «Кара пулат»ның нигезе тирәсендә бик әһәмиятле ике дәлил — бакыр акчалар белән алтын йөзек табылды. Шулар буенча без бу бинаның XIII йөз азакларында яисә XIV йөз башларында салынган булуын әйтә алабыз.

Хәтерегездә булса, «Кара пулат» дүрткел итеп, өч яруслы (өч катлы) итеп төзелгән. Ни өчендер аның тышкы ишеге икенче катта. Бу нәрсә бездә күп кенә сораулар тудыра иде. Былтыр без моңа да җавап таптык шикелле. Бина тирәсен казып карагач, җир астыннан стена калдыклары килеп чыкты. Кайчандыр «Кара пулат»ның дүрт ягында да (күрәсең, беренче кат биеклегендә) кечкенә-кечкенә бүлмәләр булган. Алар барлыгы унөч. Шулай итеп, «Кара пулат» төптән (беренче каттан) хәзергегә караганда киңрәк булган.

Экспедициянең фәнни җитәкчесе, Мәскәү профессоры А. П. Смирнов әлеге бүлмәләрдә дәрвишләр яисә мәдрәсә шәкертләре яшәгәндер, дигән фикерне әйтә. Ләкин безнең салкын климат шартларында ул таш капчыкларда дәрвишләр, шәкертләр яшәвен күз алдына китерүе кыен. Ихтимал, «Кара пулат» элек суд-хөкем урыны булгандыр дип әйтергә мөмкин. Хәзергәчә сакланып калган үзәк бинада, күрәсең, хөкем иткәннәр, гаепләнүчеләрне исә нәкъ менә шул беренче каттагы таш капчыкларда тотканнар. Бакуда, мәсәлән, урта гасырлардан калган шундый хөкем бинасы бар.

Минем җитәкчелектәге икенче бер отряд быел да Танкеевка авылы янындагы каберлекләрне казу эшен дәвам итте. Танкеевкада барлыгы 800 чамасы кабер калдыклары ачылды. Шуларның 200 гә якыны 1966 елда тикшерелде. Бу каберлекләрдәге кешеләр IX — X гасырларда, Болгар дәүләте төзелгән чорларда ук күмелгән булганнар. Җир астыннан табылган күп санлы кызыклы материаллар шул турыда сөйли.

Иделнең язын су баса торган түбән урыннарында көзге айларда су бераз кими төшә. Шуннан файдаланып без сентябрь-октябрь айларында төрле утрауларда, кал-

ку урыннарда археологик эзләнүләр һәм казу эшләре алып бардык. Соңгы 3 — 4 ел эчендә монда 500 гә якын археологик «нокталар» табылды. Шуларның йөздән артыгы — болгар авылы калдыклары. Һәм алар күбесенчә Кама тамагы тирәсендә урнашканнар. Узган елны без шундый утрауларның берсендә болгар акчалары хәзинәсе таптык.

Былтыргы эшләр турында сөйләгәндә, фәнни хезмәткәр Равил Фәхретдинов турында аерым әйтеп китәргә кирәк. Равил Фәхретдинов, фәнни экспедицияләрдә катнашу белән бергә, үзлегеннән дә шактый эшләр башкарды. Ул борынгы Болгар җирен чын мәгънәсендә аркылыга-буйга җәяүләп йөреп, тикшереп чыкты, 1700 чамасы болгар авылы калдыкларын табып, картага төшерде. Шуңа таянып, Равил Болгар дәүләтенең чикләрен билгеләде. Төп болгарлар яшәгән территориянең төньяк чиге, мәсәлән, хәзерге Казан тирәсеннән, көнбатыш чиге — Зөя елгасы буйлап үтә. Көньякта ул Иделдәге Жигули тауларына барып җитә, көнчыгышта исә Җаек (Урал) суы буйларына сузыла. Билгеле, болгарларга буйсынган яисә болгарлар тәэсирендә булган җирләрнең чиге моннан киңрәк. Мәсьәләгә бу күзлектән караганда, Болгар дәүләтенең чиген төньякта — Боз океанына, көнчыгышта — Урал тауларына кадәр сузарга мөмкин булыр иде. 1966 елда фәнни хезмәткәр Петр Старостин Чуваш АССР җирендә археологик эзләнүләр алып барды. Ул Чувашиянең төньягындагы Цивиль елгасы буйларын һәм башка районнарны тикшерде. Шунысы кызыклы: Чувашиядә болгарларга караган бер генә археологик истәлек тә юк.

Сорау. Киләчәккә планнарыгыз белән таныштырсагыз иде.

Җавап. Безнең археология һәм этнография секторында хәзер зур коллектив эшли. Киләчәктә без Идел, Кама буендагы төрки халыкларның археологик истәлекләрен өйрәнүне тагын да көчәйтергә уйлыйбыз. Шул исәптән, Болгар шәһәре калдыкларын казу эше дәвам иттереләчәк.

Кайчандыр Биләр (Бүләр) шәһәре Болгар дәүләтенең башкаласы булган. Шулай да Биләрдә әле беркайчан да диярлек казу эшләре башкарылмаган. 1967 елның җәендә без бөтен коллектив белән Биләр калдыкларын казуда катнашачакбыз. Анда без Болгар шәһәрендәгегә караганда да кызыклырак материаллар табарга өметләнәбез.

Түбән Кама, Чабаксар ГЭСлары төзелгәч, бик күп җирләр су астында калачак. Су басуга кадәр без күп кенә урыннарда археологик эшләр алып барырга тиешбез. Каманың төньяк районнарын, шулай ук Казан артын һәм Тау ягын өйрәнү киләчәктә безгә Казан ханлыгының этник составын, культурасын ачыкларга мөмкинлек бирәчәк.

1969 елда Уфада башкортларның һәм Башкортстан татарларының килеп чыгуына багышланган фәнни сессия булачак. 1970 яисә 1971 елда шундый ук сессия Казанда үткәреләчәк. Ул сессиядә Урта Идел — Урал татарларының килеп чыгышы мәсьәләсе каралачак. Без хәзердән үк менә шул фәнни дискуссиягә әзерләнәбез. Галимнәрнең Уфада һәм Казанда булачак очрашулары халкыбызның тарихын, культурасын, этногенезын өйрәнүгә, һичшиксез, зур өлеш кертәчәк.

Үземнең киләчәккә шәхси планнарым мәсьәләсенә килгәндә, хәзер мин докторлык диссертациясен Мәскәүдәге «Наука» нәшриятында аерым китап итеп бастыру өчен әзерлим. Аннары Равил Фәхретдинов белән икәүләп без Болгар турында татарча фәнни-популяр китап язарга уйлыйбыз.

— — □ — —

# ТАГЫН ИБРАҺИМ ХАН ЯРЛЫГЫ ТУРЫНДА

Ә. Булатов иптәшнең Ибраһим хан ярлыгындагы кайбер сүзләрне ничек уку һәм аңлатуга карата язылган рецензиясен урнаштырып [1], редакция дерес эшләгән. Хакыйкать бәхәстә туа, диләр. Ләкин Ә. Булатов мәкаләсендә «бу хата», «бу ялгыш», дип күрсәтелгән әйберләрнең байтагы белән килешеп булмый. Шуңа күрә, әлеге ярлыкны матбугатта чыгарырга әзерләшкән авторларның берсе буларак [2], рецензентның ялгыш төзәтмәләре хакында үз фикеребезне язарга уйладык:

а) Ә. Булатов тарафыннан ярлыкның өченче юлындагы «йибәрелгән» сүзе «йибәргән» дип төзәтелә. Ләкин ярлыкның үзендә үк бу сүз бер урында «йибәрелгән» (өченче юл), ә икенче урында (сигезенче юл) «йибәргән» формасында язылган.

б) «Аты: башлыг» гыйбәрәсен «алты яшьлек»кә әверелдерү дә, безнеңчә, шулай ук аңланмый. Сабыйга (җитмәсә, «кол» малайга) тарханлык хокукы бирелү бернинди юридик нормаларга сыймый. Шулай да, рецензент фикерен «кабул итеп», әлеге сүзне текстка куеп карыйк: «Бу азат йибәрелгән кем ирсәләрнең алты яшьлек Гөл-Бостан-хатун угылы Мөхәммәт-Газиз-хан нәсәбе шаһ...» Димәк, алты яшьлек хатынның тарханлык алырлык улы булган...

в) «Билгесез»не «танык» дигән тәрҗемәдә кабул иттек ди. «Болардин таныксыз кем-кем ирсә урманларына йөремәсенләр». Мәгънә бөтенләй бутала. Кем ул «болар?» (Килеш һәм тартым кушымчаларына игътибар итегез.) Тарханлык алучыларның үзләреме? Алайса, алар кем кулындагы урманнарга йөрмәскә тиеш? Яки һәрбер «таныклы» кеше аларның урманнарына йөреп, юкә каезлый башласа, тархан булудан ни файда?!

г) Гарәп хәрефләре белән язылган «санлыг» сүзен, әгәр үзеңнән нокталар өсти барсаң, чыннан да, «нишанлыг» дип укып була (институтта ясаган докладыбызда, рецензент хәтерлидер, бу фикерне әйткән идек). Әмма ярлыкның без караган оригиналында «нокталар җуелган» дип уйларга урын юк. Язу бик әйбәт сакланган. Биредә исә «дәрәҗәле» төшенчәсендәге «санлыг» мәгънәгә зыян китерми.

д) «Чура» сүзенә карата әйтелгән урында автор аның янындагы башка сүзләрне дә имгәтеп уза. Мәсәлән, «чура»ның (рецензентча: колның) хуҗалары булган Гөлбостанны, улы белән бергә, кол ясый («Хәйдәр-Гали кол булып саналган тол хатын Гөлбостанны»... — Ә. Булатов). Ярлыкта исә Хуш-Килде исемле кеше, аларның, ягъни Гөл-Бостан ханым һәм аның улы Мөхәммәт Газизләрнең «чурасы» дип, тартым кушымчасы ярдәмендә ике мәртәбә телгә алына. Авторның «чура» сүзендә «хезмәткәр, ирекле ялчы, хезмәтче» мәгънәләрен күрүдән баш тартуы нигезсез. Безнең фикер башка документлар белән дә дәлилләнә. Шулардан берсен генә китерик. XVI гасыр азагында яшәгән татар тарихчысы Кадыйр-Гали-бәк «Җәмигъ-әт-тәварих» исемле әсәрендә Туктамыш-хан белән Идегә морза турында болай яза: «Бу Туктамыш-хан Идел мәузыйгы(н) да үтте: ... Котлы-Кыя углы Идегә Күчүк аның чурасы ирде»... (КДУ, Гыйльми китапханә. Шәрык секторы. т. 40 номерлы кульязма. 61-а бит). Шаять, Алтын Урда дәүләте башында ат уйнатып, тәхет өстендә ханнарны биеткән Идегә морзаны беркем дә кара колга әверелдерә алмас. (Бер сүзнең берничә мәгънәне эченә алуы һәм атамаларда мәгънә үзгәрүе тел белемендә бик мәгълүм күренеш бит) [1].

е) «Сабан» сүзендә «н» хәрефенең төшеп калуында рецензент ниндидер закончалык эзли. Ләкин тәрнчә сүздәге «әлиф» өстендә, башка истәлекләрдәгечә, тәнвин-фәтхә (параллель сызыкчалар) куелса, ул, чыннан да, законлы булыр иде. «Ирсәлә»дәге соңгы «р»ның төшеп калуы да орфографик хата гына, чөнки ярлыкта ул сүз тагын ике җирдә азактагы «р» белән «ирсәләр» формасында дөрес язылган. Димәк, бер-ике ялгышка таянып, «борынгы татар телендә мондый очракларда», дип «кагыйдәләр» иҗат итәргә нигез юк әле.

ж) Ярлыкның беренче авторы кем булуы хакында мәгълүматыбыз азлыгын рецензентка хәтле әйткән идек («Казан утлары», 1965, № 8, 148—149 битләр). Сорауны кабатлаудан гына җавап табылмый бит.

Югарыдагы мисаллардан бер нәтиҗә чыга: тарихи документларның текстын, өзгәләп, һәр сүзне аерым-аерым өйрәнүдән бигрәк, төгәл әсәр, бөтен организм хәлендә синтезлау алымы белән тикшерергә кирәк. Аерым сүзләр тирәсендә чокчына башласаң, колларга тарханлык, аксөякләргә исә коллык өләшеп, алты яшьлек сабыйлардан балалар таптыру әллә ни гаҗәп булмас. Мәсьәләнең әдәби текстология фәнебез өчен менә шулай принципиаль булуын исәпкә алып, бу җавапны язу лаек табылды.

М. ГОСМАНОВ.

# САДОВНИКОВ ҖЫЕНТЫГЫНДАГЫ ТАТАР ТАБЫШМАКЛАРЫ

Дмитрий Николаевич Садовников (1847—1883) рус халкының авыз иҗаты әсәрләрен җыюда, бастыруда, аларны фәнни тикшерүдә зур эшчәнлек күрсәткән галимнәрнең берсе. Фольклористика фәнендә аның исеме хаклы рәвештә А. Н. Афанасьев, В. И. Даль, П. Н. Рыбников, А. Ф. Гильфердинг һ. б. исемнәре белән янәшә телгә алына. Д. Н. Садовниковның 1876 елда Петербургта басылып чыккан «Рус халык табышмаклары» җыентыгы аеруча популярлык казанды. Ул хәзергә кадәр рус табышмакларының иң тулы җыелмасы булып калуында дәвам итә.

Моннан 90 ел элек дөньяга чыккан бу җыентыкта кайбер татар табышмаклары яки алар турында кызыклы гына мәгълүматлар бар. Табышмакларга биргән искәрмәләрендә Садовников башка халыкларның, шул исәптән татар халкының, фольклорыннан күп кенә «параллельләр» китергән. Биредә без шулардан соңгыларына тукталып үтәргә уйлыйбыз. Садовников җыентыгының 1959 елда Мәскәү университеты нәшрияты тарафыннан чыгарылган басмасыннан [2] файдаландык. Гәрчә бу басмада җыентыкның редакторы һәм кереш мәкалә авторы В. П. Аникин тарафыннан табышмакларга яңа, тулыландырылган искәрмәләр бирелсә дә, ул аларда төзүченең искәрмәләре саклануын һәм шулар нигезендә

---

[1] Ә. Булатов. Ибраһим хан ярлыгын укуга карата кайбер фикерләр. «Казан утлары» журналы. 1966 ел. 8 сан.

[2] «Казан утлары» журналы. 1965 ел. 8 сан. 146—150 битләр.

---

[1] Безнең мәкаләдә «чура» сүзе «чүрә» рәвешендә бирелгән. Бу — җитди төгәлсезлек. Бу кимчелекне рецензент, нигәдер, игътибарсыз калдырган.

[2] Загадки русского народа. Сборник загадок, вопросов, притч и задач. Составил Д. Н. Садовников. Издательство Московского университета. 1959 год.

«Д. Н. Садовниковның табышмаклар турында ниләр уйлавын һәм ниләр язуын т у л ы с ы н ч а (ассызык безнеке — Х. М.) күз алдына китерергә мөмкин» булуын әйтә [1].

Җыентыкта без «татар табышмагы» дигән сүзләрне беренче мәртәбә 267 нче биттә, төтен турындагы 152 нче номерлы табышмакка бирелгән искәрмәдә очратабыз. Анда Садовников болай дип язган: «Төтен турындагы татар табышмагы безнеке белән охшаш. Томан турында да бердәй үк».

Китаптагы рус табышмагы мондый: «Аяксыз, кулсыз, өй түбәсенә менә» (43 нче бит). Аннары аның варианты китерелгән: «Аяксыз, кулсыз, тау башына менә». (Бик тиз югарыга күтәрелә мәгънәсендә — В. П. Аникин искәрмәсе).

Бездә боларга якын торган табышмаклар итеп «Мөгри, мөгри мөгрәлгән, мөгезе күккә терәлгән», «Өй башында аю бии» кебекләрне күрсәтергә мөмкин [2].

Русча җыентыкта томан турында «Серое сукно тянется в окно» (222 нче бит) һәм төтен турында:

«Скребу — не выскребу;
Мету — не вымету;
Пора придет,
Сама уйдет»

(44 нче бит) дигән табышмаклар бар. Бәлки, шундый ук табышмаклар элегрәк бездә дә булгандыр. Хәзер исә бу ике табышмак бер бөтен булып оешкан хәлдә генә очрый:

«Тәрәзәдән керә,
Сукно кебек җәелә,
Кусаң да китми,
Таяк та тәэсир итми.
Вакыты җитәр,
Үзе китәр».

Ут турындагы 198 нче номерлы табышмак хакында сүз йөрткәндә төзүче: «Татарлар утны кызыл кәҗә белән чагыштыралар»,— дип искәртеп үткән (270 нче бит). Безнең фольклор җыентыкларында төнне «кара кәҗә» дип алу бар. Ә менә ут турында «кызыл мәче» һәм «кызыл сыер» дигән метафоралар гына очрый.

Татарларда йомырка турында табышмаклар шактый. Н. Исәнбәт җыентыгында аларның саны 24 кә җитә. Садовниковның әйтүенә караганда исә, безнең болардан тыш тагын бер кызыклы табышмагыбыз булырга тиеш. Рус галиме менә нәрсә яза: «Татарлар (йомырка турында — Х. М.): «Күктән төшкән, тимер белән кыргандай шома»,— дип табышмак әйтәләр» (282 нче бит). Укучыны бу табышмакның бик үк матур яңгырамавы гаҗәпләндермәскә тиеш. Чөнки ул кайчандыр татарчадан русчага тәрҗемә ителгән, хәзер кабат русчадан татарчага күчерелә, кем әйтмешли, «куян шулпасының шулпасы» гына булып чыга.

Кыяр турындагы табышмакның искәрмәсе игътибарга лаеклы: «Томск губернасы татарлары недр күркәсе турында шундый табышмак әйтәләр». (287 бит). Димәк, Садовников теге я бу дәрәҗәдә Себер татарлары фольклары белән таныш булган [3]. Икенчедән, бу — табышмакның кайсы урында әйтелүен күрсәткән бердәнбер очрак. Урыннары күрсәтелмәгән башка табышмаклар Идел буенда яшәүче татарлар арасында очрагандыр, дип уйларга нигез юкмы икән монда? Билгеле булганча, Д. Н. Садовников Сембер шәһәрендә туып-үскән, байтак еллар анда яшәгән. Идел буе халыкларының тарихын, этнографиясен, фольклорын өйрәнгән. Ул язып алган башка жанр авыз иҗаты әсәрләрендә татарлар шулай ук телгә алына. Бер риваять, мәсәлән, Сембер губернасы, Алатырь өязе, Ломаты авылы татары — «гадәттән тыш көчле, юмарт, халыкны кысрыклаучы байларны яратмаучы, полициягә тоттырмаучы» юлбасар Шарюк турында сөйли [1]. Садовников җыентыгындагы кайбер русча табышмакларның әйтелү урыны «Казан» дип күрсәтелә. Ул 1883 елның августында Казан шәһәрендә үзе дә булып китә.

«Татарлар үзләренең табышмакларында елганы күк юрга белән чагыштыралар». — Елга турындагы табышмакка искәрмәдә әнә шул сүзләрне укыйбыз. (310 нчы бит.) Дөрес, безгә мәгълүм табышмакларда турыдан-туры, күк юрга, дип әйтү күренми. Әмма елганы ат белән чагыштыру бар. «Аты бара, тәртәсе кала», «Үзе чаба да чаба, койрыгы күренми» һ. б.

Су өстендәге көймә турында рус һәм татар табышмаклары бер-берсенә бик охшашлар. Моңа Садовников та игътибар иткән (311 нче бит). Биредә ике халыкның табышмакларын чагыштырып узарга мөмкин.

| САДОВНИКОВ ҖЫЕНТЫГЫНДА | ИСӘНБӘТ ҖЫЕНТЫГЫНДА |
|---|---|
| Еду, еду, — | Барам, барам, |
| Следу нету. | Эзе юк. |
| Режу, режу, | Кисәм, кисәм, |
| Крови нету. | Каны юк. |
| (180 нче бит). | (137 нче бит). |

Балык тота торган ятьмә турындагы табышмакка искәрмәсендә Садовников: «Татарларда да шундый табышмак бар», — ди (315 нче бит). Ә 1919 нчы номерлы табышмакка бирелгән искәрмәдә: «Татарлар айны көмеш касә белән чагыштыралар»,— дигән сүзләр бар (321 нче бит).

Ә менә монысы, ихтимал, Садовников китергән татар табышмаклары арасында иң кызыклысыдыр. Ул күк һәм йолдызлар турында: «Бозга бодай чәчелгән» (321 нче бит). Нинди тапкыр һәм нык метафора. Күк кадәр күкне барлык йолдызлары белән уч төбедәй боз кисәге өстенә сыйдырып кара әле син! Бер үк вакытта төнге күкнең бар буяулары да сакланган. Күкнең үзе кебек үк зәңгәр боз, гәрәбәдәй сары бодай бөртекләре...

Бу урында тагын бер нәрсәне әйтеп үтәсе килә. Безгә Буа районының Выселка авылыннан укучы Илгиз Җәләлов җибәргән табышмаклар арасында ай һәм йолдызлар турында бер яңа (матбугатта күренмәгән мәгънәсендә) табышмак бар: «Ару бодай эчендә алтын йозак». Күрәсез, йолдызларны бодай белән чагыштыру башка табышмакларыбызда да очрый икән.

Безнең кайбер әкиятләребез «Борын-борын заманда... бозга бодай чәчкән вакытта» дип башлана. Садовников китергән табышмак белән моның арасында да бәйләнеш булуы мөмкин. Әкиятләрнең аерым элементларыннан соңга табарак табышмаклар ясалу очраклары юк түгел бит. Әйтик, «Үзе бер карыш, сакалы биш карыш». Бу фантастик әкияттәге сихерче картка характеристика да, бер үк вакытта җепле инә турындагы табышмак та. Әкияттә «айга-көнгә күренми торган сылу кыз» образы очраса, безнең агач үзәге турында «Айга-көнгә күренми, агач белән тиң үсә» дигән табышмагыбыз да бар һ. б.

Шулай итеп күренекле рус фольклорчысы Д. Н. Садовников үзенең җыентыгында уннан артык татар табышмагын китерә, рус табышмакларын алар белән чагыштыра. Соңгыларының охшаш яки үзенчәлекле якларын күрсәтеп үтә.

Татар табышмакларын җыю һәм өйрәнү тарихында без аның исемен хөрмәт һәм рәхмәт хисләре белән телгә алып үтәргә тиешбез.

**Х. МӘХМҮТОВ,**
СССР Фәннәр Академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты.

[1] Шунда ук. 262 нче бит (Русчадан тәрҗемәләр безнеке — Х. М.)

[2] Татар табышмаклары Н. Исәнбәт төзегән («Табышмаклар». Казан, 1941 ел) җыентыктан алынды.

[3] Садовников Себер татарларының бер легендасына нигезләп «Ук» исемле шигырь дә язган. Кара: «Певец Волги Д. Н. Садовников. Избранные произведения и записи». Куйбышев, 1940 год. 41—42 нче битләр.

[1] Шунда ук. 78—79 нчы битләр.

# яңа китаплар

**Ибраһим Гази**

**САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР**

Беренче том

Бәясе 70 тиен

Күренекле язучыларыбыздан Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Р. Ишморат агайларның «Сайланма әсәрләр»е басылып чыгуын укучыларыбызга хәбәр иткән идек инде. Әле шушы араларда гына ул исемлеккә тагын бер китап өстәлде — 60 яше тулу уңае белән, Татарстан китап нәшрияты атаклы әдибебез Ибраһим ага Газиның да «Сайланма




әсәрләр»енең беренче томын бастырып чыгарды. Барлыгы ике томнан торырга тиешле ул «Сайланмалар»ның бу беренче томына язучының егерме өч кечкенә һәм уртача күләмле һәм «Без әле очрашырбыз», «Алмагачлар чәчәк ата», «Алар өчәү иде», «Катя Сорокина» исемле зур күләмле хикәяләре урнаштырылган.




**Салих Баттал**

**ЧИРМЕШӘН ЯКЛАРЫНДА**

Шигъри роман

Бәясе 41 тиен

С. Батталның бу романында катлаулы һәм күп төрле вакыйгалар сурәтләнгән, геройларның портретлары һәм социаль, һәм психологик планда гәүдәләндерелгән. Романда халык иҗаты формалары киң файдаланылган. Әсәр бик җиңел укыла һәм анда сурәтләнгән вакыйгалар укучы күз алдына тулы, ачык булып килеп баса.

**Сафа Сабиров**

**СУ ӨСТЕНДӘ АКЧАРЛАК**

Хикәяләр

Бәясе 40 тиен

Сафа Сабиров — Иделне һәм елгачылар тормышын бик яхшы белә торган язучы. Ул үзе дә заманында төрле пароходларда штурман булып байтак еллар эшләгән һәм Идел, Кама елгаларын йөзләрчә мәртәбә буеннан буена йөзеп үткән. Менә шуңа күрә ул язган әсәрләрнең күбесе елгачылар тормышын сурәтләүгә багышланган, булуы гаҗәп түгел. Аның геройлары — үзләренең романтик профессияләренә гашыйк капитаннар, механиклар, матрослар һәм порт эшчеләре.

Сафа Сабировның әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Су өстендә акчарлак» исемле бу яңа



җыентыгына да, нигездә, елгачылар тормышын сурәтләүче хикәяләре (барлыгы 26) тупланган.

**Гариф Гобәй**

**КОРЪӘН СЕРЛӘРЕ**

Бәясе 62 тиен

Язучы Гариф Гобәйнең «Корьән серләре» исемле бу китабы ислам диненең дә, башка төр диннәр кебек үк, дөньяга фантастик караштан гыйбарәт булуын, ул карашның кешелек җәм-

тыяте үсешендәге түбән бер баскычта барлыкка килүен һәм аның дөнья законнарын фәнни аңлау белән бернинди уртаклыгы юклыгын ачып салуга багышланган.

Коръән үзе төрле күләмдәге 114 сүрәдән тора. Сүрәләрнең иң озыны — «Бәкарә» (Сыер) сүрәсе — 286 аятьне эченә ала, ә иң кыс-



калары — «Насыр» һәм «Кәүсәр» сүрәләре — нибары өчәр аятьтән генә тора. Һәм ул сүрәләр арасында һичнинди эзлеклелек юк, алар күп очракта бер-берсенә каршы киләләр, хәтта бер сүрәдә әйтелгән фикер икенчесендә бөтенләй юкка да чыгарыла. Г. Гобәй бу китабында Коръәннең мондый каршылыклы урыннарын бик ачык һәм аңлаешлы итеп күрсәтеп бирә.

Китап укыр өчен бик мавыктыргыч һәм кызыклы язылган.

**Касыйм Фәсахов**

**УЯНЫГЫЗ!**

Шигырьләр

Бәясе 16 тиен

Касыйм Фәсаховның бу җыентыгында замандашларыбызның уй-хисләрен чагылдырган шигырьләре һәм мавыктыргыч сюжетка корылган, актуаль темаларны яктыртуга багышланган «Пәрәвез», «Диванә» исемле зур күләмле ике поэмасы басылган.




**Гамил Афзал**

**ОФЫКЛАР**

Шигырьләр

Бәясе 10 тиен

Гамил Афзалның бу яңа җыентыгына кергән шигырьләренең күбесе Октябрь революциясенә һәм аның бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленинга ба-




гышланган. Без яңа тормыш төзүчеләр, безнең көндәлек эшебездә революция хәзер дә дәвам итә — җыентыкның төп мотивы менә шул.

**Хәсән Сарьян**

**ӘТКӘМ ҺӨНӘРЕ**

Повесть

Бәясе 28 тиен

«Хикәяләр», «Классташлар» исемле җыентыклары һәм газета-журнал битләрендә басылган күп санлы хикәяләре белән Хәсән Сарьян татар укучыларына күптән таныш иде инде. Хәзер аның «Әткәм һөнәре» исемле яңа повесте басылып чыкты. Повестьның төп герое Гаяз, Совет Армиясендә хезмәтен тәмамлаганнан соң, башта Себердә төзелештә эшли, аннары туган авылына кайтып ур-




наша. Киеренке вакыйгаларга нигезләнгән, мавыктыргыч сюжетка корылган бу повестенда автор Гаязның һәм башка геройларының психологиясен тирәнтен сурәтләгән.

**М. Латифуллин**

**КУРАЙЧЫ МАЛАЙ**

Хикәя

*Бәясе 8 тиен*

Габдулла Тукайның замандашы, «Тукай маршы»ның




авторы Заһидулла Яруллин татар музыка сәнгатен үстерүгә күп көч куйган кеше. Ул — татар совет музыкасына нигез салучы Салих Сәйдәшевнең беренче укытучысы һәм «Шүрәле»

балетын язган талантлы композитор Фәрит Яруллинның этисе. Мәгъсүм Латифуллинның «Курайчы малай» исемле бу китабында Заһидулла ага Яруллинның яшьлек еллары сурәтләнә.

**Мөхәммәдьяр**

**ТӨХФӘИ МӘРДАН**
**НУРЫ СОДУР**

Поэмалар

Бәясе 25 тиен

Шагыйрь Мөхәммәдьяр — урта гасырның зур бер тарихи чорында татар шигърият байрагын күтәреп алга илткән әдипләребезнең берсе. Аның кайчан туу., нинди тормыш юлы узуы һ. б. яклары турында ачык кына итеп әйтерлек мәгълумат юк. Шулай булса да, бу җыентыкка урнаштырылган «Төхфәи Мәрдан» һәм «Нуры содур» исемле поэмаларын укыганнан соң, шагыйрьнең кайсы елларда яшәгәнлеген һәм иҗат иткәнлеген чамаларга мөмкин.



Поэмаларыннан күренгәнчә, Мөхәммәдьяр ярлы халык арасыннан чыккан шагыйрь булган. Үз әсәрләрендә ул ярлы халыкны кызганып, шул ярлы халыкның кешелекле, әйбәт сыйфатларын мактап язган. Шунлыктан ул чордагы хаким сыйныфлар Мөхәммәдьярны күрә алмаган, аны кимсеткәннәр, түбәнсеткәннәр. Шагыйрь, заманы өчен зур белемле, югары аңлы кеше булуына карамастан, кабер сакчысы булып эшләүгә дучар ителгән.

Шагыйрьнең бу җыентыгына кертелгән әлеге поэмалары филология фәннәре докторы, профессор Хатип Госман редакциясендә басылып чыккан. Җыентыкка кереш сүзне филология фәннәре кандидаты Ш. Абилов язган, текстларны, искәрмәләрне һәм поэмаларга сүзлекне дә ул әзерләгән.

*Шәүкәт Галиев*

## Шигъри рецензияләр

*ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ. «Сайланма әсәрләр».*

**Йөз еллар үткәннәр —**
**Иман сау,**
**Давыллар өткәннәр —**
**Иман сау,**
**Яшеннәр теткәннәр —**
**Иман сау,**
**Тираннар беткәннәр —**
**Иман сау!**
**Ни хикмәт, могҗиза —**
**Иман сау?!**

**Иманнар бездән дә**
**Калырлар,**
**Тагын күп буынны**
**Таныйрлар,**
**Кояшка үрелә**
**Барырлар!**
**Ни хикмәт, могҗиза?!**
**— Тамырлар!**
**Тамырлар —**
**Нык,**
**Тиран тамырлар!**

*ӘМИРХАН ЕНИКИ.*
*«Салават күпере». Хикәяләр.*

**Салават күпере үзе**
**Сирәк кенә күренә,**
**Онытылмыйча гомергә**
**Кала күңел күгендә.**

*НИЛ ЮЗИЕВ. «Традицияләр яңаргандa».*
*(Хәзерге татар поэзиясе турында этюдлар.)*

**Эзләнергә, уйланырга,**
**Шигырь диеп янарга,**
**Сау шагыйрьләр турында да**
**Мөмкин икән язарга!**
**Традицияләр яңара!!**

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Соңгы мәгълүматларга караганда СССР язучылар союзында барлыгы 6560 язучы тора.

Шуларның 2270 е — прозаик, 2185 е — шагыйрь, 918 е — тәнкыйтьче, 481 е — драматург, 180 е — балалар язучысы, 379— тәрҗемәче, 110— очеркист һәм 37 фольклор белгече.

Татарстан язучылар союзында 1967 елның 1 апреленә алынган мәгълүматлар буенча 110 язучы бар. Аларның 90 ы — татар телендә, 17 се — рус телендә, 2 се чуваш телендә һәм берсе еврей телендә яза. Жанрлар буенча язучылар коллективы болай бүленә:

Прозаиклар —41, шагыйрьләр —34, драматурглар —10, тәнкыйтьчеләр —16, тәрҗемәчеләр —7, очеркистлар —1 һәм фольклор белгече —1 кеше. (Балалар язучылары аерым жанрлар буенча исәпләнде). Татарстан язучылары коллективы арасында 16 фәннәр докторы һәм кандидаты бар.

## ШАГЫЙРЬЛӘР СЕКЦИЯСЕНДӘ

10 мартта шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышында яшь шагыйрь һәм прозаик Фәнис Яруллинның иҗаты турында сөйләшү булды.

Фәнис Яруллин — «Мин тормышка гашыйк» исемле шигырьләр һәм «Май төне» исемле хикәяләр китапларының авторы. Фәнис үзенең соңгы вакытта язылган яңа шигырьләр җыентыгы белән таныштырды. Фикер алышуда Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Марс Шабаев, Газиз Мөхәммәтшиннар катнашты. Алар Фәнис Яруллин иҗатының соңгы вакытта үсүгә таба баруын билгеләп үттеләр. Кимчелекләрен күрсәттеләр.

Фәнис Яруллин секция исеменнән СССР язучылары союзына член итеп тәкъдим ителде.

## ПРОЗА СЕКЦИЯСЕНДӘ

31 мартта Язучылар союзында проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Утырышның төп темасы итеп хикәядәге сюжет һәм композиция мәсьәләләре алынган иде. Кереш сүз белән чыгыш ясаган Н. Гыйззәтуллин хикәя жанрының әдәбияттагы роле, аның үсеше һәм үзенчәлекләренә тукталды. «Соңгы ун ел эчендә бу жанр бездә бик нык үсте, активлашты. Моңа тормыштагы иҗтимагый-әхлакый яңарышлар сәбәп булды»,— диде ул һәм мисал итеп «Әйтелмәгән васыять», «Өч аршын җир» һәм башка әсәрләрне күрсәтте.

Утырышның төп докладчысы Г. Минский хикәя жанрының кайбер кануннарына кагылып үтте. Аның: «Бу өлкәдә яңалык эзләргә кирәк түгел. Әдәбиятның үзгәрми торган традицияләре бар, сюжетсызлык һ. б. яңалык түгел, ә үткәнгә кире кайту»,— дигән фикере бәхәс тудырды.

«Г. Минскийның сюжетсызлыкка караган сүзләре белән килешмим. Сюжет бетми, ә иске мәгънәсен генә югалта. Кайбер хикәяләрнең төбендә вакыйга ятмый. Ләкин моңа карап композиция катлаулылыгы кимеми, хәтта арта бара»,— дип сүз башлады Р. Мостафин. Фикерен дәвам итеп, ул абзац мелодиясе, абзац композициясе, дөнья хикәясе тарихындагы реаль кешене реаль булмаган вакыйга аша сурәтләү мисалларын күрсәтеп үтте.

Язучы М. Әмир мәсьәләнең мөһимлегенә басым ясаганнан соң, композиция, сюжет турында үз фикерләрен әйтте.

«Мин «Рәшә» повестеның ике: журнал һәм китап вариантларын эшләдем. Аның икенчесендә әсәрнең композициясе, яңгырашы һ. б. үзгәрде. Бу нәрсә әйтәсе килгән әйберне ничек отышлырак бирү турында уйлаудан килеп чыкты», — диде Ә. Еники.

Фикер алышуда катнашкан Г. Бәширов әдәбиятыбызның тарихын белә торып та, аңа әле тиешле бәя бирелмәве турында сөйләде. Аның татар хикәяләренең иң яхшы үрнәкләре тупланган җыентык чыгару кирәклеге турындагы тәкъдиме хуплап каршы алынды.

Йомгаклау сүзе белән чыгыш ясаганнан соң, А. Расих секциянең киләчәктәге планнары турында сөйләде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

30 мартта Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлегендә отчет-сайлау җыелышы булды. Әлмәт язучыларының икееллык эше турында бүлек секретаре Ә. Маликов сөйләде. Җыелыш бүлек бюросының яңа составын сайлады. Секретарь итеп Г. Ахунов билгеләнде.

Журналыбызның бу санында Ә. Маликовның шул җыелышта сөйләгән докладын урнаштырабыз. Доклад кыскартылып басыла.

### Тормышның алгы сызыгында

Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлегенә берләшкән әдәбиятчылар тормышның тиз үзгәрүчән, хәрәкәтчән, әле стабильләшеп җитмәгән участогында яшиләр. Бирегә өр-яңа коллективлар, яңа поселок һәм шәһәрләр туып тора. Хезмәттә, семьяда яңа мөнәсәбәтләр урнаша. Шәһәрчә киенсә дә, күңеле, җаны белән авылча калган егетләрне, кызларны биредә еш очратасың. Менә болар барысы Әлмәт язучыларыннан аеруча җитезлекне, сизгерлекне таләп итә. Безнең шагыйрь һәм прозаикларыбызның, күләмле әсәрләр язу дәвамында, әледән-әле очерклар, газета мәкаләләре язарга алынулары, бәлки, нәкъ менә шунардан киләдер дә.

Р. Төхфәтуллин һәм Г. Ахуновның, М. Зарипов һәм М. Хәсәновның нефтьчеләр һәм игенчеләр тормышы, җир белән нефть бәхәсе турында язылган очеркларын укучылар яратып каршы алды. Ш. Бикчурин, М. Хәсәнов һәм журналист Фазыл Мостафин Татарстан нефтенең егерме еллыгына багышлап зур күләмле очерк китабы язарга керештеләр.

Соңгы ике ел эчендә Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар» романы, Р. Төхфәтуллинның «Еллар авазы» исемле хикәяләр җыентыгы, «Алтын канатлы кош», «Кыңгырау чәчәк», «Алсу болытлар», «Тегермән буасы» дигән хикәяләре, Г. Ахуновның «Хыялый Хәйрүш егетләре» исемле китабы, «Балет мастеры» («Литературная Россия»), «Ризамы син, Рәхим», «Чәч бөртеге» дигән хикәяләре, Әдип Маликовның «Без кояшны юлда каршылыйбыз» повесте (Детгиз), «Кембригә юл салучылар» исемле очерклар китабы, Ш. Бикчуринның «Кайнар чишмә» исемле документаль повесте, Э. Касыймовның хикәяләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре басылып чыкты.

Шагыйрьләрдән Г. Афзалның «Җәйге болытлар», «Өянкеләр моңы», «Йокысыз төндә» («Советский писатель»), «Офыклар», «Өф-өф итеп» (Уфа, Башиздат) исемле шигырь җыентыклары басылып чыкты, С. Сөләйманова һәм Э. Мөэминовалар зурлар һәм нәниләр өчен икешәр китап бирделәр.

Драматургия дә тик тормый. Әлмәт театры тамашачыга Г. Ахуновның «Утлар яна учакта» дигән пьесасын җиткерде. С. Кальметов «Тозлы шикәр», «Тайгак тау», Р. Төхфәтуллин «Гашыйклар урамы» дигән пьесалар өстендә эшлиләр. Болардан тыш, Сәет Кальметов авыл сәхнәләре өчен бер пәрдәлек пьесалар, күп кенә скетчлар язып бастырды.

Билгеле, безнең эштә кимчелекләр, кыенлыклар да бар, хәл ителмәгән мәсьәләләр дә байтак кына.

Татар әдәбиятында республикабызның нефть индустриясен зур, киң масштаб белән, тирән итеп, бай романтикасы белән чагылдырган әсәр әле язылмаган. Без Ахуновның «Хуҗалар» романына өмет баглап торабыз. Ул анда киң колачлы коммунист, партия җитәкчесе образын да, үзебезнең арадан үсеп, дәүләт эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрелгән производство командирлары образын да тудырыр дип көтәбез. Безнең үзебез яшәгән яклар, мондагы кешеләр турында халык теленнән төшми торган шигырьләр, бигрәк тә, җырлар иҗат итә алганыбыз юк әле. Нефтьчеләр турында барыбыз да җыр текстлары язып карадык. Ул җырлар музыкага да салынды, радиодан да күп мәртәбәләр тапшырылды. Ә халык отып кала алмады...

### Яшь үрентеләр — безнең киләчәгебез

Нефть районнарында исемнәре матбугат битләрендә күренгән, каләмнәре шактый өметле булган 50 дән артык яшь автор исәпләнә.

Әлмәттә бөреләнеп, хәзер Казан университетында укуларын дәвам иттерүче Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова, мәсәлчә Сәлим Шәйдуллин иптәшләр шәһәр, район газеталары битләрендә үзләренең шигырьләре белән актив катнашып киләләр.

Лениногорск әдәбият берләшмәсе җитәкчесе Альберт Хәсәнов балалар өчен «Озын аяк» исемле матур гына китап чыгарды. Быел аның «Таң йолдызы» дигән хикәяләр җыентыгы басылачак. Ашыкмыйча эшләсә, Альберт яхшы хикәяләр яза алачак. Теле, белеме, хәзерлеге бар. Тик яшь авторга җитдилек җитеп бетми, ашыга, кабалана.

Узган ел Җәмит Рәхимовның «Алтын яткан җирләрдә» исемле очерклар китабы басылды. Үз эшләрен чын күңелдән яратып башкаручы кешеләр турында автор җылы, күңелдә калырлык итеп яза алган.

Нефть якларында эшләүче яшь авторлардан 13 иптәшнең иң яхшы шигырьләрен, хикәяләрен сайлап, китап нәшриятына «Кешеләр һәм чәчәкләр» дигән җыентык тәкъдим ителде. Бу җыентыкка безнең өметле авторлардан Флера Гыйззәтуллина, Әхмәт Вильданов, Рафаил Субаев, Җәүдәт Исмәгыйлов, Имам Шәрәфетдинов, Мәхмүт Газизов, Әзһәр Гатауллин, Әгъләс Шәйхетдинов шигырьләре, Марсель Зарипов, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Наил Шәрәпов, Мөдәррис Усманов, Исхак Миңлебаев хикәяләре тәкъдим ителде.

Яшь авторлар белән эшләүнең төрле юлларын кулланып карыйбыз. Без күптән түгел Лениногорск районының Федотовка авылында укытучы булып эшләүче Мәхмүт Газизовның иҗатын бүлек утырышында тикшердек. Укып тикшерелгән 30 дан артык шигырь арасында 15 ләбе уңай бәя алды. Алар поэзиянең зур таләпләренә җавап бирерлек җитди шигырьләр. Киләчәктә бу авторның иҗаты белән «Казан утлары» журналы редакциясе дә кызыксыныр дип ышанабыз.

Мөдәррис Усманов, Лена Шәфикова хикәяләрен, Герман Крыловның «Рекорд-

лар сере» исемле очерклар китабын, Шәех Бариевның «Йолдызлар елмайганда» повестен, Имам Шәрәфетдиновның «Айсылу» поэмасын, Әзһәр Гатауллин һ. б. күп кенә авторларның шигырьләрен һәм Гаделҗан Газизовның «Безнең яз да килер» дигән тарихи романын да без барлык язучылар катнашында бүлек утырышына куеп фикер алыштык.

Язучылардан Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, С. Кальметов, Г. Афзал, Лениногорск, Баулы, Азнакай, Сарман, Бөгелмә районнарында берничәшәр тапкыр булып, әдәбият түгәрәкләре утырышларында катнаштылар, яшь авторлар белән индивидуаль семинарлар үткәрделәр.

Отчет чорында Әлмәт бүлегенә 65 автордан роман, повесть, хикәя, шигырьләр һәм очерклар керде, 5 мең биткә якын кулъязма укып тикшерелде.

Кулына каләм алган кеше гадәттә эшне шигырь язудан башлый. Безнең яшь авторларыбызның да иң күп өлеше поэзия «чире» белән газап чигә. Әлбәттә, аларның барысыннан да шагыйрь чыкмас. Бер өлеше прозага күчәр, бер өлеше, үзенең мөмкинлекләрен сынап карагач, язудан туктар. Ләкин менә бүген шунысы аяныч: безнең прозага килүче яшьләребез юк диярлек. Бу хәвефле хәл безне борчуга сала.

### Очрашулар

Язучы белән укучы арасында тыгыз элемтә җепләре сузылган. Ул я китабы аша очраша, я халык алдына үзе чыга. Без мондый очрашуларның төрле юлларын файдаланырга тырыштык: радио, телевидение аша чыгыш ясау, газетада тематик битләр бирү, әдәби кичәләрдә катнашу, китап укучылар конференцияләре оештыру һ. б.

Әлмәт язучылары Татарстан язучылар союзы уздыра торган әдәбият атналыкларында да еш катнашалар. Г. Афзал Норлат һәм Пермь өлкәсенең Барда районында, Р. Төхфәтуллин Чирмешән районында, Ә. Маликов Әгерҗе һәм Пермь өлкәсенең Барда районында, Г. Ахунов Мәскәүдә, С. Сөләйманова Мәскәү һәм Ленинградта уздырылган татар әдәбияты атналыкларында катнаштылар. Әдәби кичәләр күп булды.

Шунысы куанычлы, без бу очрашуларны һәм кичәләрне үзебез көчләп такмыйбыз, ә сорап килләләр. Димәк, Әлмәт бүлеге авторитеты файдасына сөйли бу факт. Ләкин икенче кыен ягы бар, очрашулар иҗатка бүленә торган энергияне, вакытны шактый күп алалар. Миңа кызык өчен ике ел эчендә союз членнарыннан кемнәр ничә очрашуда катнашканлыгын санап утырырга туры килде. Бу саннарга радио-телевидение чыгышлары да керә: Г. Афзал — 60, Г. Ахунов — 49, Р. Төхфәтуллин — 43, Ә. Маликов — 90, С. Кальметов — 13, Э. Мөэминова — 6 очрашуда катнашкан.

Әлбәттә, сан ягыннан куарга ярамый. Әгәр ул очрашулар һәр ике якка да файдалы икән, нигә алардан читләшергә? Язучы укучы каршында сынау үтә, көзгедәге шикелле, үз иҗатындагы уңай һәм кимчелекле якларны күрә. Ләкин бу очрашулар, безнеңчә, эстрада чыгышларына әверелергә тиеш түгел.

Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге тормышның алгы сызыгында, илебезнең иң зур нефть индустриясе үзәгендә яши. Европа буйлап узган «Дуслык юлы» биредә үзенең тирән тамырларын җәйгән. Девон мәйданнарында егәр һәм чыныгу алган йөзләрчә бораулаучылар, инженерлар хәзер туган ил киңлекләрендә яңа нефть чирәмнәрен күтәрәләр. Зур сулыш белән яши Әлмәт яклары. Халкыбыз Әлмәт язучыларыннан да бик хаклы рәвештә шундый ук зур сулышлы, киң колачлы һәм тормышның тирән катламнарын каерып алган әдәби әсәрләр көтә.

## БӨЕК ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘ

Казанлылар Габдулла Тукай исемендәге элекке кинотеатр бинасын хәтерлиләрдер. Бу бер катлы иске йорт культуралы ял итү өчен көн таләпләренә җавап бирми иде. Шуңа күрә быел, олы юбилей елында, аның урынына яңаны төзү көн тәртибенә куелды. Заманча итеп салына торган яңа кинотеатр бинасы янында халкыбызның яраткан шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл булачак.

## КАЗАН МУЗЫКА СӨЮЧЕЛӘРЕНӘ БҮЛӘК

Казанның Ирек мәйданында тагын бер матур бина үсеп чыкты — Казан дәүләт консерваториясенең концертлар залы бинасы. Аның проектының авторлары — архитекторлар М. Агишев һәм М. Яваев, конструкторлар О. Берим һәм Р. Зәбиров. Проект архитектура фәненең иң соңгы казанышлары нигезендә эшләнгән.

Тоташ пыяла ишекләргә Ирек мәйданыннан мәрмәр баскыч күтәрелә. Эчкә кергәч тә, төп фойе. Фойе стеналары гади итеп һәм шул ук вакытта хәзерге заманча зур зәвык белән бизәкләнә. Мәһабәт колонналар мәрмәр плита белән тышланган. Икенче катка алып менә торган баскычлар нәкъ Мәскәүдәге Съездлар сараендагы кебек эшләнгәннәр. Икенче катта тагын бер фойе башлана — монысы инде тәнәфес вакытында концерт турында фикер алышу һәм йомшак диваннарга утырып ял итү өчен.

Бинаның үзәге — тамаша залы. 700 кеше сыярлык урыннар баскыч-баскыч булып күтәреләләр. Сәхнәдә моңача Казанда беркайчан да булмаган музыкаль инструмент — орган. Аны махсус заказ буенча чех мастерлары эшләгән. Бу зал үзенең акустикасы ягыннан Союзда иң яхшылардан булачак.

Өченче катта — ике иркен күргәзмә залы. Бинада тавыш язу системасы һәм эфирга тапшырулар алып бару өчен радиостудия эшләнә. Шунда ук телевидение установкалары да куярга мөмкин.

Казан концерт залы республикабыз тамашачыларына Бөек Октябрьның 50 еллыгы уңае белән шатландыргыч бүләк булыр.

## СЕМЬЯ АНСАМБЛЕ

Соңгы елларда үзешчән сәхнәдә куанычлы бер хәл күзгә ташлана. Ансамбльләр хәзер бер гаилә эчендә дә оеша башлады. Бөтенсоюз үзешчән сәнгать фестивале барышында Балтачтан килгән Ибраһимовлар семья ансамбле тамашачыларда җылы тәэсир калдырды.

Иң элек Хәдичә апа, сәхнәгә чыгып, тальян гармунда моңлы итеп авыл көен сыздыра. Дәртле көй Мөбәрәк абыйны чакырып чыгара. Ул гармунга кушылып җырлый. Аның җырын олы кызлары Алсу күтәреп ала. Алсуга Римма кушыла. Римма җырны эстафета төсендә энесе Шамилгә тапшыра. Ә кечкенә Риләә җырны «финишка» илтеп җиткерә. Бу семья артистларының киемнәре дә, сәхнәдә үзләрен тотулары да, башкару осталыклары да художестволы ансамбль исемен тулысынча аклый.

## СӘЕТ ВАХИДИ ТУУГА 80 ЕЛ

Май аенда күренекле археограф, тарихчы һәм педагог Сәет Вахидиның туууна 80 ел тулды. Бу датаны гыйльми җәмәгатьчелегебез махсус билгеләп уза.

С. Вахиди элекке Спас өязенең Ташбилче авылында 1887 елны ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылында алгач, күрше авылларга һәм Казанга килеп Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укый. 1911 елны Уразлы авылына кайтып мөгаллимлек итә башлый, һәм шунда борынгы культурабызга караган тарихи истәлекләр җыю эшенә керешә. Авыллардан авылларга йөри. Йорттан йортка керә. Тырышкан табар дигәндәй, С. Вахиди да беренче зур казанышка ирешә: татар телендәге иң борынгы социаль-юридик документларның берсе булган Сәхип-Гәрәй хан ярлыгын таба. Ләкин аны бастырып чыгару бары Совет чорында гына мөмкин була.

Бу истәлекнең ачылышы белән дә С. Вахиди исеме фән дөньясында үз урынын яулаган булыр иде, чөнки борынгы чорыбызны өйрәнүдә ул документ иң ышанычлы, иң әһәмиятле истәлекләрдән исәпләнә. Ләкин галимнең әдәбият, фольклор тарихларын өйрәнү өчен дә керткән өлеше бик зур. Сүз ул җыеп калдырган борынгы кульязмалар, әдәби истәлекләр турында бара. Әйтергә кирәк, хәзерге Казан университеты һәм Азия халыклары институты китапханәләрендә саклана торган татарча кульязмаларның иң бай, иң кызыклы өлешен Сәет Вахиди җыеп, бернинди түләүсез бүләк иткән истәлекләр тәшкил итә. Алар арасында XVI—XVII гасырга караган сирәк һәм уникаль кульязмалар да шактый.

С. Вахиди табышларының гыйльми әһәмиятен җәмәгатьчелегебез үз вакытында ук югары бәяләгән иде. Академик А. Н. Самойлович, профессор Г. Гобәйдуллин, Н. Н. Фирсов, М. Г. Худяков һ. б. Вахиди эшчәнлеген тәкъдир итеп, махсус чыгышлар ясадылар.

Галимнең совет чорындагы эшчәнлеге нигездә педагоглык белән бәйләнгән. Музейда, гыйльми китапханәләрдә дә эшли ул. Кульязмалар җыю эшен һаман дәвам иттерә. Тик, кызганычка каршы, аның тормыш юлы репрессиягә эләгеп кисәктән өзелә.

Бу үзенчәлекле галимнең тормыш юлы, эшчәнлеге, һичшиксез, өйрәнелергә һәм тәкъдиргә лаек.

## ШАКИР МӨХӘММӘДЬЯРОВ

Мөхәммәтшакир Мөхәммәдьяров 1883 елда крестьян семьясында туа. Революциягә кадәр Петербург университетының юридик факультетын тәмамлый. Студент чагында ук, татар халкының әдәби, иҗтимагый хәрәкәтенә актив катнашып, үз чорының «милләт хадиме» саналып йөри. Татар халкы арасында белем-мәгърифәт таратырга тырышып йөрүче мәгърифәтчеләрнең берсе һәм шактый активы була.

Шулай ук студент чагында ул журналистика белән дә шөгыльләнә. 1906 елларда «Казан мөхбире» газетасында, шәкертләр хәрәкәтенә матди ярдәм күрсәтү киләклек турында, соңрак «Йолдыз», «Вакыт», «Ил», «Сүз» газеталарында сәүдә һәм экономика мәсьәләләре турында күп кенә мәкаләләрен бастыра.

Аннары «Алпавытлар» һәм «Сәүдә законнары» дигән әсәрләр язып, аларны аерым китап итеп бастырып чыгара.

Студент вакытында, данлыклы шагыйребез Габдулла Тукай Петербургка килгәч, беренче булып ул каршы ала, һәм аны Петербург белән таныштырып, докторларга күрсәтеп йөри.

Ш. Мөхәммәдьяров революциядән соң, үзенең элекке «таңчы» иптәшләре кебек, чит илләргә китеп, эмигрант булып каңгырып йөрмәде. Үз илебездә калып, Совет властен ныгытуга хезмәт итте. Эчке Эшләр Министрлыгында укытучы булып эшләде, шактый күп милиция кадры җитештерүдә ярдәм итте һәм милиция капитаны дәрәҗәсенә иреште.

Ш. Мөхәммәдьяров — революциягә чаклы иҗтимагый хәрәкәтнең уң флангысында барган кеше. Шулай булса да ул, һәлакәт чорында йөзтүбән китмичә, бик бормалы һәм бик тайгак юлларны намус белән үтте, үзенең төп юристлык эшеннән тыш, татар культурасын һәм әдәбиятын актив пропагандалаучы да иде ул. Ташкентта пенсиягә чыгып, 1967 елның февралендә вафат булды.

——□——

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/IV-1967 ел. Басарга кул куелды 23/V-1967 ел. ПФ 09019. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 58846 экз. Заказ М-717. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# КРОССВОРД

Төзеде: Г. БУЛАТОВ, Әлмәт шәһәре.



*Вертикаль буенча:*

1. «Ак каен» исемле поэма авторы.
2. «Хәзинә» исемле роман авторы.
3. «Гади кешеләр» исемле роман авторы.
5. «Яз сулышы» исемле шигъри җыентык авторы.
6. «Алман илендә» исемле шигырь авторы.
7. «Су анасы» исемле шигырь авторы.
9. «Шобага» исемле хикәя авторы.
14. «Ак чәчәкләр» исемле роман авторы.
15. «Тирән тамырлар» исемле роман авторы.
17. «Әйтелмәгән васыять» исемле хикәя авторы.
18. «Ташкыннар» исемле драма авторы.
19. «Тапшырылмаган хатлар» исемле повесть авторы.
31. «Галиябану» исемле драма авторы.
32. «Бибиевләр» исемле поэма авторы.
33. «Пар ат» исемле поэма авторы.
34. «Карлыгач канат кага» исемле драма авторы.
36. «Матурлык һәм бәхет» исемле китап авторы.
37. «Таң йолдызы» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.
40. «Җырла очрашу» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.

*Горизонталь буенча:*

4. «Этаплар китабы» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.
8. «Муса» исемле роман авторы.
10. «Өченче очрашу» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.
11. «Һаваларда йолдыз» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.
12. «Кембригә юл салучылар» исемле китап авторы.
13. «Батырлар һәм матурлар» исемле очерклар җыентыгы авторы.
16. «Агыйдел» исемле повесть авторы.
20. «Минем тәрәзәләрем» исемле повесть авторы.
21. «Аникин» исемле поэма авторы.
22. «Коръән серләре» исемле повесть авторы.
23. «Тукай һәм аның замандашлары» исемле китап авторы.
24. «Җир уллары» исемле трагедия авторы.
25. «Вөҗдан сүзе» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.
26. «Эшче» исемле поэма авторы.
27. «Хуҗа Насретдин» исемле комедия авторы.
28. «Хәерле кич» исемле драма әсәрләре җыентыгы авторы.
29. «Көннәрдән бер көнне» исемле хикәя авторы.
30. «Матур туганда» исемле роман авторы.
35. «Еллар һәм җырлар» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.
38. «Сигезенчесе кем?» исемле повесть авторы.
39. «Беренче яз» исемле роман авторы.
41. «Янар чәчәк» исемле комедия авторы.
42. «Ике буйдак» исемле роман авторы.
43. «Кырыс хикәят» исемле поэма авторы.
44. «Бала күңеле далада» исемле роман авторы.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

**(ОГНИ КАЗАНИ)**

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210